Безнең МИРАС

10

октябрь 2015

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Мөбарәк Аллаһ йорты!

23 сентябрьдә, Корбан гаете алдыннан, Мәскәүдә Җамигъ мәчете ачылды.

Фотолар РФ һәм ТР Президентларының рәсми сайтларыннан алынды

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС
12 +
10(45)
октябрь 2015

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

62

7 БУРСЫКЛЫ (ВОРСКЛА) СУЫ БУЕНДАГЫ СУГЫШ. *Гамир Гарифуллин*

50 БӘРӘКӘТЛЕ ОРЕНБУРГ ТУФРАГЫ. *Лирон Хәмидуллин*

ЭЧТӘЛЕК

2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

3 Яшәргә! *Рәшит Әхмәтҗанов*

ТАРИХИ МИРАС

4 Болгар. Олы манара. *Нурсөя Шәйдуллина*
7 Бурсыклы (Ворскла) суы буендагы сугыш. *Гамир Гарифуллин*
11 «Берек» газетасы. *Ленар Гобәйдуллин*
15 Үткәннән кайткан китап

ТАТАР ГАМЕ

16 Искермәгән Искер. *Мөнирә Сәгыйдуллина*
22 «Дуслык» һәм «Сандугач»!
24 Казакъстанга сәфәрләрем. *Миннәхмәт Кашапов*
29 Күл-Черкендә — Урманче музее

ПЕДАГОГИК МИРАС

30 Иң гүзәл гайрәт... *Диләрә Гыймранова*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

34 Сүз һәм сурәт. Рәдиф Гаташ

ӘДӘБИ МИРАС

36 Кутадгу билик (Котайткыч белем). *Йосыф Баласагуни*
41 Кыйссаи Таһир илә Зөһрә. *Мәсгут Гайнетдин*
50 Бәрәкәтле Оренбург туфрагы. *Лирон Хәмидуллин*
61 Тукай энциклопедиясе. *Зөфәр Рәмиев*
62 Якты эз калдырган шәхес. *Фәридә Гайфуллина*
64 Авылым сагышы
66 «Тукай клубы»: тарих һәм заман. *Сиринә Мөхәммәтҗанова*
68 Мәгъруръ нарат кебек... *Марат Закир*
71 Муса Җәлилнең «Седльце шигырьләре». *Хәнәфи Бәдигый*
76 Яшәү сере. *Роза Хәмидуллина*
78 Кадыйр Сибгатуллин шигырьләре

80 Каюм Насыйриның асыл теләге. *Эльмира Шәрифуллина*

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

84 Әни тавышы. *Зимфира Гыйльметдинова*
91 Илһам сәйраны
92 «Мәһдиевнең шәп язучы булачагына шикләнмим...»
98 Миллият сүзлеге. *Адлер Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

100 Курай. *Гүзәлия Җәләлева*
102 Йорт җанлы Туфан. *Ләбиб Лерон*

ТАТАР ҖЫРЫ

104 «Мин кемгә эндәшим?..» *Рафаэль Сәхәби*
106 Җырланмаган җыр. *Сәйдә Зыялы*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 «Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның октябрь ае. *Ленар Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 Авылым мәзәкләре яки Көлке куа кильә...
118 Гариф Ахунов турында мәзәкләр

119 Мирасворд
120 «Безнең мирас» елъязмасы. *Октябрь*

Заказ №О-2792. Тираж — 1500 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 02.10.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Ленар Гобәйдуллин төшергән, авторларның, Г.Камал театры һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Саубуллашу». 2001 ел
Киндер, майлы буяу. *Ф.Халиков рәсеме.*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)



Рәшит ӘХМӘТҖАНОВ
(1941-1995)

....

ЯШӘРГӘ!

(«Ачлык мәйданы» дигән шигырьләр циклыннан)

Яшәргә! Яшәргә! Азатлык алмыйча
Кузгалып китү юк быелгы җәемнән.
Башкае киселгән нәселем Агачы
Тамырдан таралып, дөньяга җәелгән.

Җәелгән җиремә — үлемсез агачым,
Иелмәс иңнәре биеккә үрелгән.
Яшәргә! Яшәргә! Яшәүләр — кешегә
Мең кабат газаплы булса да үлемнән.

Коллыкны яндырыпканыбыз дөрләсен,
Дөрләсен, сүнмәсен — ант итик, Ватанчы:
Йә бозлы йортыма азатлык яуларбыз,
Йә янып бетәрбез — көл булып калганчы!

Илемә багышлап үземне, сүземне
Ачлыкта утырам шул газиз нигездә.
Яшәүне сөям мин!..
Сөягем белән, Ил,
Иреккә илтүче юлларны тигезлә!

1991

БОЛГАР. ОЛЫ МАНАРА

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Җамигъ мәчетенең төньяктагы төп фасадына аркалы ишек порталы һәм «Олы манара» буларак билгеле биек манара тоташкан.

Россия тарихында үткән дәверләрнең архитектура корылмаларын саклауга юнәлтелгән беренче акты — Пётр Iнең борынгы Болгар истәлекләрен реставрацияләү һәм өйрәнү зарурлыгы турында указы барлыкка килү нәкъ менә шушы манарага бәйле. 1722 елгы Фарсы походы вакытында император Болгар харәбәләрен шәхсән үзе караган, алар анда зур кызыксыну уяткан. 1722 елның 2 июлендә, Әстерхан шәһәренә җиткәч, император Казан губернаторы А.П.Салтыковка атап указ җибәргән, ул анда «Казан губерниясендә борынгы Болгар шәһәрлегендә татар манаралары дип аталган ике баганаың нигезен төзәтүне» таләп иткән.

Олы манара төзекләндерелгән, ләкин безнең көннәргәчә сакланмаган, 1841 елда җимерелеп төшкән. Җимерелер алдыннан аны инглиз галиме Э.Турнерелли караган. Манара XIX гасыр үлчәм рәсемнәре буенча яхшы мәгълүм. Ул югарыдан кече һәм түбәндәге зур цилиндрлардан торган 24 метрлы күләмнән гыйбарәт булган. Түбән цилиндрның төп көпшәсе аскы өлештә сигез кырлы ярус аркылы 5 метрга 5 метр зурлыктагы квадрат нигезгә үткәрелгән. Манара эчендә югарыдагы уратма галереялы, цилиндрлы катка мену өчен винтлы баскыч ясалган, ул зур булмаган алты тәрәзә белән яктыртылган. Болгарда шулай ук сакланып калган Кече манарадан аермалы буларак, Олы манара ике тапкыр биегрәк булган һәм фасадының урта биеклегендә гарәп язмасы — Коръән сүзләре уелган. Бу тарихи һәйкәл археологлар тарафыннан 1892, 1915, 1946 һәм 1964-1966 елларда тикшерелгән. Манара 2000-2002 елларда элеккеге үлчәмнәрдә торгызылган. 2011-2012 елларда манараның кече цилиндрын реконструкцияләү буенча эшләр башкарылды: аркалы декоратив тәрәзә уемнары ясалды, бакыр белән тышланды, уемлап ясалган бизәкле ишек куелды. ■

Бурсыклы (Ворскла) суы буендагы сугыш. 1399 ел

БУРСЫКЛЫ (ВОРСКЛА) СУЫ БУЕНДАГЫ СУГЫШ

Гамир Гарифуллин

1396 елның азагы, 1397 еллар башында Тимер Котлык белән Идегәй 1395 елда Терек суы буендагы кырылыштан соң Кырымда ныгып урнашкан Туктамыш ханга каршы сугыш ача.

Тимер Котлык Кырым аксөякләренә төрле бүләкләр өләшә, өстенлекләр вәгъдә итеп, аларны үз ягына аударуга ирешә. Нәтиҗәдә, Туктамыш ханга хыянәт иткән югары катлау вәкилләре орышның хәлиткеч мизгелендә тылда баш күтәреп, Тимер Котлыкка җиңү китерә. Шул рәвешле, Туктамыш ханга Кырымны ташлап китүдән башка чара калмый [1]. Хан гаиләсе (ханбикәләр, олы уллары Җәләлетдин, Кәримбирде) һәм өч төмәннән (30 меңнән) артык гаскәр белән сыену урыны эзләп бу вакытта Киевта яшәүче Литва кенәзе Витаутас янына килергә мәҗбүр була.

Туктамыш белән дустанә мөнәсәбәтләрдә булган Витаутас ханны һәм аның чирүен зур хөрмәт белән кабул итә. Аның белән килгән, соңрак өстәмә көчләр буларак килеп җитәргә тиешле булган яугирләргә дәүләт чиге буенда, аерым алганда Черкас һәм Канев шәһәрләре тирәләрендә утлавыкларга бай булган җирләр бүлеп бирелә. Ә Туктамыш хан гаиләсе һәм яраннарына исә әйләнә-тирәдәге җирләре белән бергә Лида шәһәре дә бирелә. (Төркитатарларның Литва кенәзлегенә күчеп утыруларына 1997 елда 600 ел тулды. Шул уңайдан элек Бөек Литва кенәзлегенә кергән Польша, Белоруссия, Балтыйк буе илләрендә бу датаны зурлап билгеләп үттеләр. Бүгенге көндә бу дәүләтләрдә 20 меңләп канкардәшләребез гомер кичерә. Гәрчә гасырлар дәвамында туган телләрен югалтсалар да, алар гореф-гадәтләрен, ислам динен хәзергәчә саклап кала алган.)

Киевта кенәз Витаутас белән Туктамыш хан арасында уртак тел табылып, алар үзара ярдәмләшү турында килешү төзиләр. Килешүдә Витаутас Туктамышка кире Сарайны алуда булышлык күрсәтү, ә Туктамыш хан үз чиратында моның өчен, Русь Алтын Урда олысы булып исәпләнгәнгә, Литва кенәзенә урыс кенәзлекләре белән идарә итү хокукын бирү турында ризалык белдерә. Әлеге ниятне тормышка ашыруда киртә булып Тимер Котлык белән Идегәй генә торганлыктан, иң әүвәл аларны Сарайдан куып җибәрү бурычы куела.

Каршы якның рухын алдан ук төшерү максатында һәм килешү шартларын үтәү йөзеннән, Витаутас 1398 елның көзендә Днепр белән Донның түбән агымнарына зур яу сәфәре ясый. Литва гаскәрләре әллә ни зур каршылыкка очрамыйча, Алтын Урданың көньяк олысларына үтеп кереп, шактый зур мәйданны бөлгенлеккә төшерә.

Биниһая мал-мөлкәт, бихисап терлек-туарны талап алып, бик күп гаиләләрне тоткын итеп, баскынчылар кире кайтып китә.

Хәер, уңышлы дип исәпләнгән сәфәр көтелгән нәтиҗәгә китерми. Витаутас белән Тимер Котлык арасындагы мөнәсәбәтләр тагын да кискенләшеп, Бурсыклы (Ворскла) суы буендагы һәлакәтне тизләтә генә.

Үз-үзенә чамадан тыш ышанган Витаутас Тимер Котлык һәм аның артында торучы Идегәй мирза көчләрен бәяләп бетермәгән, күрәсең. Туктамыш ханның кан дошманына әверелгән Идегәй, Тимер Котлыкның әмирләр башлыгы буларак, хан җитәкчелегендә шактый зур төрки-татар гаскәрен Витаутаска каршы җибәрә. Бер үк вакытта ул Тимер Котлыкка Витаутастан Туктамыш ханны, аның улларын кире кайтару бурычы куеп, беркадәр вакыттан соң калган гаскәр башында хан артыннан үзе дә кузгала.

1399 елның июль азакларында Тимер Котлык 13 төмәннән (130 мең) торган чиру белән Днепрга койган Бурсыклы суының сул як ярында, Идегәй мирзаның килеп җитүен көтәргә ниятләп, ыстан корып урнаша. Бер үк вакытта кенәздән Туктамышны кире кайтаруны таләп итә. Мәгәр Витаутас Туктамышны кире кайтарудан баш тартып, күп тә үтмәстән, елганың уң як ярында, нәкъ урдалылар ыстаны каршында үз гаскәрен урнаштыра. Үзеннән күпкә көчлерәк дошман белән бергә-бер калу мөмкинлеген күздә тотмаган Тимер Котлык каушап кала.

Чыннан да, төп литва-беларус гаскәреннән тыш аңа ярдәмгә килгән Польша шляхтичлары, Пруссиядән — немец рыцарьлары, урыс дружиналары [2] һәм билгеле инде, Туктамыш хан чирүе белән көчәйтелеп, өстәвенә бик күп утлы корал — туп һәм пищальләр белән тәэмин ителгән 240 меңлек союздаш гаскәрләр төрки-татар чирүеннән ике мәртәбә диярлек артыграк була.

Витаутас үзенең гаять зур өстенлеген күреп, орыш башлап җибәрергә бик ашыкмый. Ул, Урданы кылычтан үткәрү белән янап, Тимер Котлыктан тулысы белән буйсынуны таләп итә, куркуга төшкән дошманның сугышсыз да бөтен куйган шартларны үтәвенә өмет баглый.

Каушаудан соң бераз тынычланган Тимер Котлык үз нәүбәтендә вакытны сузар өчен сөйләшүләр башлап җибәрә, хәйләләп, төрле вәгъдәләр биргән була. *«Бөек кенәз шәфкать күрсәтеп, мине үз улы кебек күрсен иде. Шуның өчен мин аңа буйсынып җәй саен бөтен Урдадан җыелган салым-иманаы җибәреп торыр идем»*, — ди ул кенәзгә. Витаутас моннан ары Урдада сугылачак акчаларда үзенең сурәтен төшерүне таләп итә.

Үзен инде «Литва белән Русьның бөек кенәзе» дип игълан иткән Витаутас, сөйләшүләрне сузып, хан кармагына эләгүен сизми дә кала. Шул арада 60 меңлек чирү белән Идегәй мирза да килеп җитә.

Тимер Котлык ыстанына килеп җитеп, мондагы хәлләр белән танышкач, Идегәй әле юлда булган чирүенең яртысына лагерьга бер ярым фәрсах (1 фәрсах — 7 чакрым чамасы) ара кала сулгарак борылырга, шунда бер урында яшеренеп торырга атчабар аркылы фәрман җиткерә. Бер үк вакытта ул Тимер Котлык чирүеннән дә өч төмәнне далага шул ук ераклыкка озатып җибәреп, аларга уңгарак керергә һәм таң атканчы күрсәтелгән урында булырга, берәр чокыр яисә агачлыкта поскында торырга әмер бирә.

...Идегәй килеп җиткәч, Витаутас белән сөйләшүләр бөтенләй көтелмәгән төс ала. Аның: *«Батыр кенәз! Сине безнең хан атасы урынына исәпләми булдыра алмагандыр, чөнки яшь буенча син аңардан олырак. Мәгәр, үз нәүбәтендә, син миннән яшьрәк (бу чакта Идегәйгә 47 яшь була). Шуңа күрә, әгәр дә син миңа буйсынуыңны белдереп, салым түләргә йөкләмә алсаң, аннары Литва акчаларын-*

да минем исемне күрсәтеп суктырсаң, дөрес булыр иде, шәт», — дип, хан белән сөйләшүләрдән аермалы буларак, Идегәйнең Витаутас алдында үз таләпләрен куюы кенәзне ни дәрәҗәдә ярсытып җибәрүен хәтта күз алдына китерүе дә кыен.

Хәлбуки, әлеге сүзләрдән тынычланып кына килгәндә, кинәт төрки-татарларның торган урыннарын калдырып, кире китүләре турында хәбәр алына. Һәм шул мизгелдә үк (1399 елның 12 август көне) кенәз үз гаскәрләренә елга аркылы чыгып, урдалыларны эзәрлекләү турында боерык бирә.

Алдалап далага чыгарылган Литва гаскәре, шактый зур мәйданга җәелеп (чөнки җәяүле гаскәр белән авыр туплар атлы гаскәрдән күпкә артка калып хәрәкәт итәләр), урдалыларны эзәрлекләп китә. Әмма яр буеннан 10 чакрымнар чамасы ара узгач, кенәзне гаять гаҗәпләндереп, урдалылар көтмәгәндә атларын кире боралар да, имәнеч тавышлар белән куып баручыларга каршы ташланалар.

Литва кенәзе Витаутас

Озак та үтми, алдагы җайдаклар килеп бәрелешә һәм бөтен рәт буенча каты орыш башланып китә. Башта бәрелеш литвалылар өстенлеге белән барган кебек күренә. Аларның кысрыклавына каршы тора алмаган урдалылар, артка тайпылыш ясап, менә-менә тәртипсез чигенә башларлар төсле сыман. Мәгәр, һич көтмәгәндә литвалыларның уң һәм сул якларыннан бер үк вакытта дияр-лек урдалыларның поскындагы атлы төркемнәре һөҗүм ясый. Җайдаклар атларын җан-фәрманга чаптырып килгән хәлдә, дошманның флангларын урап алып, аларның тылына үтеп керә башлыйлар…

Туктамыш хан төмәннәре Литва гаскәренең уң канатын тәшкил итә. Поскындагы чирүнең һөҗүмен беренчеләрдән булып Туктамыш хан күреп ала. Орыш вакытында ул барыннан да бигрәк чолганышта калудан курка. Шуңа күрә хан, төмәннәрен кире борып, менә-менә һөҗүмгә ыргылган дошман яугирләре белән бәрелешне булдырмас өчен, бөтен көчкә тылга чабып китә.

Мәгәр литвалылар моны үзләренчә аңлап, һәркайда: «Без чолганышта! Туктамыш хан гаскәре кача!» — дип, сөрән сала башлыйлар. Ахыр чиктә ыгы-зыгы һәм гомуми паника килеп туа. Бу хәлдән файдаланып, Идегәй

шунда ук ике-өч төмәнне Туктамыш ханнан калган бушлыкка кертеп җибәрә һәм бер үк вакытта үзәккә һөҗүмне көчәйтә. Әйләнә-тирәдәге таркалышны һәм камап ала башлауларын күреп, союздаш гаскәрләр беләнберрәттән, үзәктәге Литва полклары да качарга тотына.

Шул арада тылда куркынычсыз урынга үз вакытында килеп җиткән Туктамыш хан төмәннәре Идегәйнең камап алу өчен җибәргән төркемнәре белән бәрелешкә керә. Алар Идегәй гаскәренә елгага таба чигенү юлын кисәргә ирек бирми. Ләкин Литва гаскәрләренең яу кырын ташлап качуларын күргәч, алар бөтенесен калдырып, су буена ыргылалар. Юл уңаенда литвалыларның туплар белән әле һаман яу кырына хәрәкәт итүче җәяүле гаскәрен таптап китеп, алар беренчеләрдән булып елга буена чабып килеп җитәләр, мондый очракларда еш күзәтелә торган мәхшәр башланганчы уң як ярга чыгып өлгерәләр.

Паникага бирелгән Литва гаскәрләре дә, башлыкларына буйсынудан туктап, аларның акырыну-җикеренү, куркыту-янауларына бернинди игътибар бирмичә, елга буена атлыга. Хәзер литвалыларга бер генә нәрсә мөһим: ул да булса төрки-татарлар чигенү юлларын кисеп өлгергәнче, кечү урынына барып җитү.

...Кичү барышында Витаутас гаскәре санап бетергесез югалтуларга дучар ителә. Каршылык күрсәтү сәләтен бөтенләй югалткан литвалылар, поляклар, немецлар, урыслар кылычтан һәм ук яңгыры астында, шулай ук кулга төшкән тупларны кире борып хуҗаларына каршы ут ачу нәтиҗәсендә яр буенда, суда батып, мизгел саен меңәрләп-меңәрләп сафтан чыгып тора... Гаять зур гаскәрдән бик аз өлешенә генә елганы аркылы чыгып, эзәрлекләүдән котылу бәхете насыйп була.

Тар-мар ителгән гаскәрнең зур-зур олауларының, бар туп һәм пищальләренең (авыр мылтыкларның), тау-тау өелгән салкын коралның, бихисап әсир һәм меңләгән атларның ганимәт малы буларак җиңүчеләр кулына эләгүе — литвалылар өчен әлеге орышның ни дәрәҗәдә фаҗигале тәмамлануын дәлилли. Йөз меңнән артык яугир, шул исәптән Л.Н.Гумилёв раславынча, 20дән артык кенәз ошбу хурлыклы сәфәрдән әйләнеп кайта алмый.

Төрки-татар гаскәре качып китүчеләрне артларыннан калмыйча 500 чакрым ара, ягъни Киевка кадәр эзәрлекләп килә. Фәкать Витаутастан заманына күрә шактый зур — 3000 сум күләмендә йолым алгач кына алар кире үз далаларына кайтып китә [3].

Идегәйнең Туктамышны тота алмаудан гына кәефе кырыла. Туктамыш исә әлеге кырылыштан соң Витаутасның аңа берничек тә ярдәм итә алмаганлыгын яхшы төшенгәнлектән, Бурсыклы буенда канлы суешның тәмамлануын көтеп тормый. Елганы калганнардан ике-өч сәгатькә элегрәк кичеп чыгып, ул үзенең төмәннәре белән, Киев тарафына түгел, ә Донның үрге агымы якларына һәм аннан да арырак — Алтын Урданың Урал артындагы олыслары ягына чабып китә. Идегәй исә, Туктамыш ханның Витаутас гаскәре алдыннан чабып баруына инанган хәлдә, аны эзәрлекләми.

Искәрмәләр.

1. Фәхретдин Р. Туктамыш хан // Мирас. — 1993. — №10. — Б.74-75; Гумилёв Л.Н. Древняя Русь и Великая степь. — М.: Т-во Клышников, Комаров и К°, 1993. — 452 с.
2. Немец рыцарьлары белән шляхтаның ярдәмгә килүләренең сәбәбе — өстен чыккан очракта Туктамыш ханның Алтын Урдада католик динен кабул итү белән кызыктыруы булса, урыс дружиналарының катнашуы исә туганлык мөнәсәбәтләре белән аңлатыладыр (Витаутас кызы София Мәскәү кенәзе Василий Дмитриевичта (Дмитрий Донской угылы) кияүдә була).
3. Фәхретдин Р. Күрс. хез. — Б.74; Каратеев М. Русь и Орда. II книга. — М: «Новая книга», 1993. — С.343-352.

«БЕРЕК» ГАЗЕТАСЫ

Ленар Гобәйдуллин

1918 елда большевиклар йогынтысында «Кояш», «Тормыш», «Йолдыз», «Вакыт», «Шура» кебек саллы матбугат басылып чыгудан туктатыла, аларның урынын «кызыл» эчтәлекле газеталар яулап ала. Шул ук елның җәеннән Казан, Самара, Царицын, Уфа, Бәләбәй, Чиләбе, Оренбург, Кызылъяр, Омск, Томск шәһәрләрендә чехословаклар корпусының совет режимына каршы коралллы чыгышы вакытында 21 большевистик булмаган, милли рухтагы либераль-демократик басмалар да дөнья күрә башлый. Бу шәһәрләр Кызыл Армия тарафыннан яулап алынганнан соң инде, әлбәттә, әлеге газеталарның да сулышы кысыла[1].


№ 7.
برك

ТР ТСД ҮДА фондыннан

Сүзебез Уфа губернасы Бәләбәй шәһәрендә өяз земствосы нәшрияты тарафыннан дүшәмбе, пәнҗешәмбе көннәрендә чыгарылган иҗтимагый һәм әдәби газета «Берек» хакында. Танылган матбугат белгече Исмәгыйль Рәмиев газета турында: *«1918 елның август башларында Уфа губернасы Бәләбәй шәһәрендә чыга башлады. Чехословаклар вакытында чыгарылган битараф гәзит. «Йорт тумасы большевиклар» дип бик күп язды. Типичный земство гәзите иде»*, — дип искәртә[2]. Газетаның үзенә «хәзергә атнада ике чыгып, эшләр уңайлану белән тиз көндә көндәлек булачак», дип язылса да, И.Рәмиевнең альбомында *«көткәнчә эшләр уңайланмады, Бәләбәй кызыл яулар тарафыннан алыну белән, әлбәттә, инде моның гомере бетте»*, — дигән мәгълүмат бар.

«Берек»нең «күзәткән теләге» дә түбәндәге юллардан аңлашылса кирәк: *«Большевиклардан айну, алардан тазарынуны безнең халык бөтенләй икенче төрле аңлады. Безнең милли хәятебезгә зур зарарлар иткән, милли максатларыбызны вөҗүдкә чыгару эшенә аркылы агач тыккан «мәрхүм большевикларыбыз» урынына тагы үзебезнең йорт тумасы уңнарыбыз килеп чыкты. Алар тазарынудан бөтен гыйльми көчне барлык зыялыларыбызны себереп түгү, дип аңладылар. Аңладылар да эшкә тотындылар. Һәрбер яңалыкка, һәрбер милли хәрәкәтләргә алар большевиклыкioктаи назарыннан карый башладылар. Кызулык белән үтеп*

[1] Насыйров Т. Гражданнар сугышы чорындагы большевистик булмаган татар матбугаты // Гасырлар авазы - Эхо веков. — 2001. — №3/4. — Б.242-249.

[2] Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (1905-1925): альбом. — Казан: Гажур, 1926. — Б.107.

барган кадерле вакытларыбызны без үзебезне аякка бастырурга сарыф кыласы, большевиклардан калган җирләрне ямау һәм төзәтү эшендә дәвам итәсе урында — без милләтебезгә яңа авырулар йоктыра, милли хәятебезнең табигый агымын җимерергә тотынды. «Йорт тумасы большевикларыбыз» беткәнгә куанган вакытларда милләтебезнең йөрәген инде «йорт тумасы уңнарыбыз» тырмый башлады. Бу агым көчәеп китсә, без алга киттек түгел, бәлки кире кайттык, дибез. Без 10-15 ел буенча чәйнәлгән ысул җәдид, ысул кадим мәсьәләләрен чәйнәү, шуларны хәл кылу дәверенә кайтабыз була. Менә шундый мәсьүлиятьле (җаваплы) вакытларда бөтен зыялы көч берләшергә, **барлык урыннарда милли мәсьәләләр аякка бастырылырга тиеш.** *Бигрәк тә Диния нәзарәте бу тугрыда хәрәкәт күрсәтсә иде. Без — яшь бер милләт, без яшәргә телибез, шуңар күрә үз йортыбызда үскән суллар да хокукыбызны таптамасыннар. Шулай ук уңнар да черек башларын күтәрмәсеннәр*[3]*».*

Газета Бәләбәй шәһәрендәге «Таң» ширкәте типографиясендә басылган. Соңгы сәхифәдә бирелгән мәгълүматка караганда, әлеге матбаганың кибете дә булып, уку һәм язу-сызу әсбаплары сату итү белән дә шөгыльләнгән.

Хәзерге заман укучысына газетаның фәкать ике генә данәсе мәгълүм. 7 нче саны ТР Тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивында, 6 нчысы Башкортстанда саклана[4]. Без файдаланган 29 август санында (№7) «Башкортлык хәрәкәте», «Кавказда хәлләр», «Украинада: Украина тимер юл эшчеләренең забастовкасы», «Төрле хәбәрләр», «Москва һәм Петербургта», «Казанда», «Башкортстанда», «Мөселман гаскәриләр фиркасе», «Яуропа сугышы», «Уфа мөселманнарында мәгариф эшләре», «Бәләбәй хәбәрләре», «Әдәбият» кебек мәкалә һәм рубрикалар бар. Газета берничә мәкаләне Уфада чыгучы «Башкорт хөкүмәтенең теле», «Яңа хәят», «Слово» исемле газеталардан күчергән. Әлеге рубрика һәм мәкалә исемнәреннән күренгәнчә, газета төп мәгълүмат чыганагы буларак татар, башкорт халкын Россия, Казан-Уфа һәм Бәләбәй төбәге яңалыклары белән таныштырып барган, теге яки бу иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга үзенең мөнәсәбәтен белдергән.

Игътибарыгызга газета мәкаләләреннән кыскартып берничә цитата китерәбез:

«Большевиклар вакытында таратылган вә бәгъзы бер әгъзалары хәбес ителгән (кулга алынган) башкорт хөкүмәте яңадан аякка бастырылып, тагы эшкә кереште. Октябрьгә кадәр булган вазгыяте белән хәзерге вазгыяте арасында бу хөкүмәтнең байтак аермасы бар. Ачык кына әйткәндә, Октябрь ихтилялына кадәр корылган планнар хәзер бу хөкүмәт тарафыннан акрынлап вөҗүдкә чыгарыла башлады: яхшы куәткә малик (ия) милли гаскәр төзелде вә Башкортстанның автономный бер идарә булганын өч собрание әгъзалар комитеты тасдыйк кылды вә шуның нәтиҗәсендә Башкортстан хөкүмәте үзенең дахили (эчке) эшләрен мөстәкыйль карар юлына әзерлек ясый башлады. Болар зур муаффәкыятьләр (уңышлар). Татар бу хәрәкәткә ничек карарга тиеш? Кечкенә Башкортстан[5] *үзенең мохитенә кергән мөселманнарны, башкорт*

[3] Бу юллар И.Рәмиевнең китабыннан китерелде. Алар газетаның безгә мәгълүма булмаган 8 нче санында басылган.

[4] Гайнанов Р.Р., Мәрданов Р.Ф., Шәкүров Ф.Н. Татар вакытлы матбугаты (1905-1924): библиографик күрсәткеч. — Казан: Рухият, 1999. — Б.45-46.

[5] Кечкенә Башкортстан — 1917 елның 15 ноябрендә игълан ителә, 1918 елның гыйнварында Кече Башкортстан исемен ала. Проектының авторы — Әхмәтзәки Вәлиди.

һәм татарына карамый, идарә кыла башлау белән без дә, аның мохитенә кермәгән мөселманнар да[6]*, мәзкүр хөкүмәткә кулдан килгән ярдәмне кылырга, аның халык арасындагы дәрәҗә вә игътибарын югалтмаска тырышырга тиешбез. Башкортларның хәрәкәтен көлеп кенә күзәтү никадәр тиешсез эш булса, аларга аяк чалу,* ***яңадан башкорт-татар низагын тудырырга тырышу да зур ялгышлык, болай да тар калган халыкны аергалаштыру вә кыйммәтле вакытларны бушка җибәрү булачактыр.*** *Башкалардан элек без, шул Кечкенә Башкортстан мохитенә кермәгән төрек-татар балалары, андагы башкорт кардәшләребезгә һәм мәгънәви, һәм дә матди ярдәмнән кире тормаска бурычлыбыз. Күзебездән үтеп киткән һәм үтеп тормакта булган вакыйгалардан алган сабагыбыз безгә инде аңлашырга кушалар. Шуңа күрә дә Кечкенә Башкортстанның автономиясенә аяк чалмыйча, кулдан килгән һәр ярдәмне күрсәтеп хәрәкәт итү — безнең тарихи бурычыбыз. Бу юл Башкортстан өчен дә, безнең өчен дә файдалы юл булачак».*

Башкортлык хәрәкәте.

«Немецләр бөтен Кавказны өч мөстәкыйль мәмләкәткә бүлмәк булалар. Гаребтә Гөрҗистан булып, мәркәзе — Тифлис, шәрыктә ***Татарстан*** *булып, мәркәзе Баку булачак. Уртада төзеләчәк Әрмәнстанга пайтәхет билгеләмәгәннәр әле».*

Кавказ хәлләре.

«Казандагы бөтен алтын запасы Самарага җибәрелеп бетерелгән. Шул Самарага җибәрелгән алтынның кыйммәте хәзерге акча белән 6 ярым миллиард сум икән. Шул ук Казаннан Самарага йөз миллион сумлык кәгазь акча һәм башкача бик күп кыйммәтле нәрсәләр күчерелгән».

Казанда.

«Башкортстан хөкүмәтенең хәрби шөгъбәсе нәшрияты уларак рәсми һәм гайре рәсми кыйсемнәрдән гыйбарәт «Башкорт хөкүмәтенең теле» гәзитәсе чыгарыла башлаган. Мәсъүл (җаваплы) мөхәррире — ***Габдрахман әфәнде Фәхреддинов***[7]*. Гәзитә тулы һәм матур чыккан. Башкорт хөкүмәтенә күптәннән шундый бер тулы гәзитә кирәк иде. Бу гәзитә шуны тутырса кирәк».*

Яңа гәзитә.

«Эстәрлетамакта мөселман ротасы ясалып, комендантлыкка подпоручик Ишмурзин тәгаен кылынды. Верхнеурал өязендәге типтәрләр аерым гаскәри фиркаләр төзи башлаганнар, Орский өязендәге башкортлар фиркаләр төзегән».

Мөселман гаскәри фиркаләр.

«Уфа татар гимназиясе идарәсе кабул итү имтиханнарын яңа стиль белән 1, 2 сентябрьгә билгеләгән. Бу ел гимназиягә керергә теләп гариза бирүчеләр ифрат күп булса да, гимназия бинасы тарлык иткәнгә мөгайян (билгеләнгән) микъдар-

[6] Бәләбәй өязе 1922 елда Олы Башкортстанга кертелә.

[7] Габдрахман әфәнде Фәхреддин — башкорт хөкүмәтенең теле турындагы газетаны чыгаручы Габдрахман — Ризаэддин Фәхреддиннең беренче улы, 1918 елның башына кадәр «Вакыт» газетасының җаваплы сәркатибе.

Кече Башкортстан Республикасының картасы

дан артык укучы кабул итмәс. Бу ел гимназия идарәсе икенче (хәзерлек) белән беренче (төп) сыйныфларны параллель сыйныфлар итәргә тиеш тапкан».

Уфа татар гимназиясе.

«Мөселманнар өчен ачылып та 17-18 нче елларда ике мәртәбә татарча һәм русча укытучылар җитештереп чыгарган Златоуст каласындагы тәгълим-тәрбия курсы бу ел (18нче уку елы башыннан) семинариягә (дарелмөгаллимин[8] вә дарелмөгаллиматка[9]) әйләндерелде».

Златоусттан язалар.

«24 нче августта татарча театр булып, тамашага «Мосыйбәте Фәхреддин» куелды. Саф файда фәкыйрь студентлар файдасына тәгаен кылынган».

Бәләбәй хәбәрләре: татарча театр.

Дөрес, газетаның рухын, аның эчтәлеген берникадәр ачар өчен китерелгән әлеге юллар аерым мәкаләләрдән өзекләр генә. Күрүебезчә, «Берек» газетасы (аның башка саннары да табыла калса) гражданнар сугышы чоры, 1918 еллардагы төбәк иҗтимагый-сәяси вазгыятен өйрәнү өчен әһәмиятле чыганак.

Әлеге газетаны чыгарган шәхесләр билгесез диярлек. Газетада мәсьүл (җаваплы) мөхәррир — «комиссия» дип, шулай ук Бәләбәй земствосы нәшриятының «Берек» идарәсе булганлыгы да күрсәтелгән. Мәкалә авторларыннан «Әхнәф» исеме генә билгеле. Газетаны чыгару эшенә татарлар арасында аң-гыйлем тарату, кооператив ширкәтләре оештыруда зур көч куйган земство управасы рәисе Гомәр Еникиевнең катнашканлыгы турында да уйларга нигез бар.

[8] Дарелмөгаллимин — ирләрдән укытучылар хәзерли торган уку йорты.

[9] Дарелмөгаллимат — хатын-кызлардан укытучылар хәзерли торган уку йорты.

Зариф Мөэминовның нәсел-нәсәбе

Үткәннән кайткан китап



21 сентябрьдә Мөслимнең мәдәният йортында фольклорчы, мөгаллим, әдип, халык арасында «әкиятче бабай» һәм «шәкерт абзый» булып танылган Зариф Мөэминовның (Әхмәтзариф Әхмәтлатыйф улы Мөэминов,1893-1966) «Маҗара» китабын тәкъдим итү кичәсе булды. «Безнең мирас» укучыларына әдип исеме журналда басылган «Мәрьям» (№2-3, 2014 ел) һәм «Солдат йөрәге» (№7-8-9, 2015 ел) әсәрләре һәм шул әсәрләрне басмабызга әзерләп биргән язучы-галим Факил Сафинның кереш мәкаләләре аша яхшы таныш. «Маҗара» китабы Мөслим муниципаль районы башлыгы Рамил Хәмзә улы Муллин булышлыгы һәм «Чаллы икмәге» компаниясе генераль директоры Рафаэль Сөләйман улы Юнысовның матди ярдәме белән дөнья күрде.

Өч сәгать барган кичәдә әдипнең әсәрләреннән өзекләр, җырлар яңгырады, Казан, Түбән Кама, Әлмәт, Азнакай һәм Чаллы калаларыннан кайткан, шулай ук Мөслимнең үзендә яшәп иҗат иткән әһле каләмнәр, аерым алганда, Р.Вәлиев, Р.Гаташ, Ф.Садриев, В.Имамов, Ф.Сафин, Э.Шәрифуллина, Ш.Җиһангирова, К.Кәрим, Д.Салихов, Л.Лерон, И.Гыйләҗев, Р.Корбан, М.Әхмәтҗанов, Ф.Абдуллин, Р.Хәбибуллина, М.Әхмәтшина, З.Захарова, галимнәр Дания һәм Илдус Заһидуллиннар, журналистлар Р.Минһаж, Н.Гыйбадуллина һәм әдипнең туганнары чыгыш ясады. ■

Фәрит Галиәскәров һәм Мөнирә Сәгыйдуллина фотолары

ИСКЕРМӘГӘН ИСКЕР

Мөнирә Сәгыйдуллина

(Тарихны торгызуга юнәлтелгән җыеннан фоторепортажны тулырак www.beznenmiras.ru сайтыннан карый аласыз)

Бөек Себер ханлыгының башкаласы булган, үзенең чиксез гүзәллеге, халкының батырлыгы белән дан тоткан борынгы Искер шәһәренең нигезен катлам-катлам тарих тузаннары каплап, эзләре бөтенләй юкка чыккан. Кайчандыр үзәк булып торган әлеге шәһәрнең исеме дә халык арасында онытыла башлаган иде.

Себер ханы тирмәсендә



Ходайның тәкъдире шулай булганмы, Иртыш елгасының ярында яңадан Искер калка башлады, ел саен оныкларын җыеп кочагына кыса, себер татарларына Күчем ханның варислары икәнлеген искәртеп, күңелләрендә горурлык хисләрен уятырга көч-дәрт биреп тора. Менә инде ун ел дәвамында Себер җирлегендә Искерне торгызу буенча көрәш бара. Нигез урынын, чынбарлык тарихны җәмәгатьчелеккә кайтару, себер татарларын милләт буларак таныту эшләре Себер киңлекләрендәге төбәкләрдә яшәүче татарларны туплап, берләштерә башлады. Ел саен Искергә Төмән, Новосибирск, Омск, хәтта Иркутск өлкәләреннән милләтпәрвәр кардәшләребез, якташларыбыз, фикердәшләребез җыела. Нәтиҗәләре авыз тутырып мактанырлык булмаса да, борынгы шәһәр нигезендә тарихи мәчеткә нигез салынды, шәехләр күмелгән Астанага чардуган куелды, этнографик музей ишекләрен ачты. Ел саен Себер ханлыгының бәйсезлеге өчен һәлак булган бабаларыбыз рухына багышлап хәтем ашы уздырыла.

Искерне торгызу максатын тормышка ашыру нияте белән инде сигезенче ел Тубыл шәһәрендә һәм районында «Искер-җыен» дип исемләнгән себер татарларының тарихи-мәдәни мирасы халыкара фестивале уздырыла. Чараның төп оештыручылары: Төмән өлкәсенең

Зәйтүнә Тычинских һәм Луиза Шәмсетдинова

«Мирас» төбәк татар иҗтимагый оешмасы һәм Себер татарларының тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү үзәге.

7-9 августта уздырылган биелгы фестивальдә Төмән өлкәсе районнарыннан һәм шәһәрләреннән, Иркутск өлкәсеннән, Новосибирск, Омск, Казан шәһәрләреннән, Казакъстан Республикасының Семей шәһәреннән кунаклар катнашты.

Фестиваль үзе берничә чараны колачлый. Беренче көнне Тубыл шәһәрендә «Искернең тарихи язмышы» исемле фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Конференциянең пленар утырышында төп темага карата берничә галим чыгыш ясады. Этнолог, тарих фәннәре докторы **Дамир Исхаков**; Татарстан Фәннәр академиясе каршындагы Археология институтының өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы **Искәндәр Измайлов**; профессор, филология фәннәре докторы **Хәнисә Алишина**; җирле фольклорчы, филология фәннәре кандидаты **Луиза Сурметова**, филология фәннәре кандидатлары **Нәсия Уразова** һәм **Максим Сәгыйдуллинның** чыгышлары аеруча зур кызыксыну уятты.

Кайнар-кискен чыгышларга, җитди бәхәсләргә карамастан, конференция эше дустанә мөнәсәбәттә тәмамланды. «Мирас» оешмасы җитәкчесе **Луиза Шәмсетдинова**, фестивальнең беренче көненнән актив катнашып, һәрвакыт ярдәм кулы сузып торган Бөтендөнья татар конгрессы Бюросы әгъзасы, БТК БКның рәсми делегациясе җитәкчесе Дамир Исхаковка истәлеккә кылыч бүләк итте. Шулай ук «Мирас» оешмасы әгъзасы, Себер татарларының тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү үзәге җитәкчесе **Зәйтүнә Тычинскихка** да истәлекле бүләк тапшырылды.

Пленар һәм сессион утырыш арасында әле күптән түгел дөнья күргән «Себер татарларының тарихы һәм мәдәнияте» исемле китапны тәкъдим итү булды. Китап басмага Себер галимнәре тарафыннан әзерләнеп, Казанда редакцияләнә һәм нәшер ителә. *«Бу китап кыска вакытта әзерләнде*, — диде үзенең чыгышында басманың фәнни мөхәррире Дамир Исхаков. — *Ул күбрәк укытучылар өчен каралган. Без Тубылга 200 данә китап китердек һәм бу китап татарлар күпләп*

Илдус Насыйбуллин белән Хәсәнә Баязитова (Салехард шәһәре)

Искәндәр Измайлов һәм Дамир Исхаков

Конференция кунаклары Төмән өлкәсенең Диния нәзарәте нәшер иткән «Хикмәт» газетасы белән таныша. Беренче рәттә (уртада): «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Марат Закир һәм Рәдиф Сәгъди

яшәгән районнарда урнашкан һәрбер мәктәп китапханәсендә булырга тиеш». Җыентыкта фәнни хезмәтләре урын алган авторлар — **Александр Адамов**, Зәйтүнә Тычинских, **Равилә Кутумова** да фикерләре белән уртаклаштылар. Сүз барышында тулырак итеп икенче китапның укучылар өчен дәреслек буларак әзерләнүе турында да хәбәр ителде.

Фестивальнең икенче көне табигать кочагында, Себер ханлыгының башкаласы булган борынгы Искер каласы урынында узды.

Искер җирлегенә төрле төбәкләрдән җыелган кунаклар белән беррәттән яңгыр да ияреп килде. Көн дәвамында ул үзенең барлыгын һәм монда хуҗа икәнлеген искәртеп торса да, фестиваль программасы үз эшен дәвам итте.

Кунаклар Искердәге музей белән таныша торды. Монда исә Себер ханлыгы чорыннан башлап бүгенге көнгә кадәр кагылышлы экспонатлар тупланган. Шулар арасында игътибарны җәлеп иткәне — кылыч. Оештыручылар фикере буенча, бу кылыч — Күчем-хан гаскәре коралы. Хәтта әлеге кылычның үрнәк буларак ясалган күчерелмәсе дә музейда урын алган.

Кунакларның кайберләре Күчем ханның тирмәсе торган, гаиләсе һәм халкы яшәгән урынны күзләргә Иртыш ярына юнәлде. Елганың көчле агымсуы, текә ярларны юа-юа, Искернең тарихи нигезен тәшкил итүче туфракларны җимереп, бөтенләйгә җир йөзеннән умырып билгесезлеккә алып китә бара. Дәүләт тарафыннан сакланырга тиешле булса да, бу урында ярларны җимерелүдән туктату буенча әлегә кадәр бернинди дә чаралар күрелми. Бу исә дәүләт органнарының табигать ярдәме белән борынгы татар дәүләте эзләрен, бөек Себер ханлыгының соңгы гәрәбәләрен җир йөзеннән юып мәңгелеккә озатып, себер татарлары язмышының соңгы тарих битләрен күрәләтә көчләп юкка чыгаруга тиң.

Искернең төп нигезендә казу эшләре алып барыла. Күптән түгел монда җирле археологлар каберлеккә тап була. Бу яңалык Казан галиме Искәндәр Измайловны шулкадәр кызыктырды, яңгыр явып торуга карамастан, җирле археолог Александр Адамовка ияреп әлеге урынны карап кайтты. Галимнәрнең фикеренчә, табылган каберлек Себер ханлыгы чорына карый, әмма кем каберлеге икәнен исбатлар өчен казу эшләре алып бару зарур.

Һаваның көйсезләнеп торуына карамастан, программага кертелгән 74 концерт номерының барысы да жюри карамагыннан узып, иң яхшы дип саналганнары Гала-концертка тәкъдим ителде.

Концерт программасына бер-бер артлы татарча көрәш, ат чабышы, гер ыргыту кебек спорт ярышлары үрелеп барды. Көрәш буенча беренчелекне Вагай районының Тукыз авылыннан Данил Фаттаков яуласа, гер ыргыту буенча «Әхтәмушки» төркеме җырчысы Рөстәм Итанәковка тиң табылмады.

Җыр-биюләре, ярыш-узышлары, яңа ачышлары белән фестивальнең икенче көне дә шулай узып китте.

Халыкара фестиваль Тубылның «Синтез» концертлар залында уздырылган Гала-концерт белән тәмамланды. Тамашачылар исә яратып өлгергән җырчыларын, Күчем хан белән Сүзге ханбикәне кайнар алкышлар белән каршы алды. Өч көн дәвамында барган чараның кунакларына да сүз бирелде. Аларның һәрберсе үз чыгышында «Искер-җыены»н оештыруга көч куючы шәхесләргә, ярдәм итүче меценатларга, сәнгать әһелләренә рәхмәт сүзләре әйтеп бүләкләр тапшырды. «Мирас» оешмасы җитәкчесе Луиза Шәмсетдиновага һәм Искерне торгызучы төп инвестор Дамир Ибраһимовка Бөтендөнья татар конгрессының «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләр өчен» медале тапшырылды.

Бер-бер артлы кызыклы чыгыш-

Әхтәм Фәйзиев чыгыш ясый

лар дәвам итте. Себер тамашачысы Хәсән Хучашевның һәм Иркутск өлкәсеннән килгән искиткеч скрипкачы Әхтәм Фәйзиевның чыгышларын түземсезлек белән көтте. Хәсәннең йөрәк түреннән агылган моңы һәр тамашачының җанына бал да май булып ятты. Бәрхет тавыш, киң сулыш, мөлаем йөз — барысы да үз урынында! Татар моңнарын скрипкада яңгыраткан Әхтәм Фәйзиевка сокланмаган тамашачы залда калмагандыр. Концерт барышында Әхтәмне берничә тапкыр сәхнәгә чакырып скрипка кылларын иркенләп сузарга мөмкинлек тудырдылар. Беренчедән, ул ерактан килгән кунак, ә себер татарлары бик кунакчыл. Икенчедән, борын-борыннан себер татарларында скрипка иң популяр, хәтта ки милли уен коралы булуы белән билгеле, һәр авылның скрипкада уйнаучы үз осталары булган.

Гомумән, чыгыш ясаучыларның һәркайсы мактауга, кайнар алкышларга һәм әлбәттә бүләкләргә лаек. «Мирас» оешмасы җитәкчесе Луиза Шәмсетдинова һәркайсына диярлек истәлекле бүләкләр тапшырды һәм берничә көн рәттән барган чараларны оештыруда ярдәм иткән химаячеләргә, галимнәргә, фикердәшләренә олы рәхмәтләрен белдерде.

Шулай итеп, быелгы «Искер-җыен»ы тагын бер елга кунаклар белән саубуллашты. Җыенда катнашучыларның һәркайсына үз һөнәри өлкәсенә кагылышлы бурычлар билгеләнде. Галимнәр себер татарлары телен саклап калу, тарихны, сәнгатьне өйрәнү, мирасны саклау буенча эш алып барса, төп оештыручылар исә Искерне торгызу, ярларын ныгыту өчен көрәшен дәвам итәчәк.

Казан-Тубыл-Казан ■

«Дуслык» һәм «Сандугач»!

Иркутск өлкәсенең Бохан районы Хохорск авылында эшләп килүче ансамбльләр болар. «Дуслык» — фольклор ансамбле, ә «Сандугач» балалар өчен эшли. Һәр икесе белән дә **Фәридә Зиннур кызы Фәйзрахманова** җитәкчелек итә. Уңган-булган, чибәр вә мөлаем бу яшь ханым әле Көнчыгыш Себер дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясендә дә белем алырга өлгерә.

Хохорск муниципаль җирлегенә җиде авыл керә: Хохорск үзе, Нововоскресенка, Русиновка, Ижилка, Харатиргән, Шунта һәм Херетин авыллары. 41 мең гектар җирдә 2442 (7,65% — татарлар) кеше яши.

2015 ел Хохорскида татар мәдәнияты елы дип игълан ителгән. Каз каурые, каз өмәсе бәйрәмнәре, «Себер йолдызлары», «Алтын кәләпүш», «Ангара», «Җыр фольклоры» һәм «Алмазные грани» исемле конкурс-фестивальләр үткәреп, гөр килеп, бердәм булып яши биредәге милләттәшләребез!

Хохорск авылы күренеше

КАЗАКЪСТАНГА СӘФӘРЛӘРЕМ

Миннәхмәт Кашапов,
РСФСРның атказанган экономисты

Республикабызның Сарман төбәгендә КПСС райкомының беренче секретаре булып эшләгән чорымда 1972 һәм 1975 елларда булган көчле корылык турында китапларымда язган идем инде. Бөртекле, кузаклы культураларны урып-җыю эшләре август башында ук тәмамланды, уңыш исә бер гектардан 6-7 центнер гына булды... Шул ук җирләрдә 1976 елда һәр гектардан 20 центнер – рекордлы уңыш җыеп алган идек. Табигать шартлары төрлечә була шул...

1976 ел азагында Казанга күчеп эшли башладым... Ел йомгаклары буенча узган тантаналы җыелышта КПСС Татарстан Өлкә Комитетының Беренче секретаре **Фикрәт Әхмәтҗан** улы **Табиев** берничә районны мактап сөйләде. Алдынгы районнар сафында безнең Сарман районы да бар иде.

1978 ел исә, моңа кадәр булмаганча, явымлы иде. Бөртекле культуралар шактый югары уңыш вәгъдә итеп, өлгереп җиттеләр. Урып-җыю эшләре башланды. Август ае яңгырлары көз көннәрендә дә дәвам итте...

Дәүләтнең ашлык кабул итү пунктларында бөртекле ашлык киптерү машиналары көн-төн эшләп тә, җитешә алмыйлар иде. 1979-80 елларда республикада уртача гына уңыш җыеп алдылар. 1981 елда янә бик каты корылык башланды. Яшелчә, кукуруз басуларында, сугарулы көтүлекләрдә су сиптерү агрегатлары тәүлек буе эш режимына күчте. Терлекләргә кышка яфрак-азык, кычыткан әзерләүгә хәтта шәһәр халкы да җәлеп ителде.

Бөртекле культуралар, үсә алмыйча, саргаеп кибә башлады. Иң куркынычы – терлекләргә хәтта салам да җитмәве көн кебек ачык иде..

1981 ел... Авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләү һәм сыйфаты буенча Дәүләт инспекциясендә җитәкченең беренче урынбасары булып эшли идем. КПСС Өлкә Комитетының Беренче секретаре **Рәшит Муса улы Мусин**, өч бригада туплап, илебезнең башка төбәкләренә барып, салам әзерләргә боерык бирде.

Татарстан АССР Министрлар Советы рәисе урынбасары **Мансур Хәсән улы Хәсәнов** белән мине Казакъстанга салам әзерләргә җибәрергә карар кабул ителгән икән.

Шундый ук төркемнәр Краснодар краена һәм Оренбург өлкәсенә дә юл алды.

Мансур Хәсәнович белән без – яшьтәшләр, тиз генә җыенып, Ка-

Мансур Хәсәнов. 1980 нче еллар

Миннәхмәт Кашапов. 1980 нче еллар

закъстан башкаласы Алматы (Алма-Ата) шәһәренә очтык. Безне анда Мансур кордашның коллегасы каршы алды һәм кунакханәгә урнаштырды. Шунда ук җиңелчә генә ашап, чәй эчеп алдык. Дөя сөтеннән эшләнгән кымызның тәмен дә беренче мәртәбә

Динмөхәммәт Кунаев (уртада) иген басуында. 1970 нче еллар

шунда татып карадык. Бия сөтеннән әзерләнгән кымызга караганда йомшаграк, татлырак тоелды ул безгә.

«Сезне иртәгә көндезге сәгать унбердә иптәш **Кунаев Динмөхәммәт Әхмәтович** көтә», — дип, саубуллашып чыгып китте безне каршы алган җитәкче.

Икенче көнне күрсәтелгән вакытта Казакъстан Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының Беренче секретаре бүлмәсенә кердек.

Чал чәчле, озын таза гәүдәле чибәр кеше безнең каршыга килеп, елмаеп күреште.

Урынына барып утыргач, исемнәребезне сорады. Югыйсә, анысын гына белгәндер инде ул.

– Мансур Хәсәнов.

– Ә сезнеке?

– Миннәхмәт Кашапов.

– Минем атамны да шулай атаганнар — Миннәхмәт! – дип куйды ул татарча.

– Сез татарча да беләсез икән!

– Гаиләбездә өч телдә сөйләшәбез: русча, казакъча һәм татарча. Хатыным Зөһрә Шәриповна – татар кызы.

– Татарстаннанмы әллә?

– Юк, ул Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәреннән.

– Фикрәт Әхмәтҗанович Табиев[1] та Касыйм ягыннан лабаса!

– Фикрәт белән минем хатыным – якташлар. Без алар белән, гаилә дуслары булып, очрашкалап яшибез.

Инде төп йомышыбызны әйттек.

– Динмөхәммәт Әхмәтович, безнең Татарстанда бик каты корылык булды. Терлекләргә хәтта кышлату чорына салам да җитмәячәк. Салам белән ярдәм итә алсагыз, яхшы булыр иде,– дип Мансур Хәсәнович үтенечебезне җиткерде.

– Ике көн элек кенә башкортлар да килгәннәр иде салам сорап, аларга бераз иске салам бирдек. Сезгә дә бирмичә булмас инде... Хәзергә 5 мең тонна иске саламны үзегезгә якынрак Кустанай өлкәсендә әзерли башларсыз. Тиздән урып-җыю эшләренә керешкәч, яңа саламны да урыннарда сөйләшеп, хәл кадәри алырсыз, – дип безне сөендерде.

– Кичә Мәскәүдән **Михаил** да шалтыраткан иде әле салам сорап, — дип куйды ул аннары РСФСР Министрлар Советы Рәисе **Соломенцевны**

[1] Ф.Ә.Табиев бу вакытта СССРның Әфганстан Демократик Республикасындагы Гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе вазифасын башкара иде. — *Ред.*

исеме белән генә атап. – Россия Федерациясендәге кайбер башка өлкәләрдә дә корылык булган икән, аларга күп кирәк, барысына да биреп булмый инде, – дип аңлатты хуҗа хәлне.

Без, рәхмәтләр әйтеп, китәргә җыенганда гына ул:

– Мин Рәшиткә, бик яхшы баянистыгызга фатир алырга ярдәм итегез әле, дип телефоннан әйткән идем. Гозеремне үтәдеме икән? – дип сорап куйды. Рәшитнең КПСС Татарстан Өлкә Комитетының Беренче секретаре Мусин икәнен аңлап алдык.

– Төгәл генә әйтә алмыйм, кайткач та ачыкларммын! – дип җавап бирде Мансур Хәсәнович.

Динмөхәммәт аганың үз республикасындагы халыкның тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту өчен тырышып эшләвен белә идек инде. Танылган баянчыбызны фатирлы итү өчен, борчылып, Рәшит Мусинга шылтыратуы – аның киң күңелле, гадел, кешелекле булуы — соклану катыш гаҗәпләндерде безне. Баянчының исем-фамилиясен язмыйм. Бәлки, ул үзенең хезмәте, дәрәҗәсе белән алгандыр фатирын. Шөкер, Казаныбыз, республикабызда сәнгать, мәдәният хезмәткәрләре ихтирамга, хөрмәткә лаек шәхесләр булып яши һәм эшли.

...Динмөхәммәт агага рәхмәтләр әйтеп, чыгарга кузгалдык. Ул безне ишеккә кадәр озатып куйды. Икенче көнне Кустанай шәһәренә очтык, җитәкчеләре белән таныштык – кайсы районнарда, хуҗалыкларда салам хәзерли башларга мөмкинлеген ачыкладык. Казакъстан далаларында, авылларында йөрү өчен миңа җиңел машина – «УАЗ» беркетелгән иде.

Зөһрә һәм Динмөхәммәт Кунаевлар. 1984 ел

Мансур Хәсәнович кайтып китте. Мин Татарстаннан килгән звеноларны каршылыйм, совхозларга урнаштырам. Тиздән салам пресслау эшенә дә керештек.

Динмөхәммәт ага[2] 1911 ел азагында туган, төрле җаваплы эшләр башкарып, зур тәҗрибә туплаган. Казакъстан Республикасы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының Беренче секретаре булып 1964 елның декабрендә эшли башлаган. 1964-1970 елларда чирәм җирләрне эшкәртеп, бөртекле культураларны, бигрәк тә сыйфатлы язгы бодай чәчү мәйданнарын, аның уңышын һәм тулаем җыемын арттыруда зур хезмәт куйган дәрәҗәле олуг җитәкче

[2] Динмөхәммәт Миннәхмәт улы Кунаев, рәсми мәгълүматлар буенча, казакъ милләтенә нисбәтләнә. Вәләкин уйгыр әдибе Абдекәрим Ганиев Кунаевның чыгышы белән татар булуын, карьера үсеше өчен генә паспортта милләтен казакъ итеп үзгәртүе хакында яза. Партия эшлеклесе Сатыпалды Тотанов та үзенең «Өткен өмір өткелдері» («Үткән гомер үткелләре») исемле автобиографик китабында ошбу фаразны ныгыта. — *Ред.*

ул! Чирәм җирләрне үзләштерү елларында 550 яңа совхоз оештырылган. Совхозлар – зур! Салам әзерләгәндә 50-60 мең гектар биләмәле совхозларда булырга да туры килде миңа.

Иксез-чиксез, урмансыз, сусыз тигез дала, гасырлардан-гасырларга көтүлек булган чирәм җирләр… Казакъстанда ел әйләнәсендә явым-төшем бик аз. Шуны исәпкә алып, аларда кулланыла торган агрочаралар белән дә танышыйк әле. Дым саклауга аеруча игътибар бирәләр. Мин, агроном буларак, агротехникалары белән дә кызыксындым. Алар туфракны көздән туңга сөрмиләр. Урып-җыю эшләреннән соң калган камыл туфракны җил-давылдан, тузан өермәләреннән саклый, ә кыш көннәрендә кар тоту өчен ярдәм итә икән. Яз көне туфракны эшкәртмичә, махсус камыл чәчкечләре белән чәчәләр икән язгы бодайны. Камыл күләгәсендә бодай тишелә, көчле тамырларын, өстәмә сабакларын җибәреп үсә, ныгый, җил-давылларга бирешмичә җитешә. Урып-җыю эшләрен комбайннар белән турыдан-туры урып суктыралар; аерым урып, тиземнәрдән җыеп суктыру ише артык эшләрне башкармыйлар. Чирәм җирләрдә яңа технология белән эшләү нәтиҗәсендә, 1966-1970 елларда Казакъстанда бодай җитештерү, алдагы бишьеллык белән чагыштырганда, 1,6 мәртәбә арткан.

Казакъстанда урып җыю эшләре август аенда ук бик оешкан формада – 25 көндә тәмамлана. Табигатьнең әллә нинди хикмәтләре була бит! Анда август аенда беркайчан да яңгыр яумый. Махсус заказ буенча диярсең бу могҗизаны! Югары сыйфатлы коры бодай элеваторларга, складларга вакытында кереп урнаша… Салам хәзерләүдә звеноларыбыз яхшы гына эшли башлагач, 7-8 көннән соң мин дә кайттым Казанга, үземнең төп вазифаларны да үтәргә кирәк бит әле. Атна-ун көн узгач, Мансур Хәсәнович миңа телефоннан фикерен җиткерә.

– Миннәхмәт, Кустанайда эшләр бик әкрен кыймылдый башлады, янә барып, ашыктыру чараларын күрергә кирәк иде! – ди ул.

Мин барып, тагын 7-8 көн эшләп кайтам. Әзерләнгән саламнарны безнең көньяк-көнчыгыш районнары машиналар белән ташый да башладылар инде.

Ә шулай да поезд белән вагоннарга төяп ташу уңайлырак иде. Иң беренче салам вагоннары Татарстаныбызның төньякта урнашкан Арча, Саба, Кукмара кебек районнарына кайтты. Вагоннар күп кирәк, фактта исә бик аз бирелә. Мин, өстәмә вагоннар сорап, Целиноградта урнашкан тимер юл идарәсенә дә барып кайттым. Аның җитәкчесе булып безнең Тәтеш районыннан татар егете эшли икән.

– Ярдәм итәргә тырышырбыз, хәзер вагоннар күп кирәклеген аңлыйбыз, – дип әйтеп куйды ул.

Целиноград шәһәре хәзер Астана шәһәренә – Казакъстан Республикасының башкаласына әверелде инде. Алматы шәһәре исә Казакъстанның көньяк читендә иде бит.

1981 елда җәй-көз айларында мин биш мәртәбә Кустанай өлкәсенә барып, салам әзерләү һәм ташу эшләре буенча атна-ун көн эшләп кайта идем… Нәтиҗәдә, Казакъстаннан Татарстаныбыз хуҗалыкларына 120 мең тонна яхшы сыйфатлы салам кайтты.

…Шул елның азагында, 70 яше тулган көннәрдә, Динмөхәммәт Әхмәт улы Кунаевка Социалистик Хезмәт Героеның икенче Алтын Йолдызы һәм Ленин ордены тапшырылды. Аның техник фәннәр докторы, академик дигән, фәнни эшләре өчен бирелгән дәрәҗәле вә лаеклы исемнәре дә бар иде. Казакъстан халкы аны ярата һәм хөрмәт итә иде. Без дә аңа бик рәхмәтле булдык! ■

Редакциядән: Журналыбызның актив авторы **Миннәхмәт Кашафетдин улы Кашаповка** 30 октябрьдә 85 яшь тула. Аны шушы күркәм гомер бәйрәме белән тәбрик итәбез!

Б.Урманче музее күренеше

Күл-Черкендә – Урманче музее

Буяулар сөйләшә башлый.
Пумалага ым бирсәң...
Ташларга да җан иңә,
Урманче кулы тисә, — дип язган иде Шагыйрь.

Тылсымчы-рәссам һәм сынчы Бакый Идрис улы Урманче 1897 елның 23 февралендә Казан губернасының Тәтеш өязе Күл-Черкен авылында (хәзер Буа районына карый) дөньяга килә.

Буалылар атаклы шәхесләрен онытмый, аларның мирасын барлауда һәм ул мирасны халыкка җиткерүдә зур тырышлык куя. Шундый күркәм эшнәтиҗәләрнең берсе — Күл-Черкен авылында Бакый Урманчега ачылган музей (2012).

«ТАТМЕДИА» АҖнә караган журналларның баш мөхәррирләре узган ай башында Буа районында эшлекле сәфәрдә булып кайтты. Форсаттан файдаланып, алар Б.Урманче музеен карап, музейдагы кадерле истәлекядкярләр белән танышты.

Фоторепортаж www.beznenmiras.ru сайтында тулырак бирелә. ■

Б.Урманченың үз сыны

Б.Урманче музее директоры Илдия Гыйниятуллина

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИННЕҢ МЕМОРИАЛЬ МУЗЕЕНА 20 ЕЛ

ИҢ ГҮЗӘЛ ГАЙРӘТ...

Диләрә Гыймранова

(Ризаэддин Фәхреддиннең балаларына язган хатлары)

1995 елның 25 маенда Әлмәт районы Кичүчат авылында Р.Фәхреддиннең мемориаль музее ачылды. Шул көннән «Татнефть» ААҖнең «Елховнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе көче белән галим туып үскән нигездә төзелгән һәм җиһазландырылган музей авылга нур сибеп үзенә кунакка дәшә башлады.

Музей күренешләре белән www.beznenmiras.ru сайтыннан таныша аласыз.

Биредә Р.Фәхреддиннең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү, якын туганнарын барлау, мирасын туплау буенча зур эш алып барыла. Музей фондында 4300 берәмлек экспонат бар. Шулар арасында галим үзе исән вакытта дөнья күргән «Асар», «Гаилә», «Нәсыйхәт», «Тәрбияле хатын», «Мәшһүр хатыннар», «Җәвәмигуль кәлим шәрхе», «Шәкертлек әдәбе», «Рихләтел-Мәрҗани», «Моталлага», «Гакыйдә» кебек тирән эчтәлекле әсәрләр, Р.Фәхреддиннең һәм якыннарының кулъязма мирасы, төрле еллардагы «Шура» журналы басмалары, төп нөсхәдәге фотодокументлар һәм шәхси җиһазлары да күргәзмәләр залында урын алды. Р.Фәхреддиннең мемориаль музей фондын тулыландыруга галимнең кызы Әсма Шәрәф, оныгы Арслан Шәрәф, якын туганнары Альмира Әминова, Рөстәм һәм Фәрид Фәхреддиновлар нык ярдәм итте.

Музей фондының күп өлешен Р.Фәхреддиннең кызлары Зәйнәп Фәхреддинова белән Әсма Шәрәф саклаган гаилә архивы документлары алып тора. Гаиләдә фотоларга һәм хатларга карата аеруча сакчыл караш тәрбияләнгән, бәлки шуңа күрә бу кульязмалар хәзерге көнгә кадәр саклангандыр.

Р.Фәхреддиннең гомеренең соңгы елларында үз балаларына язган хатлары да үгет-нәсыйхәтләргә бик бай. Бар яктан камиллеккә омтылган галим балаларына да камил тәрбия бирү өчен тырышкан. Гаиләдә балаларның һәрберсендә күңел дәфтәре булып, әлеге блокнотларның беренче битләре әти кешенең аерым шушы бала өчен генә язылган нәсыйхәтләре белән башланып китүе игътибарга лаек. Әсма Шәрәф блокнотының беренче битендә язылган сүзләргә тукталып үтик: *«Сөекле*

Бисмилла иррахман иррахим.
Гэзиз балаларым, Габдельахат, Фирдаус, Альмира, Диляра. hэммэгезгэ ихлас сэламмэремне тэблиг итэмен.

кызым Әсмага. Гыйлем өйрән, гыйлем изгегә тартыр, гыйлем булган кешедә зиһен артыр. Үзеңә кирәк булачак әйберләрне хасил кылсаң, кешеләргә ачык йөзле булсаң, сүзеңне йомшак сөйләсәң, шулвакыт син булырсың акыллы кыз, яхшы кеше. Сезгә догачы Р.Фәхреддин».

Тәрбияви хезмәтләрендә җәмгыятьне гыйлемгә өндәгән кебек, кызының шәхси көндәлек дәфтәренә язылган фикер дә гыйлем өйрәнүгә багышланган. «Сезгә догачы Р.Фәхреддин» дигән юлларны укыгач, мондый сүзләрне бары тик балаларына тәрбия үрнәге булган аталар гына яза ала, дигән уй сызылып үтә күңелдән. Балалары исеменә язылган хатларны да бик мәгънәле итеп «сезгә догачы әткәгез» сүзләре белән тәмамлап дата куя торган булган. Димәк, ни генә булмасын, ата кешенең балаларына даими рәвештә хәер-догада, бары тик изгелек теләп торганын бала үзе дә төшенергә тиештер.

1930 нчы еллар илебез тарихында нинди генә авыр еллар булса да Р.Фәхреддин Мәскәү, Казан шәһәрләрендә яшәүче балаларына, туганнарына Уфа шәһәреннән даими рәвештә хат салып торган. 1936 елда Мәскәүгә улы Габделәхәд гаиләсенә язылган хатта аны шик-шөбһә биләп алганлыгы ачык күренә: *«...сезгә хат яза алмауның сәбәбе — хатлар укылыр да, сезгә зарар килүдән курку булды...»* Мондый эчтәлектәге хатларны саклау үзе бер кыюлык сораган. Курку белмәс кызлар хатларны гомер буе саклап киләчәк буын өчен олы мирас калдырган. Музеебыз фондындагы Әсма Шәрәф документлары арасында номерлар белән тамгаланган җиде хат бар. Әлеге хатлар аша гаиләнең шатлыгын, кайгы-кичерешләрен күзалларга мөмкин.

Беренче номерлы хат Зәйнәп Фәхреддиновага 1931 елның февраль аенда язылган. Хатта Р.Фәхреддин кызына нәсыйхәтләр бирә: *«...дөнья көтү өчен «гыйлем» генә җитми, бәлки «гамәл» дә кирәк, «гамәл» булмаса, «гыйлем»нән күп хикмәт чыкмый...»* Әлеге сүзләрнең махсус аның өчен язылуын искәртеп, *«бу сүз синең хакта да булганлыктан яздым»*, — дип тәмамлый. Зәйнәп Фәхреддинова 1929 елда Казан дәүләт университетының медицина факультетын тәмамлап, «врач» дипломы алган югары белемле яшь белгеч буларак, клиник хастаханәдә эшли башлаган була. Нинди генә тормыш авырлыклары кичәргә туры килсә дә, Зәйнәп Фәхреддинова, үзе сайлаган һөнәргә тугры калып, лаеклы ялга чыкканчы җәмгыять алдында үз вазифасын җиренә җиткереп башкара. Билгеле булганча, монда ата кешенең нәсыйхәтләре йогынты ясамый калмаган.

Икенче номер белән билгеләнгән хатны Р.Фәхреддин белән Нурҗамал абыстай 1931 елның март аенда оныклары Йолдыз Шәрәфкә язган. Эчтәлектән күренгәнчә, алты яшьлек оныгы бабасы исеменә үз кулы белән язып ачык хат юллаган булган. Аңа каршы Р.Фәхреддин болай дип яза: *«... үз кулың белән язуың өчен бик шатландык. Яза белү, укый белү — бик зур һөнәрдер. Хатыңны абзаларың вә туганнарың укыдылар вә бик шатландылар. Өстәл өстендә торадыр...»* Сабыйны киләчәктә белем эстәсен өчен дәртсендереп язган хаты да тәрбия чарасы булып тора. Оныгының укый-яза белергә өйрәнүе аның өчен зур сөенеч икәнлеге ачык аңлашыла.

Йолдызның сеңлесе Бәллүр 1930 елны туып, 1934 елда дүрт яше дә тулмыйча үлеп китә. Яшь гаилә олы кайгы кичерә. Түп-түгәрәк йөзле, сөйкемле сабыйның бакый дөньяга күчү хәбәрен Р.Фәхреддингә улы Габдерәшит хәбәр итә. Өченче номер белән билгеләнгән, 1934 елның октябрь аенда язылган хатта бу турыда тәфсилләп әйтелә: *«... Аллаһы Тәгаләдән инде сабыр җан кыйлуны телимез, нечкәргән күңелемез берлә үзегезгә дә сабыр итү вә түзү берлә нәсыйхәт кыйламыз. Буласы эш булды, моңа һич чара юк. Мон-*

нан да олуг кайгылар вә хәсрәтләр булырга мөмкин. Аллаһы Тәгалә шундыйлардан сакласын...» — дип кызлары Әсма белән Зәйнәпкә, кияве Галимҗанга, оныклары Йолдыз белән Арсланга сабыр итәргә нәсыйхәт кыла. *«Балаларыгызның калганнары бәхетле вә тәүфыйклы, чын адәм булып җитешсеннәр, үзегезгә һәм мөхтәрәм карендәшләренә вә яхшы бәндәләргә ярдәмче булып дөнья көтсеннәр!»* — дип теләкләр тели. Р.Фәхреддин кызы Зәйнәп өчен 1934 елның ноябрендә язган (дүртенче номер белән билгеләнгән) хатта да артык кайгырмаска өнди. *«Дөнья шулай инде. Рәхәтлектән генә тормый. Һичнәрсәдә дәвам юк, була да бетә, килә дә китә...»* — дип фәлсәфи фикерен белдерә. Шул ук көнне кызы Әсма белән кияве Галимҗан исеменә язган хатта: *«Бер мәртәбә кайгыга батабыз, чумабыз, шул арада нинди рәвештә үзеңнең хәлеңне язып аңлатырлык, үз-үзеңә акыл бирерлек вә үзеңне юатырлык балаларымыз вә кызларымыз булган икән, моның өчен күзләребездән дәрьялар агызып елап Аллаһы Тәгаләгә шөкер итсәк тә аз булыр, дип куанабыз... Үзебезне бәхетле бәндәләрдән саныйбыз.... Буласы эш булды, күреләсе маҗара күрелде. Ахыры хәерле булсын. Үзегез, һәммәгез сәламәт булып тынычлыкта бер-берегезгә ярдәмче, бер-берегезгә юаныч булып гомер сөрсәгез иде»*, — дип ата кеше изге теләкләрен җиткерә. (Тик киләчәктә бу гаиләне ни көткәнен бары тик Аллаһы Тәгалә үзе генә белгәндер. Бәллүрнең үлеме Әсма белән Галимҗан Шәрәфләр гаиләсенең беренче югалтулары гына, беренче кайгылары гына булмый. Бу ачы хәсрәтнең артында тагын да зуррак сынаулар көтә.) Шушы ук хатта Зәйнәпнең Әсма гаиләсе янында булып, авыру балага тиешле тәрбия бирүен олы куаныч буларак та билгеләп үтә Р.Фәхреддин. Кызлар өчен язылган «Нәсыйхәт» китабында: *«...бөтен гомерегез — кызлык, хатынлык, аналык диелгән өч хәлдән гыйбарәт булганлыгы вә хасталарны карау хезмәте дә бу кешеләрнең хезмәте булганлыктан, бу хезмәтләрне игътибар белән үтәгез!»* — дип белдерә. Авыру кешеләрне карау олы сабырлык вә түземлек сорый, шуңа күрә бу хезмәтне гүзәл холыклы кешеләр тиешенчә башкара ала. Балаларына язылган хатта да бу хакта туктапып фикер йөртүе аерым игътибарга лаек.

Алтынчы номер белән билгеләнгән хат 1935 елның гыйнвар аенда Казанда яшәүче балалары исеменә юлланган. Ни дәрәҗәдә сабыр булуны сораса да, оныгы Бәллүрнең вафат булуы бабай кешенең сәламәтлеген шактый какшаткан булып чыга: *«Бер айдан артык буладыр, үзем күптөрле авырулар белән мәшәкатьләндем. Бу көннәрдә колакларым ишетмәүдән кала башкалары бетеп торалар»*, — дип үз исәнлеге турында хәбәр кыла. Җиденче номер белән тамгаланган, Мәскәүдә яшәүче балалары исеменә 1936 елның февраль ахырында язылган хаттан күренгәнчә, галимнең сәламәтлеге әле дә ныгымаган, киләчәк тормышына өмете сүнеп бара: *«... ике ай кадәр вакытлардан бирле сәламәтлегем зәгыйфь. Дөньяда рәгъбәтем калмады... Сездән вә балаларымның һәммәсеннән камил дәрәҗәдә ризамын, бәхилмен...»* Бу хаттан соң Р.Фәхреддиннең үз кулы белән язылган хаты сакланмаган. 1936 елның җан өшеткеч авыр еллар икәнлегенә шик юк. Ил өстенә килгән гарасат та мөфти күңеленә борчу салган. Ул вакытта какшаган сәламәтлекне ныгытырга һич кенә дә мөмкинлек булмаган. Гаилә әгъзалары арасында соңрак язылган хатлар да бу елларга ачыклык кертә алмыйлар. Хатларның күп очракта тикшерү аша узганын истә тотып, алар бер-берсе белән хәбәрләшүне дә сирәгәйтергә мәҗбүр булган. Соңрак Р.Фәхреддиннең балалары бәйрәмнәр белән котлаган открыткалар аша бер-берсенең исәнсаулыгын белгертеп торган. Ә вакыт тәгәрмәче туктаусыз алга тәгәрәгән... ■

Казакъстанда, Семей шәһәрендә. 1985 елның җәе иде бу. Абайның тууына 140 ел тулган көннәр

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Рәдиф Гаташ

***

Без — дүрт кеше: Әбрар ага Кәримуллин *(сулдан өченче)*, Илдар Юзеев *(уңнан бишенче)*, Казакъстанда туып үскән Мәхмүт Хөсәен *(уртада, ак күлмәкле)* һәм аның артында — мин. «Абай юлы» романына кече яшьтән гашыйк булган, казакъ әдәбиятын, шигъриятен яратучы фәкыйрьләрегез... Утыз ел узып киткән икән, әй! Әмма кичәгедәй истә. Гомер-гомергә татар мәдрәсәләре, татар муллалары, байлары булган Семипалатинск (Семей) шәһәре, Абай булган җирләр, Иртыш елгасы. Достоевский яшәгән урыннар, музей. Аннары дала, Чыңгыз тавы итәгендәге казакъ авыллары, Абайның сөйгәне Тогҗан яшәгән авыл, Абай күмелгән мула (зират)... Төне буена сузылган «алтын бакан» (таган) уеннары, чәчәннәр-акыннар ярышы (казакълар «айтыз» диләр, безнеңчә «әйтеш» була инде). Безнең дә борынгы чәчәннәребез белгән булыр ул думбра уйнап сүз һәм җырда көч сынашуны! Төрки рух, Айдалада талантлы казакъ «бавзә»ларыбыз, җанга якын «чырак»лар ! Шунда ук Тукай китапларын укып белгән чал аксакал акын белән әңгәмә. Шактый «утрак»ланган без «нугай»лар да тамырларда төрки каны акканын тойдык ул көннәрдә. Кызганыч ки, юлдашларым инде күптән вафат. Казакъстанда ул көннәрдә танышкан дусларның да күбесе дөньяда юк. Семей айданы тирәләре дә полигонлы, радиацияле урынга әйләнеп, шактыйдан ябылып торды...

Хәзер, бездән соң нәкъ утыз ел узгач, Абайның бөелгы зур юбилеена (казакъча: туена) Казаннан дустыбыз, олы галим Хатыйп Миңнегулов барды. Казакъстанның күптәннән «үз

кешесенә» әйләнгән төрки әдәбиятлар белгече Хатыйп дустым Семейның бик нык үзгәргәнен, үскәнен, Абай белән бәйле мемориаль комплекслар үсеп чыкканын, Чыңгыз таулары итәгендә — Абай каберендә дә, энесе Шәкәрим гүрендә дә — мәрмәр һәйкәл, төрбәләр төзелүен, Абай юбилееның дөнья күләмендәге олуг бәйрәм ителүен сокланып, һушы китеп сөйләде. Безгә дә мөстәкыйль төрки кардәшләребездән көнләшергә генә түгел, ә үрнәк алырга, бөекләребезне чын-чынлап зурлый белергә өйрәнергә кирәктер инде, бәлки?! Әлбәттә, шулай.

1986 елның җәендә, СССР язучыларының VIII съезды узган көннәрдә, Мәскәүдә Кремльнең бер залында төшкән фото бу

***

Җитәкчебез — Туфан Миңнуллин. Без шактый санда делегатлар идек (Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Миркасыйм Госманов, Ренат Харис, Тәлгат Галиуллин, Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим, Нонна Орешина һ.б. белән мин фәкыйрегез дә). Кызыл мәйданда төшкән күмәк фотобыз төрле китапларда дөнья күрде. Мәшһүр Чыңгыз Айтматов белән бергәләп төшкәне дә басыла тора. Фотографы — Фәнил Тимербаев, үзебездә — Казанда эшләп, яшәп киткән егет, минем якташ. Истәлеккә сурәт алдыруны Гәрәй Рәхим белән икәү оештырдык. Ә Андрей Вознесенский белән төшкәне — минем «тырышлык». Атаклы урыс шагыйре бик теләп кабул итте тәкъдимне.

Татар язучылары нәкъ шул көнне Раиса Горбачёва белән дә рәсемгә төшеп калды бит әле! Китабын алырга дип, Гәрәй ашыгып өенә кайтып киткән иде, мин дә бер якта башкортлар белән сөйләшеп, керми калдым. Ул съезд (соңгылардан булгангадырмы?) бик кызыклы узды. Бөтен Союздан җыелган делегатлар, төрле халык вәкилләре арасында танышлар да күп иде. Таныш булмаган бөек замандашлар да...

СССР таркалу алдыннан Мәскәүдә язучыларның уртак бер җыелышына шаһит сурәтләр. Ихлас дуслык көннәре, аралашулар хатирәсе!.. ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Сузылмасын кеше ашына кулың,
Алдыңдагын гына аша, акыллым.

Пычак тартма шунда, җилек суырма,
Тиз җий, тик күршеңне һич ашыктырма.

Хатыннарча җиймә, артык ашыкма,
Шулай ук тәкәллеф кылма артыкча.

Ашка килгәнеңдә бик тук булсаң да,
Бий ашы – хөрмәт, дип аша, кысталма.

Ни төрле бер эшкә тисә дә кулың,
Тотын ипләп, йөзең яктырак булыр.

Ни шәп әйткән, әнә, белекле хәким
(Бу сүзеңне тотсаң, саф алтыннарга тиң):

Әгәр эш кушсалар, и, уңган батыр,
Эшне белек илә гамәлгә ашыр.

Әгәр боерсалар оештыруны,
Юмарт, уяу бул һәм тиз үк тап юлны.

Ия булсаң өлкә, җир-су, утарга,
Малны юмарт, ләкин белеп тотарга!

Вәзир булсаң кулың бик озын була,
Тик ахмак эш итмә, бул түзем генә.

Киңәшче булсаң, бул бик тә тәгъбирле,
Хәтәр һәм ялгышны әйтеп бирерлек.

Әгәр йолдыз багар[1] урыны тисә,
Сак бул, бәхет кунган сиңа югыйсә.

Сү башы, ил башы булсаң син үзең,
Тугры бул, җете тот колак вә күзне.

Хаҗип булсаң, һич тә ришвәтче булма,
Ятим-тол, ярлылар хаҗәтен тыңла.

Сине хәзинәче итеп куйсалар,
Тугры бул, дәүләти малга кул салма.

Бетекче-сәркатип булалсаң үзең,
Бий серен каты тот, чыгарма сүзен.

Иң зур гамәлдарлар була нәкъ шулар,
Шуннан соң төрле эш башкаручылар:

Түшәкче, лачынчы яки ашчылар,
Вак-төяк эшләрдә алар башчылар.

Син андый хезмәттән ерак тор берүк,
Рәхәте аз аның, мәшәкате күп.

**Әгәр эш кушсалар, и, уңган батыр,
Эшне белек илә гамәлгә ашыр.**

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.

[1] Оригиналда кӧк айуклук. Бу сүзне ДТС (312) «тотнаклык» дип аңлата, хәлбуки бу аңлатма контекстка ярашмый: кӧк айук — тәгаен бер вазифа ияce «төрекмәннәрдә бертөр башлык» дип кенә аңлатыла. Без кӧк айук «күк ихтыярын әйтеп (ай — «әйтү») бирүче», дип уйлыйбыз.

Олыны олыла, кадерен сакла,
Сиңа килер дәүләт вә кот шулчакта.

Үзеңә чын хөрмәт теләсәң әгәр,
Кешене хөрмәт ит, кушчы-гамәлдар![2]

Олыны олыла, кадерен сакла,
Сиңа килер дәүләт вә кот шулчакта.

«Олыны хөрмәтләү бар дөньяда бар:
Олы кеше килсә, аягыңа бас.

Ни ди, ишет, әнә абышка[3] сүзен
(Аның сүзен тотсаң ачылыр күзең):

Ярашса олыга кече хөрмәте,
Олы да кечегә кылыр игътибар».

Сүзен кисеп әйтте Үгделмеш: – Менә
Бийгә хезмәт итү шулай күрелә.

Мин әйттем – ишеттең инде, өйрәндең
Бийгә хезмәт итү ничек кирәген.

Менә шулай булыр бийнең табугы[4],
Уңсаң, ачылачак бәхет капусы.

Моны белдең, зирәк, үзең белерсең,
Ары табан әйтсәм, үзләштерерсең.

1. КАПУДАГЫ ИРАТ БЕЛӘН МӨГАМӘЛӘДӘН БАШЛЫЙК

Җавап биреп әйтте Уйгырмыш сүзен:
– Ишеттем барсын да, и, үзең изге.

Тагын бер сүз-сорау башыма килде –
Шуны тыңлап, җавап әйтеп бир инде.

Илбик табугына керсәм шәһәргә,
Аның капусына кирәк килергә.

Моның тәртипләре-юлы ничек соң?
Яшәү шуңа баглы булыр ич, дустым.

Ничек ират белән аралашырга?
Һәм башлыкларына яраклашырга?

Табыйм дисәң, иплем, хөрмәт вә гыйззәт,
Ир-ат белән булган араны төзәт.

Хәзер инде шуны миңа син аңлат
Һәм мин белим аслын, уйлыйм бер кабат.

Җавапта Үгделмеш әйтте: – Бу чыннан
Да кирәкле шәйдер, кадерле туган.

Миңа фарыз моны әйтеп бирергә,
Ниләр белергә һәм ничек йөрергә.

Аларга безнең көн баглы ул, кардәш,
Кайсысын кардәш дин, кайсысын адаш.

Кирәк сәрай әһле белән ярашу,
Сөйләшү, киңәшү һәм аралашу.

Ни ди, ишет, күптән хезмәт кылучы –
Сәрайда низам һәм тәртип куючы:

«Якынлык теләсәң үзең бий белән,
Капу башы белән якынлык телә.

Табыйм дисәң, иплем, хөрмәт вә гыйззәт,
Ират белән булган араны төзәт.

[2] Кушчы-гамәлдар — «чиновник» (беренче сүз – төрки, икенчесе фарсыча).
[3] Оригиналда авучка — «карый, бик карт кеше».
[4] Табуг — буйсынган хезмәткәре һәм аның хезмәте.

Олыны олы бел – сүзен хөрмәтлә,
Сине әдәпсез бер утын, димәсләр.

Ничек якын күрсә дә сине бийләр,
Кәперәймә ират[5] алдында бер дә.

Төгәл өч төркемдер капу әһеле
(Боларга баглыдыр эшнең асылы):

Беренчесе була синнән олуглар,
Хөрмәт ит – алар да сине олуглар.

Олыны олы бел – сүзен хөрмәтлә,
Сине әдәпсез бер утын, димәсләр.

Ни яхшы әйткән бер белдекле белкә
(Белкәләрнең сүзен атма чүплеккә):

«Кечегә олылык олыдан кала,
Олыга яраган кече кот ала.
Олы сүзен тыңла – йөгер йомышка,
Теләгенә кече шулай җитәлә».

Олылар бәхет ул – бәхет теләсәң,
Олыга хезмәт ит – бәхет киләчәк.

Икенче бер төркем, туган, ул тиң-туш[6].
Ерагайтсаң — дошман, якын күрсәң — дус.

Аралашыр кешең – дустың һәм ишең,
Әҗер-бүләк алсын синнән дус кешең.

Тагын үзгә төркем – синнән кечеләр.
Шулар арасында – әче, төчеләр.

Хезмәт итсә – әҗер, зыян итсә – ор,
Игътибарсыз куйма, хәлен белеп тор.

Басылдырма, текә тот үз-үзеңне,
Телеңне уйнатма – аз әйт сүзеңне.

Дошман бер булса да, зарары мең-мең,
Дустың мең булса да, бер генәгә тиң.

Адаш, кулдаш, иптәш күп булсын шактый,
Аларның күплеген мәкаль дә мактый.

Таныш түгелләрне дошман кылма тиз,
Дошман күплегеннән файда булмас ич.

Дошман аз булса да зыяны күптер,
Дошман файдалы, дип расламый фикер.

Ни ди, ишет, әнә күңле уяулар
(Дошманлыкка дучар булганнар шулар):

Дошман бер булса да, зарары мең-мең,
Дустың мең булса да, бер генәгә тиң.

Дошманыннан кеше күрмәс игелек,
Ә игелек күрсәң – хәйлә дип белик.

Танышың булса ни мөнәсәбәттә,
Шулай ук бул – ул шат булсын, әлбәттә.

Исәрне иш итмә, кач һәм ерак тор,
Исәр – юлдан язган яман юлдаштыр.

Үзеңә тиңдәшне ал дус-иш итеп,
Тик тиңдәшләр белән ул чын дус-ишлек.

Исәрне иш итмә, кач һәм ерак тор,
Исәр — юлдан язган яман юлдаштыр.

Үзең изге атлы булаем дисәң,
Кырыс бул, катылма исәр-иссезгә.

Күрәм – барча затлар үз өерендә,
*Кеше, кош-корт, җанвар өерен белерләр.**

Ишет, нәрсә сөйли илчеләр башы
(Яхшы-яманны күп кичергән, яшьле):

«Сыерчыкны күрдем: чыр-чыр кычкыра,
Карасам – ише бар, ул да кап-кара,

Аккошка кушылмый, күр, һичбер үрдәк,
Каракош һәм шоңкар йөреми бергә.

[5] Ир-ат — хан сараендагы каравыл әһелләре: рәсман алар ханның хезмәтчеләре булсалар да, еш кына хан үзе аларга баглы булган һәм алар ханнарны алмаштыра алганнар.
[6] Тиң-туш – оригиналда шулай, татар сөйләшләрендә дә бар.
* Нәкъ оригиналдагыча язылган юллар курсив белән бирелде.

Очар кошлар оча иштәш өердә,
Сайлаган иптәшең булсын фикердәш».

Кеше якынлыгы ике төрледер,
Ике төрле кеше дус булып йөрер:

Берсе – тәңредәш һәм уйдаш, фикердәш.
Мондый дуслык азат була мәкердән.

Икенче төр дуслык – эш кирәгенчә,
Бу дуслык ныгымас, кирәге бетсә.

Әгәр тәңредәш дус белән эш итсәң,
Йөген күтәреш һәм сукранма һич тә.

Бу дуслыктан максат итмә бер файда:
Файдасын күрерсең теге дөньяда.

Әгәр дуслык булса тик эш хакына,
Ул дус әхвәленә бик үк катылма.

Ни ди дуслары күп булган бер ирән
(Дусларның төрлесен ул сынап күргән):

Дусны файдада һәм зыянда сына,
Тик үзеңнең тезең нык булсын шунда.

Дустыңның күңелен белмәкче булсаң,
Ачы сүзләр әйт һәм, гүя, ачулан.

Сөярен-сөймәсен белим дисәң, син
Кадерле әйберен сора – белерсең.

Тузынмаса ике очрагында да,
Кадерлә ул ирне, якын күр җанга.

Гайбәтче сүзенә бер дә кушылма –
Күмер көйри аның теле очында.

Низаглар дөньяда гайбәттән куба,
Гайбәтче башын кис, и катгый туган!

Тәмгычының булса тәмгысы әгәр,
Сиңа ул «агам», йә «энекәш» дияр.

Тәмгысы булмаса йөзен чөерер,
Күрмәгәндәй булыр, дәшмичә йөрер.

Дусны файдада һәм зыянда сына,
Тик үзеңнең тезең нык булсын шунда.

Һәр тиңдәшне дус тот, булса тәмгысыз:
Алар белән яшәп була кайгысыз.

Дус-иш шатлык яки кайгы көнендә
Уртаклашып, ярдәм итеп килерләр.

Яраткан иптәш-дус күп булсын, дисәң,
Ачык йөз, икмәк-тоз кызганма һич тә.

Бу ике кылыктан җылыныр кеше,
Яхшы-яман көндә булыр дус-ишең.

Бу хакта тәгълимат болайрак сөйли
(Бу сүзне эшкә тот, холкы сөеклем):

«Тоз-икмәк җийдер син елмаеп-көлеп,
Йөзеңне якты тот, сөчек сүз белеп.
Инсанны кол итә торган шәй шулар,
Бүтәнне мин белмим, тап үзең берүк».

Ике төрле тагы, күр, дошман-ягы
(Корылган буладыр аның тозагы):

«Бере мәҗүсидер, дошман ул төптән.
Кяфер дә диелер. Дошманлык — күптән
Янә бер дошманлык – файда, зарардан,
Бу дошманлык була бары тик үчтән»

Кяферләргә каршы кирәк каты җәң[7],
Фида булсын шунда мал һәм тән вә җан.

Әгәр юк-бар өчен булса дошманлык,
Юк өчен булашма, кыл миһербанлык.

Дошманга файда кыл – ул якыная,
Явызлык кылам, дип ул кыла файда.

Ничек тә дошманны якын ит – яраш,
Котыл дошманлыктан – исән булыр баш.

Яраткан иптәш-дус күп булсын, дисәң,
Ачык йөз, икмәк-тоз кызганма һич тә.

[7] Җәң — «сугыш, сугышның бер эпизоды» (битва). Чаг.: *җәнҗал, җәң-җәдал.*

Яраксыз кешегә барма якын да,
Яраксыз килер дә тотар якаңнан.

Җәнҗалдан файда юк – ачык бел шуны,
Һәм файдасыз эшкә тидермә кулны.

Дошманың артмасын, хезмәтең артсын,
Дошманлы кешегә бар дөнья каршы.

Кешенең яхшысын, иплесен дус күр,
Ярамас дуслардан кеше үкенер.

Яхшы дус өстәсәң якынлашырга,
Ике төрледән син эзлә – бул бергә.

Бере – изге, батыр, чыннан асылзат,
Шундый белән дуслаш, әгәр табылса.

Икенчесе – тирән динле, фикерле
Кеше ул, кешелек шундыйдан килер.

Якынлык тот ошбу ике зат белән,
Болардан тиячәк игелек гелән.

Яманлыгы мәшһүр кешедән син кач,
Бу төрле кешегә кара эчлек хас.

Корымга кагылма – карасы йогар,
Яманга ягылма – яласы йогар.

Менә нәрсә дигән белемле белкә
(Укымышлы моны бәяли белә):

«Яманга катылма, и, иге кеше,
Сиңа ягылачак аның кылмышы».

Яманга ягылма, белеп тор, туган,
Яманатың чыгар илара шуннан.

Яраксыз кешегә барма якын да,
Яраксыз килер дә тотар якаңнан.

Күп тапкыр күрдем ки – иге бер кеше
Исәргә катылгач, бозылды эше.

Күрдем изгеләрне – яман дус өчен
Югалтты халыкта абруйлы исмен.

Бийләр өен шулай атыйлар – *карши*,
Монда кеше берсе-берсенә каршы.

Хөсет байтак булыр *карши* эчендә,
Хөсет кайда булса, шунда җәң-җәдәл.

Кем олырак синнән, ул сине типсәр[8],
Сине утка этәр, «көйсен», дип эстәр.

Сине типсәячәк күп тыңдәшләрең,
Хөсетлектән көнең төнгә әйләнер.

Шуңа күрә *карши* – *каршый* диелә,
Ике як карышса, берсе җиңелә.

Син инде түзем бул, күңлем кояшы,
Һичкем дә типмәсә, йөре тын басып.

Хөсет — чир ул, аны дәвалау озак,
Хөсетле үз-үзен гел ашаячак.

Берәүгә сөенеч килгәнгә сөен,
Берәүгә көенеч килгәнгә көен.

Ни бар яхшы, яман – Алла хөкеме,
Хөсетле һичкайчан куймас хөсетен.

Ни булыр кешегә типсәү – хөсеттән?
Хөсетчеләр чирләр, бозылыр эчтән.

Көчеңчә игелек кыл син һәркемгә,
Күрермен — дип уйла — нәтиҗәсен дә.

Берәүгә сөенеч килгәнгә сөен,
Берәүгә көенеч килгәнгә көен.

Атың изге булыр, сине сөярләр,
Сиңа якынлашыр өчен юл эзләрләр.

Дошман арттырма син үзеңә, туган,
Ә дус-ишләр һич тә артык күп булмас.

Әгәр дошман килеп чыкса бер тагын,
Аңар әзер булсын шундук тозагың.

Дәвамы бар ■

[8] Типсәү — «хурлау, кимсетү», себер татарларында бик билгеле сүз.

Н.Хаҗиәхмәтов рәсеме

КЫЙССАИ ТАҺИР ИЛӘ ЗӨҺРӘ

Артыннан килеп кочмакчы булганында, үпкәләгән төс күрсәтеп, Зөһрә Таһирга шул бәетне әйтте:

Серләремә — сердәшсең. Юлларымда — юлдашсың.
Кулың миннән ал, Таһир: син — миңа карендәшсең...

Таһир шунда ук аңа болай дип җавап кайтарды:

Серемә — сердәшем син. Юлымда — юлдашым син. –
Мин — бер вәзир улымын: нинди карендәшем син?

Зөһрә аңа, үз үпкәсен белдереп, бу шигырьне әйтте:

Тәкъдир җитеп, сөйгәнмен. Күп бәетләр сөйләдем,
Ә син мине оялттың! Шул булдымы сөйгәнең?

Гафу үтенеп, Таһир бу бәетне әйтте:

Беләсең ич, һич моны эшләмәдем юри мин.
Җаным сөйгән Зөһрәҗан, кичерүең сорыймын.

Зөһрә, куанып, аңа болай җавап кайтарды:

* Дәвамы. Башы журналның 9 нчы санында (№9, 2015).

Гашыйгым син, Таһирым, мәгъшугым син, Таһирым.
Гафуымның билгесе: кил үбешик, Таһирым.

Шуннан соң алар, бер-берсенең муеннарына сарылышып, үбештеләр һәм үзләренең сөю хисләрен бер-берсенә сөйләделәр.

Көннәр бер-бер артлы уза торды. Алар муллаларына барып әүвәлге кебек сабак укыр иделәр. Буш вакытларында, әлеге бакчага килеп, бергәләшеп сәер итәрләр һәм бер-берсенә шигырьләр әйтешер иделәр. Унбиш яшьләренә кергәндә болар шулкадәр балкып чәчәк аткан гөлләрдәй гүзәл кыз һәм егет булып җитештеләр ки, күргән кеше: «Аһ, тагын бер мәртәбә күрсәм...» — дип, артларыннан карап калыр иде.

Көннәрдән беркөнне Таһир илә Зөһрә ул чишмә янындагы бакчага тагын икәү килеп сәйран кылдылар, бер агач күләгәсенә утырып хәлләренә яраша шигырьләр әйтештеләр.

Зөһрәм, тансык ярым — син, җисем эчендә, җаным — син,
Башым белән җаннарым корбан булыр ярым син!

Зөһрә аңа болай җавап кайтарды:

Җандай газиз булгач соң, ничек сине сөймәскә?
Миңа син җан булгачтын, ничек «җаным» димәскә?

Шуннан соң алар бер-берсенә антлар, вәгъдәләр бирештеләр. [...]

Вәзире Баһир Бабаханның гаскәр башы иде. Ул һәлак булганнан соң хан Бабахан яшь Карабатырны гаскәренә башлык итеп билгеләде. Карабатыр Бабаханның имектәшенең (бер имчәк анасын имеп үскән сөт туганының) баласы иде. Яшь булса да ул инде батырлыгы һәм сугыш эшенә маһирлыгы белән танылып өлгергән иде. Яубаш итеп билгеләнгәч тә, ул, Зөһрәгә өйләнеп, хан тәхетенә чыгу турында хыяллана башлады. Шул хыялы белән мавыгып, татлы өметләренә чумып яшәгәндә Карабатыр Зөһрәнең Таһирга гашыйк булуын сизеп калды. Шул заманда, көнчелек тамырлары бүртеп, ул боларның мәхәббәтенә каршы көрәшкә ташланасы итте. Сарай тирәсендә үскәнгә Карабатыр төрле мәкер-бозыклыкларга бик оста иде. Ул Зөһрәнең мәхәббәтенә каршы көрәшкә аның әти-әнисен аякландырасы булды. Беркөнне Карабатыр Таһир белән Зөһрәнең бакчага китәргә җыенганнарын белеп калды да, болардан алда тиз генә бакчага килеп, чишмә буендагы бер куе яфраклы агачның башына менеп посып утырды. Тиздән Таһир белән Зөһрә дә бер-бер артлы бакчага килеп керделәр, очраштылар, күрештеләр һәм, Ходаның хикмәте, нәкъ шул Карабатыр яшеренгән агач янына килеп чишмә буена утырып, бер-берсенә җыр-шигырьләр әйтешә башладылар. [...]

Боларны читтән күзәтеп торган Карабатыр әләк белән Алтын сарайга, ханым алдына йөгерде, бу хәлләрне сөйләп, аны куркытты. [...]

Карабатыр кебек бер егет авызыннан мондый хәбәр ишетүдән хурланып ханым буыла язды, ачуыннан шартлар дәрәҗәгә җитте, каны кызуының ялкыны күлмәгенә кабардай булды. Ул шунда ук хан янына йөгерде. Тагын да дәһшәтлерәк төс биреп, бу хәбәрне ханга ишеттерде. Әмма хан бу хәбәрдән ул кадәр чәпчемәде, ярсымады: «Илдәге һәртөрле юк-бар сүзләрдән бу кадәр кызарга кирәкми», — дигән үгет белән генә чикләнмәкче булды кебек. Әмма ханым аз гына да суынмады: «Менә, үзең сораш, колагың белән ишет», — дип шунда ук Карабатырны Бабахан каршына җилтерәтеп китерде. Карабатыр, урынына карап, яңа уйдырмалар белән тәфсилләп, хәбәрне ханга да сөйләп бирде. Хан бераз уйланып торганнан соң: «Кыз баланы өлгергән минутында ук тапшырырга хәерлерәктер шул», – дип, Таһирга кызын бирү турында уйлана башлады. Хатыны тынычлана алмагач: «Тукта, кызма, һәр хәлне үз күзең белән күреп ышанган хәерле. Барып үзем күзәтим, күрим, шуннан соң уйлашырбыз», — дигән нәтиҗәгә

килде. Карабатырга: «Алар тагын бакчага барырга әзерләнгән вакытларында миңа килеп әйтерсең, икәү барып күзәтербез», — диде. Карабатыр боларның кабат бакчага китәргә җыенган вакытларын сагалап йөрде дә, ханга килеп хәбәр бирде. Берничә көн үткәннән соң Таһир белән Зөһрә сазларын, сорнайларын алып кабат бакчага киттеләр. Әмма аларның әзерләнүләрен күргәч тә хан белән Карабатыр да бакчага барып, читтәрәк, бер җирдә посып, боларны күзәтеп тордылар. Хикмәти Хода, ул көнне Таһир белән Зөһрә бер-берсенә сарылышмадылар, үбешмәделәр, үз хәлләреннән зарланышып җыр-шигырьләр генә әйтештеләр. Уйчан Таһир Зөһрәгә бу бәетләрне әйтте:

Сезне безгә бирергә шаһым вәгъдә кылгандыр.
Мәгърур патша-әтиең, дәүләт-бәхете тулгандыр,
Вәгъдә кылган көннәрен күрер микән күзебез?
Югыйсә, хәсрәт белән үтәр микән көнебез?
Бу хәсрәтем бетәрме, вәгъдә көне җитәрме?
Булмаса, аһ-зарларым гомерлеккә китәрме?

Зөһрә аны юатып җавап кайтарды:

Сүзен әйтердән элек, ханнар гакыл кыла, ди.
«Тәхетем бирәм!» — дисә, соң вәгъдәсендә тора, ди.
Ата-анам миһербанлы булды миңа һәрвакыт.
Вәгъдә, минем ризалык — китерер безгә бәхет!..

Алтын сарайга кайткач та, хан Бабахан ничәләп хезмәтчеләрен Таһирны үз алдына алып килергә юнәлтте. [...]

Хан Таһирны кырыс каршы алды. Таһирның сәламенә җавап та биреп тормастан, кашларын җыерып:

–Бу ни дигән сүз: ничек син минем кызым белән очрашырга, аңа гыйшык җырлары әйтергә батырчылык иттең? Зөһрә — патша кызы, син — гидайсың! Аллаһы Тәгалә коллары арасын бер-берсенә якыная алмаслык дәрәҗәдә төрле-төрле иткән. Кем сине мондый әдәпсезлеккә өйрәтте дә кем арагызда арачы булды? — дип ачулы сораулар яудырды. Таһир да хан алдында үтәлә торган барча әдәп кагыйдәләрен җиренә җиткереп, әмма аз гына да каушамастан, катгый җавап кайтарды: «Әйе, Зөһрә — падишаһ, мин аның гидае. Зөһрә мәхәббәтенең колы булып, мин аны үземә чын патша иттем. Гыйшык — Ходадан, ул безнең икебезне дә тиңләштерде: Зөһрә дә минем кебек үк яна», — диде. Бу мәхәббәт нигезендә ханның үз әтисе белән вәгъдәләшүләре ятканлыгын да искә төшерергә онытмады: «Патшаларга хас рәхимлелек күрсәтеп, безнең икебезне максатыбызга җиткерсәң, без бәхетле булыр идек. Мин гидаең булсам, баю юлын ачу, кол булсам бәкләр сафына күчерү чын хакыйкый ханның кулыннан килә торган нәрсә...» — дип сүзен тәмамлады. Шулчак сарайга Таһирның әнисе килеп керде. Хан алдына тезләнеп, ул аңардан ике гашыйк яшьне бәхетле итүен үтенде. «Бер көнлек дөнья вәсвәсәсенә бирелеп, үз вәгъдәңне бозма, ятим хакына кермә», — дип ялварды. Хан Бабахан Гүзәл ханым сүзләреннән уйга калды. [...]

Ханым, өермәдәй ярсып, шунда ук хан алдына килеп җитә һәм, һичкайчан, һичкайчан да кызының Таһир белән кушылуына юл куймаячагын белдерә. [...] Үз сүзләренең патшага әллә ни зур тәэсир күрсәтмәгәнен күреп, бу туйны булдырмаска берәр төрле хәйлә эзли башлады. Ул шәһәрдә тирә-якка даны таралган бер сихерче карчык бар иде. Ханым сараена шул сихерчене чакыртып китертте. Таһир белән Зөһрә арасында булган мәхәббәтне, патшаның Зөһрәне Таһирга бирергә ният кылганын сөйләде дә: «Минем кызым — падишаһ кызыдыр, бу Таһир — вәзир углы гына. Мин кызымны Таһирга бирүгә һич риза түгел. Минем кызым — шаһзадәләргә лаек. Әй кортка, чарасын табып, син ханның күңелен

Таһирдан суыт, аны күрә алмый торган булсын», — дип, карчыкка күп алтыннар бирде. Шул заманда ук патшаның күңелендә Таһирга карата салкынлык һәм нәфрәт пәйда булды. Бар ниятләрен, вәгъдәләрен онытып: «Шул, бүгеннән Таһир сарайга кертелмәсен, күземә күренмәс булсын!», — дип боерды. [...]

Беркөнне Зөһрә сорнаен янына куеп, кулына саз алып уйнап утырганда апасыннан:

– И, апам, сиңа бер соравым бар, зинһар һичнәрсәне миннән яшермичә чын дөресен әйтегез әле: Таһирны ни өчен сарайдан читләштерделәр, шәһәрдән кудылар? — дип сорады. Моңарчы ул, дөрестән дә, моның сәбәбен анык кына белми иде. Апасы аңа Карабатырның шомчылык итүләрен һәм әләкләрен, туйга әзерлекләр башлап та, әнисе сихерче карчык ярдәмендә боздыргач, әтисенең Таһирны күрәлми башлавын — барын, барын сөйләп бирде: «Падишаһ хәзер дә икегезне тикшереп торырга, каравылчылар, һәр ягыгызга күзәтчеләр куйган, кичәкөндез серләрегезне тикшереп тора», — диде. Бу хәбәр Зөһрәнең кәефен шулкадәр бозды ки, ул һуштан язып егылыр хәлгә җитте. Апасы аның битенә гөл сулары сибеп, юатып кына бераз тынычландырды. Зөһрә әлеге сарай чарлагына чыгып көннәр буе юлдан үтүчеләрне тамаша кылып утырыр иде. Кай чакларда, узгынчылардан берәрсе, моңлы аваз белән Таһирның берәр зарлы шигырен җырлап җибәрә, Зөһрәҗан, сүзләрен ишетеп, Таһир белән күрешкәндәй булып кала иде.

Көннәрдән беркөнне, гадәтенчә, ялан кырларда сорнай-сазларын кулына алып җырлар әйтеп йөргәндә, Таһир Зөһрәнең кәрван юлына каршы җиде юл чатында сарай төзетеп, чарлагыннан узгынчыларны тамаша кылып утырулары турында ишетеп калды. «Чарлагында утырганда, Зөһрәҗанның гөл йөзен күрә алмаммы?» — дигән уй күңеленә килеп, ул да узгынчы рәвешендә Зөһрә сарае алдыннан үтмәкче булды. Сарайны күргәч тә ул Зөһрәне күргәндәй булды, сарай каршысына килеп чарлак тәрәзәсенә карап, үзенең үпкә сүзләрен әйтүдән тыелып кала алмады:

Әйткән вәгъдә-антларың оныттыңмы, Зөһрәҗан?
Әллә миннән күңелеңне суыттыңмы, Зөһрәҗан?! –
Юлыңда чын гашыйк җанның хәл-хәбәрен белмисең,
Аһ-зарлы, ялгыз ярыңнан бер хәбәр дә алмыйсың. –
Гашыйк ярлар мәгъшукка хәбәр салмас булырмы?
Чын хакыйкать яр булса, хәбәр алмас булырмы?..

Зөһрә Таһирның моңлы авазын ишетеп, тәрәзәгә ташланды, тәрәзәсенең канатларын киң ачып җибәрде. Апасы: «Чү, солтаным, бу ни итенүең, күзәтчеләр барын оныттыңмы?» – дип кисәтсә дә, Зөһрә тыелып калыр хәлдән үткән иде, бу сүзләрне колагына да элмәде, бар дөньясын онытып, Таһирга гөл йөзен күрсәтеп бу шигырьне әйтте:

Кайгы булды юлдашым, тоткын булды гөл башым. –
Таһир, күңелем калдырма: гыйшкың — минем моңдашым.

Таһир һаман әле үпкәсен баса алмый иде. Әйтте:

Шаһзадә кыз булсаң да оныттың, дим, антыңны? –
Мин хат итеп җыр юллыйм, син алмыйсың хатымны.

Таһирның гашыйк йөзен күреп, Зөһрәнең гакылы башыннан китә язып калды. Ул аның авазына рәхәтләнә, нәрсә әйткәнен Таһир: «Вәгъдәсез Зөһрә!» — дип такмаклап торса да, аны ишетми, аңламый, кабул итми иде. Аннан соң Таһир: «И җан Зөһрә, безнең бу аерылышуыбызга нәрсә сәбәп булды? — дип сорады. Ул да бу хәлләргә нәрсә сылтау булганын белми, күз алдына китерә алмый, аңлый һәм аңлата алмагач, кайвакытларда, аны Зөһрәгә сылтауларга кадәр барып җитә иде. Зөһрә апасыннан ишеткәннәренең барысын да Таһирга сөйләде.

Боларның бер-берсенә шигырьләр әйтешкәннәрен күзәтчеләр күреп, шунда ук хәбәрне Карабатырга җиткерделәр. Ул патшага йөгерде һәм хәлне аңа сөйләп бирде. Ханның бу хәбәргә, шартлардай булып, ачуы кабарды. Шунда ук Таһирны тотып алдына китерергә боерып күп гаскәрләр җибәрде. Гаскәрләр килгәндә Таһир белән Зөһрә бер-берсеннән аерылудан әрнүләре турында шигырьләр әйтешәләр иде. Таһирның кулында коралы юк иде. Гаскәрләр аны тотып бәйләп, ханнары алдына китерделәр. Аны күрүдән котырыныр хәлгә җиткән патша: «Җәллад!» — дип кычкырды. Йөгерешеп килгән җәлладларына: «Хәзер үк мәйданга алып чыгып, бу җинаятьченең башын чабыгыз! Җисме җиһанда калмасын, исеме башкаларга гыйбрәткә калып, һәркемнең моннан соң патша кызы сарае янына рөхсәтсез якынаюдан коты алына торган булсын!» — дип боерды. Шул заман коты алынган вәзирләрнең барысы аяк өстенә торып ханнан Таһирның бер кашык каныннан кичүен үтенделәр. Нәкъ шул көннәрдә ил чигенә хәвефле дошман ябырылып, җыелган гаскәр яуга китәргә тора иде. Вәзирләр: «Таһирның канына кергәнче, аны яуга юлла. Тәкъдирендә үлем язылган булса, ул дошман явы белән алышып һәлак булсын», — диделәр. Мондый киңәш ханга да хуп күренде. Ул: «Канын сезгә багышладым. Ләкин хәзер үк гаскәр белән шәһәрдән юк булсын», — дип боерды.

Ил чигенә кадәрге ерак юлны үткәндә үк иң намуслы, үз көчләренә һәм сәләтләренә ышанучы күп батырлар, дуслык, ихтирам күрсәтеп. Таһир тирәсенә туплана башладылар. Таһир-Зөһрәдән аерылуга илткән көннәреннән, үз хәленнән үртәнә, дөньясыннан күңеле тарсына иде. Ул, барып җиткәч тә, дошман сафлары өстенә ташланып, көрәштә тизрәк шәһид китү турында хыялланды. Ул шулай итте дә: килеп җитү белән ял итеп, урнашып-төпләнеп тә тормастан, каршы як яубашының җансакчылары өстенә ташланды. Әмма дус батырлары аны ялгыз калдырмадылар. Үз батырларына ярдәмгә, яклашырга акрынлап барлык калган гаскәрләр дә тартылдылар. Бу хәлләр көн саен кабатлана торган булды. Шул рәвешчә, Таһир, гамәлдә, һәр бәрелешне оештыручы, аның үзәгендә кайнаучы хакыйкый яубаш булып калды. Сарай тирәсендә үскән ир бала буларак, ул даирә гадәте буенча, Таһир сабый вакытларыннан ук, кылыч, ук, сөңге сугышларын, хәрби белемнәрне өйрәнеп үскән иде. Зирәк, сәләтле бала буларак, ул һәр күрсәтмәне шунда ук үзләштереп ала, үзенә хас бер пөхтәлек белән үти белә иде. Шуңа күрә, бу яу кырында да ул каршы якның һәр корган хәрби хәйлә-мәкерләрен шунда ук сиземләп ала, алар юлына үз каршылыгын куя торган булды. Һәр каршылык күрсәткән урынында ул дошманнар өстенә үзен һәлак итәргә теләгәндәй, ярсу арысландай ташлана. Каршы як аңа каршы күпме генә көч ташласа да ул каушамый, курыкмый, корыч кыядай, какшамас бер хәлдә, кирәк булса, көне-төне дошманнарын тураклый да тора. Кайсы якка гына ташланса да, дошманнар һаман шул какшамас корал алмас корыч кыяга килеп бәрелә һәм җимерелә иде. Гаскәр башы булып килгән Карабатыр да Таһирның бу тырышлыкларының үзенә файдалы икәнен бик тиз аңлады. Ул Таһирның яубаш булып китүенә каршылык күрсәтмәде. Хәер, моңа аның рөхсәтен-ризалыгын сорап торучы да булмады. Карабатыр бик тиз үзенә лаеклы эш табып алды: кайда бәрелеш башланмакчы булса, шунда ул һөҗүмгә үтү турында боерыклар, күрсәтмәләр язып җибәрә; бәрелеш туктагач, Таһирны һәм аеруча тырышлык күрсәткән батырларны күп югалтуларга сәбәпче булуларында гаепле һәм шелтәле; ханга бу бәрелешләр һәм аларның нәтиҗәләре турында, Таһирның һәм батырларның үзенә буйсынмаулары, дуамаллыклары турында хәбәрләр һәм әләкләр язып тора иде. Сугыш-бәрелешләр турындагы хәбәрләрдә

җиңүләр, әлбәттә, Карабатыр һәм аның якыннары эшчәнлеге нәтиҗәсендә генә мәйданга килә иде. Шул рәвешчә, ул Таһир һәм батырлар ирешкән һәр җиңү өчен үзенә һәм якыннарына һәр көнне ханнан рәхмәтләр һәм бүләкләр ала, яуда үзе җиңүче булып калырга җирлек әзерли иде. Карабатырның бу яудагы шаккатыргыч батырлыклары, яулаган җиңүләре турында хәбәрләр, искиткеч хикәяләр шулай Алтын Сарайдан бөтен илгә тарала, ишәя, бүртә башлаган иде.

Дошман илнең патшасы үзе дә бу яуга чыккан икән. Үзенә үлем тынычлыгы эзләгән Таһир беркөнне тапкырлыкның соңгы баскычына омтылып язмышын сынамакчы булды: дошманның патшасын кулга төшерергә уйлады. Дус батырларын ияртеп ул, һич нинди каршылык белән хисаплашмастан, соңгы чиктәге киеренкелек һәм тапкырлык белән, патша чатыры ягына ташланды. Ук һәм кылыч яраларыннан тиресе иләктәй тишкәләнеп бетсә дә, ул дошман каршылыгын җимереп, патша чатырына барып җитте, кылычы белән үзәк терәген чабып патша чатырын аударды һәм үзе дә, хәлсезләнеп, шунда егылып калды. Бу хәлләр патшага мәхшәр дәһшәтеннән көчлерәк тәэсир итте: үлеме табанына басып кугандай ул гаскәре яныннан өч көн һәм өч төн ераклыктагы тыныч урынга качып китте һәм шунда ук үзен сакларга бар гаскәрләрен үз янына чакырып алды да, кичекмәстән килешү турында сөйләшүләр башларга боерык бирде. Бабахан гаскәре ягыннан бу сөйләшүләргә, билгеле, яу башы Карабатыр үзе җитәкчелек итте. Җиңелгән һәм курыккан чит патша, дуслык билгесе итеп, үзе ташлап качкан җирләрен, шундагы Мәрдин дигән шәһәр белән Бабахан ихтыярына тапшырырга риза булды.

Бу казаныш нәтиҗәсендә, Карабатыр моңарчы бер кеше ирешә алмаган дан, дәрәҗә яулады. Бер үк вакытта ул Таһир һәм аның иң якын дусларыннан котылу юлын уйлады. Патша белән язышып, аны яңа яуланган Мәрдин шәһәренә хаким итеп билгеләтте. Алтын Сарай капкасына кайтып җиткәч, Таһир кулына ханның шул хактагы боерыгын китереп тоттырдылар: «Ул яңа биләмәне җуймас өчен, кичекмәстән, шул минутта ук юлга кузгалырга», — диелгән. Хан телдән генә: «Бу шәһәргә аяк басмасын һәм кайтырга уйламасын. Әгәр дә кайтканын ишетсәм, шул минутта тотып башын чаптырырмын!» — дигән. Таһирның тиресе иләктәй телгәләнгән, ат өстендә утырырлык хәле булмаса да, төя өстенә ятак җәйлап аны шунда салдылар, якын дусларын озата барырга җансакчылар итеп билгеләделәр дә, ерак юлга озаттылар. Шәһәр һәм хан, олы бәйрәм ясап, зур тантана белән, җиңүче итеп, шау-гөр килеп Карабатырны каршыладылар…

Яуда Таһир үзенең илгә терәк, таяныч була алырлык, җиңү яулап бирерлек ир булганын күрсәтте. Бабахан шундый хакыйкый, ышанычлы таянычны читләштереп, аны ялган, ясалма батыр курчакка — Карабатырга алыштыруы белән иленең, дәүләтенең яшәү тамырына үз кулы белән балта чапты, үз тәхете нигезен үзе җимерде…

Таһирның китү юлы Зөһрә солтан сарае алдыннан үтә иде. Сарай тәрәзәсенә карап, Зөһрәгә атап ул бер шигырь әйтте:

Әтиең вәгъдәсен бозды, утларга ташлый безне.
Дошман дип, читкә сөрде, кабат күрешербезме?
Ир-егетләр ирлеген, үлмәенчә куярмы?
Күңел куйган ярыннан, үлмәенчә туярмы?
Мәгъшук ярын күрмичә егет күңеле тынармы?
Аерылырга ярыннан, үлмәй, буенсынармы?
Рәнҗү михнәт күрермен, яр юлында үлермен.
Үлем күзем йомганда, мәхәббәттә сүнермен.

Зөһрә Таһир тавышын ишетеп, йөгереп килеп тәрәзләрен ачып җибәрде, күзләрен яшь илә тутырып, бу шигырьне әйтте:

Аргамакка менәсең, ерак җирләр үтәсең, –
Гашыйк ярың Зөһрәне кемгә ташлап китәсең?
Алтын сорнай кулыңда, атлы гаскәр уңыңда,
Кызыл гөлләр ачылсын, Таһир, йөргән юлыңда.
Хозыр булсын юлдашың, бәхет булсын кулдашың,
Сагынганда, Таһирым, былбыл булсын моңдашың.
Исән булсын башыгыз, йөзгә җитсен яшегез,
Ерак җирдән бу илләргә бәхет-хәбәр чәчегез!

Зөһрәнең бу якты теләкләрен ишетеп, үз хәлләре һәм язмышлары турында, Таһир беренче кат, уйланып калгандай булды, тетрәнеп куйды һәм Зөһрәгә болай җавап кайтарды:

Мәхәббәттә пакь без, саф, сәләтле дә, көчле дә, –
Бу заманда, бер ихтыяҗ бармы безнең төслегә?!
Эше — илгә кирәкмәс, көчебез көнгә кирәкмәс, –
Дөньясына без кирәксез, телгәлибез йөрәк, бәс!
Без барлыкка галәм ярсый, юк итәлсә, сөенә,
Барлыгыңа бер шат зат юк, юк булсаң, кем көенә?
Көчле, дәртле булганга тик, читкә тибәрелгәнбез.
Бу тормышта тере хәлдә юкка чыгарылган без.
Яшәү көчен яшен суккан, көч бар, бернәрсәң дә юк...
Яшьтән өлеш — яшьтән башка, баш ташка бәрсәң дә юк.

Таһир шул уйларга талып, Зөһрә сарае турысыннан үтеп киткәнен сизми дә калды. Кабат борылып караганында, ул Зөһрәнең чарлак тәрәзәсеннән яртылаш чыгып, гүя аның артыннан очып китәргә омтылган хәлдә күреп, бу шигырьне әйтте:

Арттан карап калдың син, сүнмәс утлар салдың син,
Гашыйк ярдан аерылып, еглый-еглый калдың син, –
Ялгызлардан аерылган аккош кебек моңаеп,
Ботагыннан каерылган гөлдәй сулып калдың син.
Канатлары каерылган, ялгызыннан аерылган –
Балачыгын алдырган коштай чу-у-лап калдың син.
Кайда безнең яшь чаклар? Гөлбакчалар? Кочаклар? –
Калды безгә җан әрнеткеч әрнү-сүнмәс учаклар.
Инде хуш, сау бул, ярым, аман-исән бул, ярым,
Җан гашыйгың Таһирга дога кылып тор, ярым!
Китәр юлларым ерак, гашыйк ярым, әлфирак!
Гамь шәрабен бергә эчкән миһербаным, әлфирак!
Карасам, күзем җитмәс, әйтсәм, сүзем ишетелмәс
Кайгың исемнән китмәс, Зөһрәҗаным, әлфирак!
Яр-моңдашым, онытма! Җан юлдашым, онытма!
Бергә йөргән, бәхет күргән сукмакларны суытма!
Кайгы, гамем бүлгүче, сине — серләр белгүче
Тапшырамын Аллага! — Син дә мине онытма!

Таһирның күзләреннән ачы яшьләр сытылып чыкты. Бу хәлне күреп озата баручыларның да күзләре чыланды. Яшьләрен яшерер өчен алар башларын түбән иделәр яки читкә карадылар. Туган яклардан ераклашкан саен Таһирның гыйшык дәртләре дә куәтләнгәннән куәтләнә иде. Чыдамы калмагач, ул кулына алтын сазын ала, япан кырларны иңрәтеп моңлы көйләр уйный яки Зөһрә гүзәллекләре турында шигырьләр әйтә иде. Юлаучы адәмнәр, тәэсирләнеп, аның бу моңлы көйләрен, җырларын отып калалар иде. Шул рәвештә юл кичеп, җиденче көннең

кичендә болар Мәрдин шәһәренә килеп керделәр. Хакимлеге дә, шәһәре дә сөекле ярыннан мәхрүм ителгән Таһирга сакчысыз зиндан булып күренде. Яралары төзәлеп, тәне көчкә килгәнче, ул, яудагы тырышлык белән, эшләрне тәртипкә салды, үзенә алмаш — ышанычлы бер хаким әзерләде. Җәрәхәт җөйләре төзәлгәч, шәһәрне һәм эшләрен үзе әзерләгән хакимгә тапшырды да, Зөһрәдән аерым яшәргә чыдамы калмаган Таһир, гади көтүче киемнәре киенеп, аргамагына атланып туган якларына кайтып китте.

Зөһрә дә Таһирдан аерылуны бик авыр кичерде. Ул бакчага бармас булды, Алтын Сарайга килмәс иде. Үзенең чарлагына бикләнгән, тәрәзә пәрдәләрен төшергән дә үзенең аерылу-ялгызлык сызланулары эченә чумган. Чыдамы бетеп сабырсызланганда, сазын кулына ала да үз ачы дәртләрен җырга салып сөйли иде:

Гөл идем. Син — былбылым. Очтың. Тирәмдә мыж килә
Ябалак, козгын. Мин калдым син ярымнан аерылып,
Таһирым китте, югалды. Хәстә калдым тилмереп.
Җан — җәрәхәт. Тән дә әрни, син ярымнан аерылып.
Тик синең дәрт җан бирә, сүндерми бу гомерем шәмен.
Кайгы-әрнүләрең татлы, син ярымнан аерылып.

Нәкъ шулчакта Таһир, кайтып җитеп, аргамагын көтүендә калдырып, көтүче киемендәге узгынчы булып Зөһрә сарае алдына килеп, бу җырны җырлап торган икән:

Миһербаным, татлым, балым, табармынмы, ярым сине?
Илләр кичеп, җилдәй исеп, табармынмы, ярым, сине?
Сөрелдем, тик гыйшкым гаеп, зәгъфран кебек саргаеп
Кайтсам, иртә-кич ялбарып табармынмы, ярым, сине,
Әй, гүзәлем, көмеш сәнам! Тик син җаным, мин тик бәдән.
Сине диеп кайткан адәм, табармынмы, җаным, сине.
Һәр сулуда тик син истә, югалтмыйм йокыда, кичтә.
Аерылмаслык булып һич тә, табармынмы, ярым, сине.

Таһир тавышын ишетеп, Зөһрә, кыш уртасында көтмәгәндә чәчәк аткан якты гөл кебек балкып, тәрәзләрен ачып җибәрде. Әйе, сарай алдында саз уйнап шигырь әйтеп Таһир басып тора иде. Үзен-үзе белештермәстән ул урамга атылды. Алар бөтен дөньяларын онытып бер-берсенә үзләренең сагыну-зарыгуларын, дәрт-хәсрәтләрен, сагыну-сагышларын — гашыйклык хәлләрен сөйләргә тотындылар. Вакытны да, кайда икәнлекләрен дә бөтенләй оныттылар. Бу минутта алар чиксез бәхетле иде, шат иде...

Әмма хан әләкчеләре-күзәтчеләре дә йоклап тормадылар. Алар Таһирның кайту хәбәрен шул заманда ук Алтын Сарайга җиткерделәр. Таһирның кайтып кызы белән очрашуы хәбәрен ишетеп хан шундый ярсыды, дәһшәтле тавыш белән «Җәллад!» дип илереп җибәргәнен үзе дә сизми калды. Әмма Таһирның соңгы сугышта ниләр эшләгәне турында хәлнең чынын, хакыйкатьне дә инде ул белеп алган иде. Бу хәлдә Таһирны җәллад кулына тапшыруны ил кабул итмәячәк. Моны ул бик яхшы аңлый иде. Әмма аны ул илдә калдыра да алмый, якында түзеп тора алмый иде. Шуңа күрә, йөгерешеп килгән җәлладларына: «Хәзер үк Зөһрә сарае янына гаскәр белән барып Таһирның аяк кулын чи каеш белән тубыктан касыгына кадәр бәйлисез дә, нык сак астында кабат Мәрдин шәһәренә, инде зинданга озатасыз!» — дип боерды. «Баш өсте!..» — дип гаскәрләр, җәлладлар йөгерешеп киттеләр. Килеп, Таһирны бәйләп егып, чи каеш белән биләүдәгедәй пәрәвезләделәр дә шунда ук, ах-вахына карамый, нык сак астында кабат Мәрдин шәһәренә озаттылар. Көн-төн атларын куып, җиденче көндә Мәрдин шәһәренә барып керделәр. Таһирны зиндан башлыгына тапшырып, сакчылар тапшырган-

нары турында язу алып кайтып киттеләр. Таһир болар артыннан: «Дусларым, Зөһрәгә әйтегез, вәгъдәсен онытмасын...» — дип кычкырып калды.

Таһир гашыйк зинданда төн-көн Зөһрә гыйшкында яна, үз дәртләре турында җырлар җырлый, шигырьләр әйтә, кайчак ул җырларын һәм шигырьләрен кәгазьгә язып зиндан тәрәзәсеннән тышка ташлый иде. Кайбер кәгазьләрне узгынчылар алып укыйлар. Таһир шигырен укыган дәртлеләр күңелендә гыйшык уты кабына, алар бу шигырь һәм җырларны телдән телгә, илдән илгә йөртәләр иде. Зөһрә солтанны сагынып, Таһир бу шигырьне җырлый:

Карагайлы кара урман, — үтәр көнем булырмы?
Кара болыт башымнан китәр көне булырмы?
Михнәт китеп, рәхәтләр җитәр көне булырмы?
Кайгыларның башымнан үтәр көне булырмы?
Җандай газиз ярымны күрер көнем булырмы?
Әүвәлгедәй очрашып йөрер көнем булырмы?
Кара нәркис күзләрен, якты йолдыз күзләрен,
Кызыл гөлдәй йөзләрен күрер көнем булырмы?
Кызыл алма ияген, саф көмештәй сөяген,
Гәүһәр-якут беләген сөяр көнем булырмы?
Синсез кабар ашларым, кызыл канга охшыйдыр.
Якты көннәр күземә, кара төнгә охшыйдыр.

Шулай Зөһрә гыйшкы белән грифтар булып Таһир бу зинданда җиде ел калды. Артык та сабырсызланган минутларда ул мондый шигырьләр әйтеп үзен юата иде:

Михнәт салган Иябез рәхәт бирә алмасмы?
Хәсрәт салган Иябез шатлык бирә алмасмы?
Кайгы биргән Аллабыз аны ала алмасмы?
Бу тәкъдиргә тарыткан рәхмәт күзен салмасмы?
Елама, күңелем, елама, төннәр үтәр, көн килер.
Михнәт үтеп, безгә дә рәхәт җитәр көн килер.
Һәр михнәткә бер рәхәт булса кирәк, иншаллаһ!
Гыйшык биргән Аллабыз кушса кирәк, иншаллаһ.

Таһирны шулкадәр җәберләп, бәйләп алып киткәннәрендә Зөһрә солтан коты алынып, бүлмәсенә кереп һуштан язып егылып калган иде. Йөзенә гөл сулары бөркеп, апасы аны көчкә һушына китерде. Башын тез өстенә салып, апасы аңа күп үгет-нәсыйхәт сүзләре сөйләде, юатты, тынычландырды. Зөһрә дә, тәкъдиргә тән биреп, әүвәлгедәй чарлагына менеп, дөньядан үзен пәрдәләп, туктаусыз Таһир турында уйланып күңелен юата торган булды. Шул рәвешчә, ай артыннан айлар, ел артыннан еллар үтә торды.

Дәвамы бар

Текстны басмага
***Мәсгут Гайнетдин** әзерләде.* ■

Кыйссаны тулысынча www.beznenmiras.ru сайтында укырга мөмкин.

БӘРӘКӘТЛЕ ОРЕНБУРГ ТУФРАГЫ

Лирон Хәмидуллин

Дәрдемәнд. XX гасыр башы

1

Милләтебезнең рухи күтәрелеш чорында бу хәрәкәткә үз өлешләрен керткән шәхесләребез байтак. Дини, иҗтимагый-сәяси һәм тарихи хезмәтләре белән башка төрки халыклар арасында да дан казанган Шиһап Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйрилар тәрбиясендә үскән буын исә татар әдәбияты үсешенең яңа тармагын — роман, повесть, хикәяләр иҗат итүне башлап җибәргән. Әдәбият гыйлемендә «чәчмә әсәрләр яки проза, драма әсәрләре» дип билгеләнгән бу өлкәдә беренче уңышка ирешкән авторларыбыз арасында иң күренеклеләре — Муса Акъегетзадә һәм Заһир Бигиев (икесе дә Пенза төбәге кешеләре). Аларның «Хисаметдин мелла» белән «Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә» романнары бер-бер артлы 1886, 1887 елларда Казанда дөнья күрә. Татарлар арасында беренче проза әсәрләре тууга урыс һәм төрек әдәбиятлары үсеше дә үрнәк булган, этәргеч биргән, дигән фикер безнең әдәбият тарихын барлаучылар тарафыннан әйтелгәләде инде.

Шул фикерне күпмедер дәлилләр өчен Дәрдемәнд һәм аның Шакир агасы хатларыннан берничә җөмлә китерү дә җитәдер, мөгаен. (Мәгълүм ки, Закир Рәмиев-Дәрдемәнд 1880-1881 елларда Төркиядә укып йөргән. Ике бертуган еш кына хат алышкан.) Менә Шакирның 1881 елда энесенә язган мәктүбеннән кайбер җөмләләр: *«Безнең халык өстендә чапан, башында чалмасы булмаган кешенең сүзенә игътибар итми. Халыкка һәртөрле әхвәлне аңлата торган китапларны укырга кирәк. Шуңа күрә дә фәһем алырдай китапларны, романнарны күбрәк алып кайта күр»*, — дип язган ул. Шул ук зыялылар арасында бу елларда: «Татарлар арасында хәзер чалмалы муллалар җитәрлек, чалмасыз муллаларга кытлык», — дигәнрәк әйтем дә йөргән. «Чалмасыз муллалар», ягъни киң белемле затларның халыкка күбрәк файда китерәчәге, халыкның рухи үсеше өчен дини, гыйльми китаплардан тыш әдәби эчтәлекле хезмәтләрнең дә кирәклеге турында җитди сүз йөртә алар. Муса Акъегетзадә һәм аның чордашлары тудырган әдәби әсәрләрне укып үскән икенче, өченче буын вәкилләре исә мондый фикерләрне тирәнәйткән, баеткан әсәрләр тудырырга хыялланган.

Бу язмамда мин Дәрдемәнд һәм аның абыйсы Шакир Рәмиев даирәсенә кергән, алар белән бер дәвердә яшәгән, кулга-кул тотынып эшләгән шәхесләрнең кайберләре — узган ике гасыр аралыгында әдәби әсәрләре белән дә танылганнары — хакында язмакчы булдым. Монда искә алыначак ул кешеләрнең барысы да диярлек Оренбург каласында яшәгән, алар тудырган әсәрләрнең дә күпчелеге шушы төбәктә иҗат ителгән. Соңрак бу төбәкнең бәгъзе шәхесләре белән кискенрәк мөнәсәбәттә булган Гаяз Исхакыйның да узган гасыр башында берникадәр вакыт шунда яшәвен, «Хөсәения» мәдрәсәсе хәлфәсе булуын, кимендә ике әсәрен (шул исәптән «Ике йөз елдан соң иңкыйраз»ын да) шунда иҗат иткәнлеген танырга тиешбез. Аның тәүге әсәрләреннән «Бай углы» романы, «Ике гашыйк» комедиясе һәм ул чорда «озын хикәя» жанрында йөргән «Очрашу» әсәре дә шул шәһәрдәге «Кәримевләр басмаханәсе»ндә дөнья күргән.

Сүзне Ризаэддин хәзрәт Фәхреддиннән башлап җибәрик. Берничә дини-тәрбияви эчтәлекле китабы элгәрерәк язылган һәм чыгарылган булса да, аның төп иҗади хәзинәләре Оренбургта язылган һәм шундагы басмаханәләрдә нәшер ителгән. Бертуган Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә аның кырыклап, якын туганнары булган «Кәримевләр басмаханәсе»ндә егермеләп китабы басылып, төрки дөньяга таралган. Аның бертуган Рәмиевләр белән Уфада, мөфтияттә

эшләгән елларда ук дустанә мөнәсәбәттә булуы мәгълүм. Моңа аларның нәселе бер төбәктән чыгуы да, Рәмиевләрнең кайбер буын бабаларының дин әһеле вазифасын үтәве дә ярдәм иткәндер, мөгаен. Риза хәзрәтнең яшьтәше Дәрдемәнд тә төп чыгышы белән хәзерге Әлмәт районына кергән Тайсуган авылыннан бит. Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләрендә бу авылда XVIII йөз башында ук тирә-якка танылган мәдрәсә эшләгәнлеге хәбәр ителә. 1913 елда «Шура» журналында бертуган Рәмиевләрнең шәҗәрәсе басылган. Анда аларның бабалары Габделкәримнең, яңа оеша башлаган Эстәрлетамак өязенә күченеп киткәнче, «Тайсуган төбәгендәге бер авыл имамы» булуы теркәлгән. (Нишләптер хәзерге Әлмәт төбәге түрәләре генә элекке алтын приискалары хуҗалары, танылган матбагачылар — морза Рәмиевләрне үз төбәкләреннән чыккан шәхес дип танып бетерми кебек.)

2

Ризаэддин хәзрәт ул чорда дини, иҗтимагый-тарихи һәм тәрбияви эчтәлекле («Тәрбияле бала», «Тәрбияле ана» һ.б.) хезмәтләр язудан тыш, ике исемдә күләмле генә әдәби әсәр дә иҗат итеп бастырган. Һәм шуларның берсенә (1903 елда чыкканына) танышы, фикердәше Закир Рәмиевнең әсәре икәнлеген белмәстән, «Дәрдемәнд» тәхәллүсе белән кулына килеп эләккән «Үткән көннәр» шигырен дә кертеп җибәргән. Дәрдемәнднең шигыре тәүге мәртәбә «таш басмада» шул рәвешле дөнья күргән. Ризаэддин хәзрәтнең күләмле бу әдәби әсәрләре Уфада, мөфтияттә казый вазифасын үтәгән елларда язылган. Шуңа күрә ул аларны үз исемен яшереп, «Гафил бине Габдулла» тәхәллүсе белән нәшер иткән. «Тәрҗемәи хәлем» язмасында моңа үзе болайрак аңлатма бирә: «Сәлимә...» илә «Әсма»ны галимнәр җәмәгатеннән булган затлар сөймәделәр. (Сүз, әлбәттә, дин галимнәре турында бара. — Л.Х.) Әгәр дә минем әсәрем икәнен белгән булсалар, башыма кыямәтләр кубарачаклар иде. Фәкать авторлары билгеле булмаганлыктан, беркадәр сүрелделәр».

Аның «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәре 1898 елда Казанда, «Әсма, яки Гамәл вә җәза»сы 1904 елда Оренбургта басылып чыккан. Әсма Шәрәф әтисенең бу күләмле әдәби әсәрләрен язарга керешүен түбәндәгечә бәян итә: «Әткәйнең күп еллардан соң сөйләгән сүзләре: «Сәлимә...» белән «Әсманы...» язуыма сәбәп — роман тәртип итү генә түгел иде; бәлки, күңелгә урнашкан файдалы фикерләрне үз телебездә язып, укучыларга ирештерү иде» («Ризаэддин Фәхреддин» китабы, Казан, 1999).

Сүз уңаенда шуны да искәртеп үтик: бөек акыл иясе алтышар, сигезәр табаклы әсәрләренең, гәрчә нәшер ителгән китапларында «хикәят» дип тамгалануына карамастан, жанр дәрәҗәсе буенча киңрәк, тулырак атамага ия булганлыгын чамалаган икән. Хәер, хәзерге заман әдәбият галимнәре дә ул әсәрләрне «повесть» яисә «роман» дип билгеләү ягында.

XIX йөз ахыры белән XX йөз башларында проза жанрында иҗат итүчеләр саны бермә-бер арта. Оренбург төбәгенә бәйләнеше булган язучылардан бу чорда Гаяз Исхакый, Александр Пушкинның «Капитан кызы» һәм Николай Гогольның «Борынгы алпавытлар» әсәрләрен тәрҗемә кылып каләм чарлау белән бергә, бер-бер артлы хикәя, бәян, романнар да тудырырга керешә. XIX гасыр ахырларында аның ике хикәясе, бер романы («Бай углы»), «Өч хатын белән тормыш» драмасы аерым-аерым китап буларак басылып чыгалар. Фатих Кәрими дә бу елларда бик актив эшли. Ике гасыр аралыгында аның «Салих бабайның өйләнүе» (1897), «Җиһангир мәхдүм» (1900) хикәяләре, «Бер шәкерт илә сту-

1914 елның җәендә Дәрдемәнд (уңнан беренче) **кызы Зәйнәп** (сулдан өченче)**, Шакир абыйсының кызы Камилә** (уңнан өченче) **һәм аның ире Садри Максуди белән Европа илләре буйлап сәяхәт кыла. Сәяхәтләрен Төркиядә тәгәллиләр. Шул елда бертуган Рәмиевләрнең уллары Европаның югары уку йортларында укыган була. Бельгиянең Льеж университетында бу чорда Шакир улы Әхмәт-Мидхәт** (сулдан беренче) **белән Дәрдемәнд улы Гариф** (сулдан дүртенче) **укый. Шагыйрь улы Искәндәрнең** (сулдан икенче) **Германиядә укып, инженер дипломына ия булган чагы.** Фото Льеж шәһәрендә төшерелгән

дент» (1899) һәм «Мирза кызы Фатыйма» (1901) повестьлары нәшер ителә. Соңрак «Хыялмы? Хакыйкатьме?» повесте (1908), «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902), «Кырымга сәяхәт» (1904) һәм Балкан сугышы вакыйгаларын чагылдырган «Истанбул мәктүпләре» (1913) дөнья күрә. Ул шулай ук бер дистә чамасында дәреслек, ике дистәдән артыграк исемдә фәнни-популяр китап һәм тәрҗемәләр авторы да. Әдипнең соңгы тәрҗемә хезмәте буларак утызынчы еллар башында башкарган тагын бер эшен билгеләп үтәргә кирәктер. 1992 елда Галимҗан Ибраһимовның без төзеп чыгарган «Казакъ кызы» китабында олуг әдипнең Мәскәү түрәләренә атап урысча язылган күләмле бер хаты (тәрҗемәдә) китерелде. Ул әле телгә алынган романны урысчага аударучы Фатих Кәрими эшеннән канәгать булмавын белдерә. Аның кульъязмасын типографиягә төшерүгә мин каршы киләм, ул әсәрне урыс әдәбиятын яхшырак белгән башка кеше тәрҗемә итәргә тиеш, ди. Фатих Кәриминең бу хезмәте шул рәвешле юкка чыгарыла. Әмма безгә аның шундый эшкә алынып каравын хәтердән чыгармаска кирәк, билгеле.

Фатих белән бер үк чорда Чистайдагы Закир ишан мәдрәсәсендә белем алган Галиәсгар Гафуров-Чыгытай да шәриктәшеннән калышмаска тырышкан, күрәсең — тиздән матбугатта аның «Тутам» повесте дөнья күргән. Бу әсәрне язган чакта авторның Бозаулык шәһәрендә мәчет имамы булып торуын искә алырга тиешбез. Шушы яшь мулланың яңа төр мәктәпләр ачуга күп

көч һәм акча түккән Гани бай Хөсәенев белән берлектә, 1898 елда үз каласында яңа ысул белән укытырга тиешле мөгаллимнәр курсын оештыруын да онытмасак икән.

Әлбәттә, бу елларда Дәрдемәнд, Ризаэддин хәзрәт, Гаяз Исхакый, Фатих Кәримиләрдән аерымрак төбәктән — Буа тирәләреннән чыккан Шакир Мөхәммәдевны һәм аның хезмәтләрен дә атамый үтү гөнаһ булыр иде. Ике гасыр аралыгында ерак Харбин каласында гомер иткән Шакир да (Оренбург Каргалысындагы мөгаллимнәр хәзерләү мәктәбендә Фатих Кәрими курсларын үткән элекке шәкерт) бербер артлы ике повестен бастырып чыгара: «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай»ны — Казанда (1901), «Яфрак асты, яхуд Мәкәрҗә ярминкәсе»н — Оренбургта (1901). Шуннан соң янә Оренбургка кайтып төпләнә һәм биредә шактый актив иҗат итә башлый. Берара «Карчыга» исемле көлке-сатира журналын да нәшер итә.

3

Элек Оренбург төбәгендә яшәп иҗат иткән шәхесләрнең эшчәнлеген барлау өлкәсендә беркадәр сүлпәнлек сизелә кебек. Фактлар турында язганда төгәлсезлекләр дә очрап куйгалый. Кайберәүләрнең әдәби эшчәнлеге, әдәби талпынышлары исә күп очракта телгә дә алынмый. Мәсәлән, Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Хөсәен Ямашевлар белән бер чорда Казан Укытучылар мәктәбендә укыган, узган гасыр башларында иҗат җимешләре беркадәр күренгәләгән шәхесләрдән Габдерахман Дәүләтшин (балачактан ук Әхмәт Хөсәенев өендә тәрбияләнгән), Шакир Мөхәммәдьяров (Орск шәһәрендә туган), Габдерәүф Ниязбаев (Оренбург Каргалысында туган) исемнәрен алыйк. Ул заманда аларның үз драма әсәрләре дә, Александр Пушкин, Николай Гоголь, Александр Островскийларның әсәрләреннән тәрҗемәләре дә яңа туып килүче театр сәхнәсеннән төшмичә уйналган, газеталарда әдәбият, мәдәният темасына язган хезмәтләре даими рәвештә басылып килгән бит! Болар төркеменә шул ук уку йортын тәмамлаган, иҗади хезмәткә бәйле еллары шул ук Оренбург каласында узган Тимерша Соловьёвны да, кайбер истәлекләрдә «Бозаулык каласы сәүдәгәре» буларак кына теркәлгән Ярулла Вәлине дә кертергә хаклыбыз.

Татар энциклопедиясенең бер томында «издатель, журналист» буларак кына теркәлгән Тимерша Салаватулла улы Соловьёвның да иҗат юлы хикәя, бәяннар иҗат итүдән башланган. Ниһаять, энциклопедиянең V томында (2010, 378 бит) аңа багышланган мәкаләне уку өлешчә генә булса да күңелне сөендерде. Димәк, ул да искә алынган. Ә «Әдипләребез» белешмәлегенә, нишләптер, аны кертмәгәннәр дә. Кайбер хезмәтләрен «Саллави» тәхәллүсе белән дә бастырган бу шәхеснең татар әдәбияты, татар мәдәнияте өлкәсендә хезмәтләре кечкенә түгел. 1900 елда Оренбургта татарча басмаханә ачкан элекке ахун Гыйльман Кәримевнең икенче кызы Гасыйманың ире (димәк ки, Фатих Кәримигә дә, Риза хәзрәт Фәхреддингә дә кияү) булган әлеге зат байтак еллар «Кәримевләр басмаханәсе»нең мөдире дә булып тора. Белгечләр бу басмаханәдә йөз җитмештән артыграк татарча китап басылган, дип саный. Шуларның күпчелеге, минем исәпләвемчә, Казандагы Укытучылар мәктәбендә белем алган Тимерша Саллави фатихасы белән чыккан булырга тиеш. Мәдрәсәләр өчен урыс теле һәм әдәбияты хәлфәләрен әзерләүче әлеге мәктәптә ул елларда байтак кына булачак татар зыялысы укыган. Хәтернең иң өске өлешендә сакланганнарыннан Г.Исхакый, С.Максуди, Ш.Мөхәммәдьяров, Х.Ямашев, Ф.Туктарларны кабат атап үтү зыян итмәс.

Мәрхүм академик Әбрар Кәри-

муллин — татар телендә китап басу эшен төпле өйрәнгән шәхес. Ләкин Оренбург архивлары белән якыннанрак таныш булмавы сәбәплеме, яисә «Кәримевләр басмаханәсе»н яшәтүчеләрдән Фатих Кәримигә күбрәк өстенлек бирүеннәнме, «Тимершаһ кияү»нең эшчәнлеген ул беркадәр күләгәдәрәк калдыра кебек. Әбрар аганың Оренбург басмаханәләренә багышланган кайбер фикерләре белән килешмәвем турында мин хәбәр иткәләдем инде. Мәсәлән, ул Рәмиевләр басмаханәсендә Риза Фәхреддиннең 24 китабы басылып чыккан, дип яза. Дөреслектә алар 39 данә. Башка чыганакларда шулай диелә. 1999 елда нәшер ителгән соңгы китабында Әбрар ага Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсенең фактик хуҗасы — Фатих Кәрими, нинди китапларга юл ачуны ул хәл иткән, диебрәк яза. Бер байга яллаңган хезмәтче ничек хуҗасының мал-мөлкәтенә хуҗа була алсын икән? Бигрәк тә үзе дә әдәбият өлкәсендә каләм тибрәткән хуҗаның кул астында эшләгән килеш? Шул ук китабында галим, атасы вафатыннан соң Фатих Кәрими «Кәримевләр басмаханәсе»нең төп хуҗасы булып кала, китап басу тәртибен ул гына хәл итә, дигәнрәк фикер үткәрә. Дөрес, 1902 елның җәеннән 1906 елга чаклы басмаханә белән җитәкчелек итү Фатих мәхдүм карамагында була. Энеләре дә, «Тимершаһ кияү» дә ул чорда аның кул астында йөри. Әмма тиздән Гариф Кәримов Мәскәү, Камиле Казан университетларында укый башлый. Димәк, Оренбургтан китә. Кул көче кулланып эшләтелгән иске басмаханә ике кеше карамагында кала. Атасы вафат булгач


МИЛОСТИВЫЙ ГОСУДАРЬ

Мухамедъ-Фатихъ Гильмановичъ.

Издавая на татарскомъ языкѣ газету "ВАКТЪ" и журналъ "ШУРО", я лично за себя и въ качествѣ уполномоченнаго брата своего Орскаго купца – Мухамедъ-Шакира Мухамедъ-Садыковича Рамѣева, симъ уполномачиваю Васъ на слѣдующее: управлять конторой и редакціей вышеозначенныхъ изданій, завѣдывать кассою, нанимать служащихъ, приглашать сотрудниковъ и на – время своего отсутствія, редактора, условится съ ними, разсчитывать ихъ получать и принимать денежную, заказную, и другую корреспонденцію, – посылки, клади и товары присылаемые на имя газеты "ВАКТЪ" и журнала "ШУРО", покупать нужные для изданія ихъ предметы, бумаги и другіе товары, нанимать помѣщенія. Открывать въ банкахъ текущіе счета отъ имени вышеназванныхъ изданій, подписывать чеки, получать переведенныя – черезъ банкъ по адресу ихъ деньги. Предъявлять иски къ разнымъ лицамъ ходатайствовать повсѣмъ дѣламъ касающимся изданія означенныхъ газеты и журнала, въ судебныхъ и административныхъ учрежденіяхъ и у должностныхъ лицъ, выступать отвѣтчикомъ отъ лица газеты и журнала противъ – другихъ. Довѣренность эту можете передовѣрять другимъ лицамъ съ правомъ дальнѣйшаго передовѣрія, что Вы или повѣренные Ваши учините, я вѣрю, спорить и прекословить не буду.

Довѣренность эта принадлежить крестьянину Мухамедъ-Фатиху Гильмановичу К а р и м о в у.

За себя и по довѣренности отъ брата Орскаго купца Мухамедъ-Шакира Мухамедъ-Садыковича Рамѣева Орскій купецъ Мухамедъ-Закиръ Мухамедъ-Садыковичъ Рамѣевъ

Оренбург нотариусы раслаган бу хат 1908 елда Закир Рәмиев-Дәрдемәнд тарафыннан Фатих Кәримигә юлланган. Нотариус расламасы алдыннан Дәрдемәнднең кул тамгасы бар

(май, 1902 ел) йортларын, сыер, атларын сатканнан һәм Шакир Рәмиевтән өч мең сум акча алып торганнан соң, бу типографиягә тагын бер искерәк станок та алына. Ләкин уңышлы эшләп китү өчен ул чаралар да җитәрлек булмый, басмаханә зур табыш китерми. Алынган заказларны үтәү вакытлары бик еш кичектерелә, басма китапларның сыйфаты да күпләрне канәгатьләндерми. Шуның өстенә Фатих Кәримине 1906 елның февралендә «Вакыт» газетасы мөхәррире итеп билгелиләр. Аның үз басмаханәсе белән шөгыльләнергә вакыты калмый, шунлыктан ул бу эштән

бераз читләшә. Басмаханәгә иркенрәк бина, яңарак җиһазлар алу нияте белән алар сәүдәгәр Мәхмүд Хөсәенев гаиләсенә мөрәҗәгать итәләр. 1906 елда «Кәримев, Хөсәенев вә шөрякәсе» ширкәте оештырыла. Аның рәисе итеп Мәхмүд бай улы Хөсәен билгеләнә. Ул, нигездә, китап сатуны оештыру, башка төбәкләрдә басмаханә филиалларын ачу һәм тоту (мәсәлән, Уфада) өчен җаваплы була. Тимерша Соловьёвка төп басмаханәнең мөдире вазифасын үтәү йөкләнә.

2000 елда «Рухият» нәшриятында дөнья күргән «Фатих Кәрими» китабындагы бер истәлеккә күз төшерик. Туксан бишенче бит. Истәлек авторы — Фатих мәхдүмнең иң кече сеңлесе Закирә (Казан матбагачылары Шәрәфләрнең кечесе — Борханы 1908 елда Оренбургка сөргенгә җибәрелгәч, шуңа кияүгә чыккан кыз). Ул гасыр башындагы хәлләрне болайрак бәян итә: *«Типографиягә Хөсәеневләр кушылгач, матди ягы бераз төзәлә. Алынган эшләрне вакытында өлгертү, пөхтәлек арта... Шул елның ахырындарак типографияне яңадан үстереп... бер юристның йортын арендага алып, чын техника белән эшли торган типография корып җибәрәләр... Шулчакта Фатих абзый, үз өлешенә булган пай акчасын алып, бөтенләй басмачылыктан чыга, аерыла. Кәрван-сарай урамында кечерәк йорт сатып ала... (Шуннан соң) күбрәк вакытын өендә язу, тәрҗемәләр белән мәшгуль була, Шакир Рәмиевнең өч баласын укыта».* (Ул яшәгән йортны барып күргәнем бар, бигүк кечкенә, дип әйтмәс идем. — Л.Х.) Әдип сеңлесе язмасының соңгы җөмләсен ачыклап китү сорала. Билгеле, Фатих Кәрими бу елларда өйдә генә утырмаган. Бу истәлектә аның сәгать икеләрдән соң кылган гамәлләре бәян ителә. Аңарчы ул «Вакыт» газетасы редакциясендә эшли. Закирә ханым Фатих Кәриминең «Кәримевләр басмаханәсе» ширкәтеннән чыгу вакытын төгәл әйтми, 1906 ел вакыйгаларына бәйләп кенә язып үтә. Башка бер чыганакта Кәриминең бу ширкәттән чыгу вакыты итеп 1909 елның беренче яртысы күрсәтелгән. Мөгаен, бу вакытта инде ул басмаханә эшчәнлегенә бәйле мәсьәләләрдә «Тимершаһ кияү» белән дә килешә алмагандыр. Закирә ханым да бит шул ук язмасында: «Озакламыйча Фатих абзый белән эшләгән наборщиклар да, мөдир белән килешә алмыйча, чыгып китәләр», — дип яза. Әмма мөдир җизнәнең исемен атап тормый.

«Татар энциклопедиясе» китабының татарча III томында «1914кә кадәр басмаханә белән Ф.Кәрими идарә итә» дигән сүзләр теркәлгән. Ул мәкаләгә башка төр төгәлсезлекләр дә хас. Әйтик, анда Фатих мәхдүмнең «йөзгә якын китабы үзләрендә басылган» кебегрәк әйтелә. Дөреслектә аның 1918 елга чаклы нәшер ителгән алтмышлап-җитмешләп китабының берничәсе Казан, Петербургта һәм унлабы, шул исәптән 450 битле «Истанбул мәктүбләре» Рәмиевләр басмаханәсендә чыккан. Димәк, бу мәкалә дә Әбрар аганың хаталарына нигезләнеп язылган булып чыга. Мәкалә авторы күрсәтелмәгән. Тимерша Саллавиның Кәримевләр басмаханәсендә тулы хуҗа булуы хакында Зариф Бәшири истәлекләрендә дә телгә алына («Замандашларым белән очрашулар», 1968).

Бу шәхеснең туган авылы хәзер Кайбыч төбәгенә караган Шүшермә була. Аның атасы Салаватулланың соңрак Апас тирәлегендә яшәвен әйтүчеләр дә бар. Тимершаның бер улы Казанда, икесе Мәскәүдә гомер иткән. Оренбург төбәге шәхесләрен барлаучы Мәдинә Рәхимкулованың 1980 еллар ахырында хәбәр итүенчә, Мәскәүдәге улларының берсендә Тимерша аганың зур архивы сакланган була. Анда «Шура», «Чүкеч» һәм башка мәҗмугалар төпләмәләре, «Вакыт» газетасы бәйләмнәре булган. 1993 елда, Мәскәүгә Бәшир Рәмиев

(Дәрдемәнднең оныгы) белән очрашуга барганда, мин ул кешене эзләп тә караган идем. Мәдинә апа миңа аларның исемнәрен, телефоннарын язып биргән иде. Әмма Мәрзия ханым (Тимерша Соловьёвның кайсыдыр улының җәмәгате) миңа ул ике бертуганның шушы елларда бакыйлыкка күчүен әйтте, «архив сакланган өй хуҗасы соңгы вакытларда ялгыз яшәде, ул вафат булганда мин Казанда, туганнарымда кунакта идем; соңрак аның фатирын башка кешеләр алган, архивы юкка чыккан», дип сөйләде. Мөгаен, шулай булгандыр да. Тимерша ага үзе 1947 елда, җитмеш ике яшендә Мәскәүдә җан тарта.

Энциклопедиянең урысча V томында, Тимерша агага багышланган мәкаләдә дә: «Ул Түбән Новгородта да яшәде, фәлән кунакханә мөдире булды», — дигән җөмләне ачыклыйсы иде, минемчә. Дөрес, бу шәһәрдә Әхмәт бай Хөсәенев зур бер кунакханә тоткан. Аннан килгән керемне «Хөсәения» мәдрәсәсен яшәтү өчен кулланган. Әхмәт бай исән чакта да, ул үлгәч тә (1906 ел) бу кунакханәнең исәп-хисап эшләрен шул байның конторасында да эшләүче Тимерша ага башкарган булса кирәк; һәрхәлдә, кайсыдыр елларда шул кунакханәнең мөдире вазифасын да үтәгән. Ләкин ул анда озаклап яшәдеме икән? Юк бугай. Белүемчә, аның «бурычы» — кунакханәне Мәкәрҗә ярминкәсе көннәренә әзерләү һәм ярминкә кунакларын урнаштыру, ашату-эчертүне күзәтү-тәэмин итүдән торган. Шул эшләрне башкаруда ярдәмләшү өчен ул, гадәттә, каникулга чыккан мәдрәсә шәкертләрен дә үзенә иярткән. Тимерша-Гасыйма гаиләсенең бу шәһәрдә чынлап торып яшәве турында бернинди истәлекләрдә телгә алынмый. Дөрес, җәйге айларда, ярминкә көннәрендә кунакханә мөдиренең анда көн итүе беркемне дә шаккатырмый, әмма гаилә башлыгы шул вазифаны башкарудан киткәч, алар биредә калдымы икән? Бусын ачыклыйсы иде.

Тимерша Соловьёв-Саллавиның китап рәвешен алган вә барланган әдәби иҗат үрнәкләрен искә төшерик. Кесә дәфтәренә теркәлгән бер язмамда «аның беренче китабы «Хикәят» (1900) дип кенә аталган», дигәнмен. Энциклопедиядә, Марсель Әхмәтҗанов мәкаләсендә исә дүрт китап исеме теркәлгән. Шуларның өчесе — әдәби эчтәлекле әсәрләр китабы: «Мужик илә мулла...» (1902, Оренбург), «Биби Казан» (1905) һәм «Ишан Хәдичәсе» (1906). Болар хикәяме, кечерәк күләмле бәянмы (ул заманнарда бәянны «озын хикәя» рәвешендә дә тәкъдим иткәннәр), әллә соң романнармы — әйтә алмыйм. Әсәр жанрлары энциклопедиядә дә теркәлмәгән. «Мәктәп вә мәдрәсәләрне Духовное собраниегә бирү» китабы (1908), әлбәттә, безнең темага керми. Тимерша Саллавиның үзе нәшер иткән «Чүкеч» һәм башка мәҗмугалар битләрендә дә аерым әдәби парчалары, юмор-сатира әсәрләре басылган булырга мөмкин. Ләкин алар әлегә барланмаган, ахры. Ә узган гасыр башында Оренбургта чыккан татар матбугаты тарихы тупланган архив Кызыл Урда шәһәрендә саклана, дигән хәбәр бар. 1925 елда Казакъстан республикасының башкаласы Оренбургтан шул шәһәргә күчерелгән. Безнең галимнәрдән әлегә ул архив ишеген ачып керүчеләр турында ишеткәнем юк. Ә менә башкорт кардәшләрнең анда да барып җитешкән булуы ихтимал. Соңыннан Уфада яшәп иҗат иткән олуг шәхесләрдән Афзал Таһиров, Давыт Юлтый, Сәгыйть Агиш кебек әдипләр, шул исәптән «Башмагым» кебек комедияләр тудырган Хәйбүш Ибрайларның башлангыч иҗат юлы Оренбург каласына бәйле ич.

4

Татар әдәбиятына багышланган хезмәтләрдә сирәгрәк искә алынган шәхесләрнең тагын берсе Ярулла Вәли буладыр. «Татар әдәбияты тарихы» тупламасының II томында (1985) аның исеме бер урында — Мөхәммәт ага

Гайнуллинның драматургиягә багышланган очеркында телгә алына. Ике гасыр аралыгында иҗат ителгән һәм китап буларак басылып чыккан проза әсәрләрен барлау, бәяләү бүлегендә исә ул автор бөтенләй искә алынмый. Бу бүлекне Флүн Мусин язган булган.

Ә хәзер язучы Ярулла Вәли белән якыннанрак танышыйк. Элегрәк, «Татарстан хәбәрләре» газетасы күренеп алган бер мәлдә, ул шәхес турында кечкенәрәк бер мәкаләм басылган иде. «Татар энциклопедиясе»нең урысча һәм татарча чыккан вариантларында шул язмамның сөземтәсе бирелде. Әлеге мәкалә газетада урын алганнан соң миңа Ярулла Вәлиулла улын якыннан белгән берничә кеше белән аралашырга, аның турында кызыклы истәлекләр ишетергә туры килде. Әмирхан ага Еники дә үз биографиясенә бәйле вакыйгаларны тасвир иткән соңгы әсәрләренең берсендә Ярулла Вәли исемен бик җылы искә алган. Үсмер елларында (Дәүләкәндә яшәгәндә) мавыгып, йотлыгып укыган әсәрләре арасында бу язучының шактый күләмле «Үзеңә кайту» китабы булуын да бәян итә ул. Шушы юлларны укыгач, мин Әмирхан абый белән очрашып та сөйләшкән идем. «Язучы Ярулла Вәлине күреп тә белә идегезме әллә?» — дип сорадым. «Юк, якыннан таныш түгел идек. Аның хәл-әхвәлен болай гына, ишеткәләп кенә беләм», — дип җавап биргән иде әдип. Ул яратып укыган «Үзеңә кайту» әсәренең жанры буенча повестьмы, романмы булырга тиешлеген, нәшер ителгән елы 1913 тирәсендәдер, дип әйтүен бер җирдә теркәп тә куйганмын. «Ул китап минем өстәл өстендә озак ятты, кат-кат укыган идем мин аны. Күршедәге бер кызга күзем төшеп йөргән чаклар иде», — дип сөйләгәне хәтердә.

Узган гасыр башында Ярулла Вәли драмалар авторы сыйфатында да бик популяр шәхес була. Аның ике әсәре — «Оят, яки Күз яше» белән «Ачлык кушты»сы ул чорда эшләгән барлык театр труппалары тарафыннан да сәхнәләштерелгән, диярлек. Сәхнәгә багышланган гаять тә бай эчтәлекле «Октябрьгә кадәрге татар театры» китабында (1988 ел, 398 бит, авторлары — Б.Гыйззәт, Һ.Мәхмүтов, И. Илялова) Ярулла Вәли һәм аның пьесалары исеме еш очрап тора. Кырык беренче биттәге берничә җөмләгә күз төшереп алыйк. Казанда 1907-1910 елларда «Яшьләр» труппасы актив эшли. *«1907-1908 елларда гына да алар Г.Исхакыйның «Ике гашыйк» һәм «Алдым-бирдем», Г.Камалның «Бәхетсез егет», Я.Вәлинең «Оят, яки Күз яше», Д.Таждаровның «Яшь хатын» әсәрләрен сәхнәләштереп, шактый уңыш һәм популярлык казаналар».* (Искәртеп үтик: соңгы әсәр авторының чын исем-фамилиясе Габдерахман Дәүләтшин була. Тукай Казанга килгән беренче елны аны җылы түшәк, «яхшы гына акча түләнгән» эш белән тәэмин итеп торган, үз нәшриятын булдырган кеше.)

Икенче бер урында, «Сәйяр» труппасының 1910 елда Чиләбе шәһәрендәге гастроле турында язганда «Оят, яки Күз яше» драмасы аеруча уңыш китерә», дигән җөмләне дә укыйбыз. Бу әсәр аерым китап буларак Оренбургта 1902 елда Гыйльман Кәримев басмаханәсендә басылып чыккан. Бу язучының аңа чаклы һәм аннан соң басылган әсәрләре дә башлыча шушы басмаханәдә дөнья күргән: «Мәңгелек мәсҗед» — 1901дә, «Әфиюн» — 1906да, «Җанлы җеназа», «Ахырзаман бәласе» һәм «Урман әүлиясы» — 1907дә һәм «Ачлык кушты» драмасы — 1908 елда. Бу тәртиптәге проза әсәрләренең хикәяме, повестьмы яки романмы булуы әлегә ачыкланып бетмәгән. «Әдипләребез» китабында алар хикәя буларак теркәлгән. «Оят, яки Күз яше» драмасының басылып чыгу датасы бу белешмәлектә җиде елга кичектерелгән, гәрчә ул әсәр

1907 ел урталарыннан башлап берничә труппа тарафыннан сәхнәләштереп өлгергән булса да. «Шура» журналына багышланган хезмәтләрдә бу авторның тагын 1909 елда дөнья күргән «Каравыл тавы» нәсере булуы да әйтелгән.

Тагын инкыйлабка кадәрге татар театрлары тарихына багышланган китап битләренә күз төшерик. 1908 елда басылып чыккан «Ачлык кушты»ны да шул чор театрлары үз иткән. Чөнки ул татар кыз балаларының фаҗигале язмышын тасвирлаучы әсәр. Татар авылларында, гаиләне ачлык фаҗигасеннән йолып калу ниятеннән чыгып, яшь кызларны үзбәк, төрекмән байларына сату гадәте булган. (Шул вакыйгаларга багышланган күләмле бер мәкаләсендә Мөхәммәт Мәһдиев андый гадәтнең соңрак Татарстанга кергән авылларга да хас булуын язган иде.) Ярулла Вәлинең «Ачлык кушты» драмасында шундый аянычлы бер вакыйга бәян ителә. Һәм, әлбәттә инде, ул әсәрне шул чор театр труппалары көтеп алган кебек була. Аны басылып чыккан елында ук сәхнәләштерә башлыйлар. Әүвәл телгә алынган китаптан тагын берничә язма китерик: *«Бу чорда драма әсәрләреннән Г.Исхакыйның «Мөгаллим», Г.Камалның «Уйнаш», Я.Вәлинең «Ачлык кушты», Ф.Әмирханның «Яшьләр»е аерылып тора... «Ачлык кушты» матбугатта күренү белән, Г.Камал һәм Ф.Әмирхан аңа карата зур-зур мәкаләләр язып чыгалар. Г.Камал бу драманың кыскарак булуын тели, сәхнәгә куяр өчен катлаулы эшләнгәнлегенә игътибар итә» (123-126 битләр). «Әсәрне сәхнәләштергәндә әлеге фикерләр искә алына. «Сәйяр» аны Төркестаннан кайтышлый беренче тапкыр Оренбургта күрсәтә... Аннары драма Казанда, Панаев бакчасындагы Җәйге театрда уйнала»* (127 бит). Бу китапның «Йомгаклау» өлешендә дә Я.Вәлинең исеме Ф.Бурнаш, Г.Исхакый, Г.Камал, К.Тинчурин, С.Рәмиев, М.Фәйзи, Г.Колахмәтов исемнәре белән бер сафта китерелгән.

1926 елда Мәскәүдә нәшер ителгән «Татар театры тарихыннан» китабында да (авторлары — режиссёр В.Мортазин-Иманский һәм Т.Ченәкәй) Ярулла Вәли иҗаты югары бәяләнгән. «1907-1909 елларда «Сәйяр» труппасы күп кенә шәһәрләрдә гастрольләрдә булганда «Оят, яки Күз яше»н уйнаган. Шуның белән зур уңышка ирешкән. Мәкәрҗә ярминкәсендә 1907 елда беренче мәртәбә уйналганнан соң, татар һәм урыс газеталарында аңа карата хуплау мәкаләләре басылып чыга. «Татар тормышыннан алып язылган, труппаның моңарчы куелган әсәрләреннән барыннан да яхшысы», — дигән сүзләр дә була ул мәкаләләрдә.

Утызынчы елларда мөһаҗирлектә язган «Шималь төрекләренең әдәбиятына бер караш» хезмәтендә Гаяз Исхакый да язучылар исемлегендә Ярулла Вәлине үзеннән соң өченче урында теркәгән. «Г.Исхакыйдан соң берничә ел соңрак әдәбият мәйданына Г.Камал чыга», — диелә дә, ике бит чамасы урында әдип Галиәсгар Камал иҗаты тасвирлана. Аннары: *«Шул ук чорда Ярулла Әлвәли исемле бер язучы берничә хикәя, роман һәм пьеса яза. «Ачлык кушты» исемле пьесасы шактый зур уңыш казана. Ләкин... әдәби сәләте җитәрлек булмавы аркасында, язучы бик тиз арада әдәбият мәйданыннан сәүдә базарына күчеп урнаша»*, — дип яза автор. Шул рәвешле Г.Исхакый каләмдәше Я.Вәлинең унынчы еллар урталарында бай кызына өйләнеп, «байларга ялчы булуын» өнәмәвен дә, Оренбург төбәгендәге кайбер каләм әһелләре белән даими рәвештә диярлек килешми яшәгәнлеген дә сиздереп куя. «Таң йолдызы» нәшер ителгәндә, 1907 елда ук аның Фатих Кәримине «буржуаз язучы» дип битәрләгәнлеге мәгълүм. Ул елларда бу ике шәхеснең бер-берсен тәнкыйтьләп язган язмалары матбу-

гатта даими рәвештә калка торган. Ә Ярулла Вәли — шул елларда Фатих мәхдүмнең якыннары исемлегендә йөргән шәхес.

Гаяз Исхакыйның бу хезмәтендә Ярулла Вәлидән соң китерелгән язучылар исемлегенә дә күз төшереп үтик. Менә алар: әдипнең Казан Укытучылар мәктәбе буенча шәриктәше, гасыр башы театрларында тәрҗемә әсәрләре даими рәвештә уйналган, шул чорның әдәби-мәдәни һәм иҗтимагый вакыйгаларына багышлап китаплар чыгарган, мәкаләләре белән катнашкан Шакир Мөхәммәдьяров, күренекле шагыйрьләр Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави һ.б.

Алтмышынчы елларда Ярулла Вәлинең әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлегенә Исмәгыйль Рәмиев тә игътибар иткән. Вафаты алдыннан (1969) нәшриятка тапшырган энциклопедик эчтәлекле, зур күләмле хезмәтендә Ярулла Вәлигә, милли-либераль «Вакыт» һәм «Яңа вакыт» газеталарына багышланган аерым мәкаләләр бар. Язучы һәм тәҗрибәле мөхәррир Рәис Даутов бик кыйммәтле булган ул белешмәлекне 2001 елда «Әдәби сүзлек» исеме белән бастырып чыгарган иде.

Бөек әдип Гаяз Исхакыйның Ярулла Вәли иҗатына карата әйткән сүзләрендә, мөгаен, дөреслек тә бардыр. Чынлап та, 1913 елдан соң Ярулла Вәли язудан туктаган, яңа әсәрләр иҗат итмәгән, ахрысы. Әллә кайнатасы Дәрдемәнд үрнәгендә язганнарын китап рәвешенә китерергә ашыкмаганмы? Дәрдемәнд тә бит әнә күпме язган югары сыйфатлы әсәрләре һәм кул астында иң заманча җиһазлы басмаханәсе була торып, үз әсәрләрен китап рәвешенә китерергә тырышмаган, диярлек. 1910 елда аның балаларга багышланган юка бер китапчыгы гына чыгып калган.

Ярулла Вәлинең шул замандагы газеталарда яисә мәҗмугаларда чыккан әсәрләре турында да әлегә берәр төрле хәбәрнең күренгәне булмады. 1913 еллар тирәсендә аның «буржуй» Закир Рәмиевнең кече кызы Зәйнәпкә өйләнүе (Исхакый язганча, «байларга ялчы булуы») иҗат итәргә комачаулаганмы? Әллә соң җилкәсенә өелгән җаваплы эшләрнең күплеге аны иҗат эшеннән аерганмы? Әйтүе кыен. Бу вакытта «Вакыт» басмаханәсенең эше өчен ул да җаваплы була. Ә 1917 елгы түнтәрешләр чорында ярты ел чамасы «Вакыт» газетасының баш мөхәррире вазифасын да башкарган. Шул вакыйгаларның чагылышына дәлил итеп, бер архив фондында сакланган телеграмма караламасын күрсәтергә мөмкин. Фатих Кәрими аны сентябрь аенда Чиләбе шәһәре тирәләрендәге приискасында булган Закир әфәнде Рәмиевкә юллаган: хезмәткәрләр баш күтәрә, эш хакын арттыруны таләп итә, дип. Шуннан соң озакламыйча Фатих Кәрими үз кәнәфиеннән төшерелә, шау-шулар нәтиҗәсендә «Яңа вакыт» газетасы барлыкка китерелә. Исмәгыйль Рәмиевнең «Әдәби сүзлек» белешмәлегендәге «Яңа вакыт» мәкаләсенә күз төшереп алыйк. «Фатих Кәрими вә аның фикердәшләре, әүвәлге «Вакыт» идарәсе белән килешә алмыйча, аны ташлап чыкканнан соң, «Яңа вакыт» тирәсенә оешалар. Наширләре (ягъни яңа хуҗалары) — Дәминев, Галәлетдинов тиҗарәтханәсе (сәүдә йорты). Газетаның фикри юнәлешен Ф.Кәрими болай билгели: газета вә аның мөхәррире бер партиягә дә мөнасиб социалист түгел, ул хөр фикерле тәрәккыйчы ... милләтчедер». Газета 1917 елның 1 ноябреннән 1918 елның 3 октябренәчә нәшер ителгән.

Шул ук китапта (61 бит) Исмәгыйль Рәми: «1917 елны «Вакыт» газетасы мөхәррирлеге Ярулла Вәли кулына күчте», — дип яза. Ул үзгәрешнең кайсы айда булганлыгын хәбәр итми.

Ахыры киләсе санда ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

АЙНЮК Самакай малае, Т.ның яшерен имзасы. «Шыер» пародиясе «Ялт-йолт» журналында (1912, №37) шул имза белән бирелә. Ф.Агеевның (1887-1938) мишәрчәрәк язылган шигыренә пародия рәвешендә иҗат ителгән текстка имзаны да Т. мишәрчәрәк куйган. Җаектагы Хәсән Самакаев исемле бер танышының Г.Ибраһимов исемендәге институтта истәлеге саклана (9-ф.,4-тасв.,119-эш). Имзага нигез рәвешендә нәкъ менә бу кешенең фамилиясе хезмәт иткән булуы да мөмкин. Пародия беренче мәртәбә өчтомлыкка кереш сүзе төшерелеп «Бәет» дип исемләнеп кертелә. Айнюк Самакай малае имзасы «Дин вә мәгыйшәт»тә дә күренә. «Ялт-йолт»ның 1913 елгы 56 нчы (20 май) санында чыккан имзасыз «Хәбәрләр урынына» исемле язмада: «Ачык муенлы марҗаларга карагач тәһарәт бозыламы?» дию «Дин вә мәгыйшәт» аркылы мәсьәлә сораучы Айнюк Самакай малае (чынында, «Дин вә мәгыйшәт»нең 1913 елгы 4 нче (18 гыйнвар) санында мондый сорауны биргән кеше — Мөхәммәдмөбин әфәнде Ханов), «Ялт-йолт»та бу нечкә мәсьәлә хәл кыйлынган бирле («Ялт-йолт»та үзе белән комган йөртергә тәкъдим ителгән була), яныннан комганын калдырмый йөри башлады», – диелгән.

Әсәр.: Биш томлык, 2 т., Б. 210, 375.
Әдәб.: Гимадиев У.И. Сила сатирического слова, с.268; Рәмиев З.З. Габдулла Тукай псевдонимнары. «Казан», 1995, №9-10, Б.81, 82; аныкы ук. Тукайның ачык һәм яшерен имзалары, «КУ», 1996, №4, Б.140.

Зөфәр Рәмиев

Габдулла Тукай

ШЫЕР

Фәхрелислам Агиевның шыерын, малай, Кулаткада да севеп укыганнар. Вата, шыннан күреп, Кулаткада бер шаир, безнең журналга да нәстәдер бер бәет посылать иткән. Вата:

Бәет

Их, малай, вафасыз да бу: міръ!
Бак вана: Хусаен дә помер!
Әмән безнең күк алаша кебек
Ашый, кәбәм, һич туймый бу йир.
Нишләсен вет, Азраил килсә, бар кеше үләр,
Тимай бай булсаң да азанчы күмәр.
Вет праруклар да, малай, вафат булды,
Сахабалар: Али, Усман, Үмәр. ■

Якты эз калдырган шәхес

Фәридә Гайфуллина,
Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте укытучысы, филология фәннәре кандидаты

Көзнең иң матур чагы – әбиләр чуагы. Дөнья чуп-чуар, яп-якты. Һавадан күбәләктәй яфраклар оча, җиргә төшкәннәре аяк астында кыштырдаша. Биткә пәрәвез җепләре кагыла. Менә шундый матур көннәрдә якташыбыз, халык язучысы Гариф ага Ахунов дөньяга килгән. Әгәр исән булса, аңа быел 90 яшь тулган булыр иде. Ни кызганыч, ул инде күптән арабызда юк...

Беренче рәттә (сулдан): Г.Ахунов, Г.Шәрәфи, Р.Даутов

Исән чакта Гариф ага белән очрашып, аралашып яшәдем. Ул бик гади кеше иде. Кайчан килсәм дә, ничә килсәм дә, Гөлшаһидә апа белән алар мине үз кызлары кебек каршы алды, озатып калды. Гариф ага миңа үзенең иҗат юлы, әсәрләренең язылу тарихы, үзе тудырган әсәр геройларының прототиплары турында сөйләде. Болар исә миңа хезмәтемне язганда зур ярдәм булды.

Гариф ага Ахунов — күпьяклы, киң кырлы талант иясе. Беренчедән, ул — әдәбиятның алгы сафында торучы, заман сулышын тоючы, үткен күзле, тапкыр сүзле әдип. Төрле жанрларда иҗат итә: хикәя, повесть, романнар яза; шигырьләр тудыра, тәрҗемә эше белән шөгыльләнә. Әдәби тәнкыйть эшчәнлеген, драматургияне дә үз итә. Бигрәк тә әдип татар укучысына үзен проза остасы буларак таныта. «Хәзинә», «Хуҗалар» романнары, «Идел кызы» дилогиясе, «Этләр патшасы», «Тимерханның күргән, кичергәннәре» повестьлары — әдипнең талант җимешләре.

Икенчедән, Г.Ахунов — рәссам. Үзе белгән, яраткан, балачактан

Президиумда уртада Гариф Ахунов

якын иткән табигатьне сурәтли, портретлар язу белән дә шөгыльләнә. Аның рәсемнәре бүген дә музейларда саклана.

Өченчедән, Г.Ахунов — актив җәмәгать эшлеклесе. Ул — талантлы оештыручы була. Егерме ике төрле җәмәгать эше башкарган һәм барлык җәмәгать оешмаларында да карусыз, бөтен җан җылысын салып хезмәт күрсәткән.

Г.Ахунов актив тормыш алып барган шәхес. Илебезне генә дә өч тапкыр йөреп чыга. Зур илнең күп мәшһүр кешеләре белән очраша, фикер алыша, тәҗрибә уртаклаша. Башкорт, үзбәк әдәбиятларын, әдипләрен яхшы белә. Якут поэзиясен ярата. Каракалпак, Төньяк Кавказ әдипләре — аның якын дуслары. Урыслардан мәшһүр С.Залыгин, В.Распутин кебек олы затлар — аның даими фикердәшләре.

Г.Ахунов — тәҗрибәле, үткен телле публицист та. «И кадерле туган як», «Без бит Арча яклары», «Чишмәләр белән сөйләшү», «Әдәби язмышлар», «Йолдызлар калка» кебек китаплар шул хакта сөйли.

Ул — күп кенә киносценарийлар авторы: Ә.Еники турында «Тауларга карап» исемле документаль фильм, Г.Тукай турында «Каргышлы балачак» исемле телевизион фильм, беренче Президентыбыз М.Шәймиев турында «Без бит — адәм баласы» исемле лирик-документаль фильм, «Хәзинә» исемле киң экранлы, төсле фильм, «Габбас мулла» исемле телевизион фильм.

Г.Ахунов — мемуарлар остасы һәм яшьләрнең остазы иде. Татар әдәбияты тарихына үзеннән һәрьяклап зур өлеш кертә. Татар әдәбиятының алдынгы вәкилләренә, үлгәннәргә һәм тереләргә багышлап, том-том истәлек-мәкаләләр туплап чыгара. Яшь каләм тибрәтүчеләргә дә бик теләп ярдәм итә...

Якты эз калдырып китте Гариф ага, кешелекле дә, талантлы да иде. Әсәрләре дә бүгенге көндә үз йөзләрен, төсләрен тулысынча саклап кала алды... ■

Ленар Гобәйдуллин фотолары


Авылым сагышы

Өч гасырлык тарихың
Бар иде бит, авылым.
Нинди җилләр алып килде
Замананың давылын?

Йорт-җирләрең җимерелде,
Зиратларың тапталды,
Тау башында япа-ялгыз
Шомырт-миләшең калды.

Чишмәләрең зарыгалар
Чиләк тавышын тыңларга.
Язмышыңны калдырам
Киләчәк буыннарга.

Гариф Ахунов

Кечкенә Өчиле,

Кечкенә Өчиле авылында «исән калган» чишмә

Авылым сагышы

Арча районында Гариф Ахуновка бәйле истәлекле урыннар. Фоторепортаж www.beznenmiras.ru сайтында тулырак тәкъдим ителә.

«Казан арты» тарих-этнография музеенда Г.Ахуновка багышланган экспозиция. Уңнан: музей директоры Р.Р.Камалов, шагыйрә Н.Г.Ахунова, директор урынбасары Ш.З.Гарипов

Фәнис Идрисов Кечкенә Өчиле авылында Г.Ахунов туган нигезне күрсәтә

«Туган авыл». Гариф Ахунов рәсеме

Шәүкәт Галиев

СИН КАЛДЫРГАН ЕЛЛАР

Идел өсләрендә көзге томан,
Безнең офтанулар түгелме?
Кояшы да сирәк күренә шул,
Елмаюлар, Гариф, сүрелде.

Яңа гасыр, яңа өметләр дип,
Киләчәкне яшьләр көтәләр.
Яңа дуслар безнең булмас инде,
Иске дуслар, Гариф, китәләр...

Безнең гасыр — безнең язмыш иде,
Нәкъ без кирәк идек аңарга —
Сүрән күңелләрне жылытыйк дип,
Бергә-бергә, Гариф, янарга.

Егерменче гасыр даһиларын
Тудырды да, китте алып та.
Без аларга фикердәшләр идек,
Безнең чордаш иде Алыплар.

Гамәлдә гел сине юксынабыз,
Бәйрәм түрендә дә син кирәк:
Моңсу чакларны да күңелләргә
Куяр идең, Гариф, син көйләп.

Идел өсләрендә язгы томан,
Күтәрелер уйлар-дулкыннар,
Якты булсын син калдырган еллар,
Синдәй, Гариф, көләч булсыннар!

17 октябрь, 2000 ел

Казанбаш мәктәбендә туган якны өйрәнү музее. Укытучылар Г.Ахунов экспозициясе янында

«Тукай клубы»: тарих һәм заман

Сиринә Мөхәммәтҗанова

Фото һәм аудиорепортаж белән www.beznenmiras.ru сайтыннан таныша аласыз

Әүвәлге Тукай клубы барлык әдәбият һәм мәдәният эшлеклеләрен берләштергән көчле үзәк булып саналды. Бирედә танылган журналистлар, талантлы язучы-шагыйрьләр, мәдәният һәм сәнгать әһелләре бик еш җыела иде. Байтак ел үткәч, ниһаять, әлеге клуб үзенең эшчәнлеген янәдән башлап җибәрде. Шушы көннәрдә генә «Матбугат йорты» үзенә аксакал язучыларны, газета-журнал мөхәррирләрен, журналистларны җыйды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары Сөмбел Таишева оештырган очрашуда халкыбызның танылган язучы-шагыйрьләре Равил Фәйзуллин, Марсель Галиев, Гәрәй Рәхим, Әхмәт Рәшитов, Вахит Имамов, әдәбият галиме Фоат Галимуллин һ.б. катнашты.

Татарстанның халык шагыйре, «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры

Утыралар, сулдан-уңга: Әхмәт Исхак, Риза Ишморат, Гомәр Бәширов, Сәрвәр Әдһәмова, Афзал Шамов, Хәсән Туфан, Кәрим Җаманакыл (Кырым).
Басып торалар: Идрис Туктар, Хәмит Ярми, Мәхмүт Бөдәйле, Мөхәммәт Гайнуллин, Абдулла Әхмәт, Газиз Иделле

киңәшчесе **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** кичәне ачып җибәргән чакта болай диде:

— Безнең 70 ел чамасы тарихыбыз шушы йорт белән бәйләнгән. Әлеге бинаның диварлары яшьлек хатирәләребезне, тәүге шигырьләребезне, гомумән, халкыбызның рухын үзендә саклыйдыр кебек. Без бу йортны югалтырга тиеш түгел идек. Әгәр татар өчен Казан — Мәккә булса, аның Кәгъбәсе «Матбугат йорты», дияр идем...

2006 елда «Мәгариф» китап нәшриятында, аның директоры галим, язучы Мөдәррис Вәлиев инициативасы белән, 33 әдип катнашында, «Матбугат йорты — гомер китабы» дип исемләнгән истәлек-хатирәләр китабы басылып чыкты. Бу исем бик тә мәгънәле. Чөнки әлеге авторларның күбесенең яшәеше шул йорт белән бәйле. Заманында бу бинада китап нәшрияты, газета-журнал редакцияләре, китап кибете урнашкан иде. Кыскасы, әлеге йорт кайнап торды. Хәзер бу бинага башка кеше хуҗа булса да, мине бернәрсә тынычландыра: бу йортта Тукай клубы сакланып калды. Без биредә затлы кичәләр, очрашулар оештыра алабыз. Икенче катка менүгә Муса Җәлилгә бәйле экспонатлар, аның язу өстәле һәм башка кыйммәтле документлар саклана. Мин әле бу йортка чит җирләрдән бик күп туристлар киләр, алар дөньяда Тукай, Җәлил, татар әдәбияты барын белерләр, Тукай клубы алга таба да татар әдәбиятын пропагандалар, дип ышанам.

Тагын бер теләгем бар: киләчәктә дә яшьләр әлеге изге йорт барлыгын белеп үссен иде. Мөмкинлекләре булганда Тукай клубына килсеннәр, гыйбрәт алсыннар. Минемчә, алар бик күп рухи байлык тупларлар...

Аннан соң ул тамашачыларны тарихи фотолардан тупланган презентация белән таныштырды. Башка язучыларның чыгышлары да кызыклы һәм тирән эчтәлекле иде.

Тантаналы кичәнең икенче өлеше бөек язучыбыз Гариф Ахунов истәлегенә багышланды. Халык хозурына «Арча» телерадиокомпаниясе тарафыннан төшерелгән Гариф Ахуновның тормышы һәм иҗатына багышланган өр-яңа документаль фильм тәкъдим ителде.

Язучының кызы Наилә ханым элек әтисенең юбилей кичәләре зуррак масштабларда, зур сәхнәләрдә үткәрелүе хакында әйтеп үтте. Ә бүген күренекле язучыбызны искә алу тантаналары мәктәпләрдә, китапханәләрдә генә уздырыла. Болай барса, тагын 10 елдан соң яшь буын бөек шәхесләребезнең исемнәрен бөтенләй онытмасмы?! ■

Мәгърур нарат кебек...

Марат Закир

Мәгъсум абый Хуҗин белән мин «Идел» журналында эшләгәндә аралаша башладым. Редакциягә Мәгъсум абый килеп керсә, безнең алда ни җитди булып күренергә тырышкан баш мөхәррирребез Фәиз абый Зөлкарнәй дә түзми, елмая башлый. Ул арада «Салават күпере»ннән Зиннур Хөснияр белән Ләбиб Лерон да кереп җиткән.

Югыйсә Мәгъсум абый эч катып көлә торган мәзәкләр дә сөйләми үзе. Вәләкин без аңа магнитка тартылгандай тартылабыз. Агабыз кырында рәхәт безгә! Чөнки үзенә генә хас бер якты вә тансык җылылык хасил итә торган аурасы-җан халәте бар Мәгъсум абыйның.

Шулай бер килүендә ул миңа:

— Бер хикәяңне антологиягә әзерләп бир әле, — диде.

Әле китап та чыгармаган башым белән мин аптырап калдым.

— Ул хикәяңне сайлап алдым инде, әгәр дә... риза булсаң, — дип өстәде аннары агай.

Журналда гына басылган әлеге хикәяне мин егерме яшемдә язган, һәм әллә ни җитдигә санамый да идем. Әнә шулай иттереп, «Канлы болыт» хикәясе Мәгъсум Хуҗин төзегән «Татар хикәясе антологиясе»ндә урын алды.

Берничә ел үтеп, инде «Казан утлары»нда эшли башлагач та, агай бу хикәягә «бәйләнүен» дәвам иттерде. Эш болай булды. Өч хикәямне журналга әзерлим. Мәгъсум абый, кереш сүз язарга ниятләп, кульязмамны сорап алды.

— Хикәяләрең әйбәт кенә, — диде ул көннәрнең берендә. — Әмма дә теге әфган хикәяң... шәп иде!

Инде менә хәзер, бүген — Мәгъсум абыйның вафатыннан соң күпме сулар аккач кына — уйлап утырам... «Егерме яшьтә алган планка-кимәлеңне төшермә!» — дигән икән бит миңа олпат остазым.

Мәгъсум ага — туган Сабасына, аның туфрагына кендек каны тамганнан бирле гел мөкиббән булып, табынып яшәгән зат. Язучының бөтен әсәрләре дә диярлек шушы як рухы белән сугарылган. Нәтиҗәдә, әдипнең беркемне дә кабатламаган, фәкать үзенә генә хас стиле формалашкан. Күрше Мамадыш-Тәкәнеш якларыннан булгангамы, ул мине якташы итеп саный иде. Тәлгат Нәҗмиев белән берлектә чыгарган «Яшә, Саба-йорт!» китабына автографын болай дип язып бирде: «Якташка! Сезнең якта да бар андый наратлар!» Бу култамга — китап авторларының шундый бер чал нарат янында төшкән фотосурәтләренә дә ишарә. Дүрт-биш гасыр гомерлек борынгы наратның безнең райондагы урынын да әйткән иде әле Мәгъсум абый.

Туган төбәге турында, Саба кешеләре хакында шулкадәрле дә яратып, онытылып, тәмләп-тәфсилләп яза ки — бу китапны укып чыккач, мин бераз аптырап та, Мәгъсум абыйга болай дидем:

— Нигә үзең турында берни дә юк соң?!

Агаем, калын каш астыннан гына, сизелер-сизелмәс кенә моңсу елмаеп куйды.

— Минем хакта... сез язарсыз инде... — диде.

Марсель Галиев
фотосы

***

...Еш кына без Мәгъсум абый белән «Идел-Пресс»тан өй уңаена бергә кайта идек.

— Ашыксаң, бар, мине көтмә, пехота! — ди ул, таягын җиргә батырып. Вәләкин аның алдында әллә нинди ашыгуларың да баштан чыгып оча, валлаһи. Әле генә Шәйхи Маннур турында сөйли башлаган иде...

— Мөдәррис Әгъләмгә генә килешә иде ул шигъри адымнар белән йөрү! — дим мин аңа. — Ә хикәя ул саллы, мәгърур адымны, ашыкмыйча гына барганны ярата!

Чагыштыру ошый агайга һәм ул, тәмләп кенә көлеп куя да, без кала уртасындагы паркта тәмәке кабызып, ашыкмыйча гына алга атлыйбыз. Мәгъсум абый исә... Фаил Шәфигуллин турындагы истәлекләренә керешә. Ә бая сөйли башлаган Шәйхи Маннур турындагысын барыбер ишетмичә өйгә кайтып китмәсемне беләә, хәйләкәр.

Мәгъсум абыйга машиналар берөзлексез чабышкан Чистай урамының аргы ягына чыгарга кирәк. Мин аны озата барам да, кире автобус тукталышына башымны борам.

— Әйдә, хәзер инде мин сине озата чыгам! — ди Мәгъсум абый. — Алайсам, бу яктан җәяү генә кайтсаң, кайтырыңа ерак шул — ике тукталыш!

Шулай иттереп, тәки өйгә җәяү йөрергә өйрәтте мине агай!

***

...Дөнья артыннан куучы машиналар арасында февраль бураны адашып йөри. Кайчандыр Мәгъсум абыйны өенә озаткан чатка чыгам да, Чистай урамы буйлап өйгә атлыйм. Минем дөньямда, адаштырмас маяк булып, бер мәгърур, олпат нарат үсеп утыра! Әнә бит ул, әнә-ә — аңа буран ни, вакыт ни, салкын ни — юл чатында вәкарь вә сабыр гына таягына таянган да, сизелер-сизелмәслек кенә моңсу елмаеп, басып тора Мәгъсум абый...

Ләбиб Лерон

ЕРГАНАК ЮЛ ЯРА...

Мәгъсум Хуҗинга

Бу — тормыш бу.
Без — мәңгелек юлда:
Офыккача безнең юл бара...
Агымсудай гомер, ярсу иҗат
Ерганаклар булып юл яра!..

Бу — тормыш бу:
Юл гел алга әйди,
Үткәннәргә дәшә юл безне —
Боргаланып аккан ерганактай
Еракларга илтә ул безне...

Бу — тормыш бу.
Тукталыш юк юлда.
Вакыттан һич булмый калышып.
Күктә — сырганактай[1] кояш.
Җирдә —
Ерганактай гомер агышы.

Бу — тормыш бу.
Дөнья сабак бирә —
Тәнәфессез үтә дәресләр:
Күз аллары томанлана кайчак —
Әлҗе-мөлҗе килә хәрефләр...

Бу — тормыш бу.
Ашыктыра Вакыт.
Ерганак юл яра[2]— укталып...
Туу-Яшәү — Гомер маршруты.
Үлем исә —
Тәүге тукталыш.

20 сентябрь, 2015 ел ■

[1] Мәгъсум Хуҗинның «Сырганак» дигән хикәясенә ишарә.
[2] 1961 елда язучының шул исемдәге беренче китабы басылып чыга. (Автор искәрмәсе).

Кайтаваз

Муса Җәлилнең «Седльце шигырьләре»

Хәнәфи Бәдигый

«Безнең мирас» журналының сигезенче санында басылып чыккан Рәзин Нуруллинның «Акка кара төшсә, югалмый...» дигән мәкаләсендә каһарман-шагыйрь Муса Җәлил иҗатының әлегә кадәр билгесез булган яңа сәхифәсе ачыла, дип әйтергә була. Анда шагыйрьнең якташы — Гобәйдулла Салихов дигән кеше тарафыннан, 1942 елның октябрендә, Седльце (Седлец) шәһәрендәге хәрби әсирләр лагеренда Муса Җәлилдән күчереп алган алты шигырь урнаштырылган. Югалган дип исәпләнгән ул шигырьләрнең 72 елдан соң табылуы үзе бер могҗизага тиң. 2007 елда Салиховлар яшәгән йортны сүткәндә, чормада күн букчада табыла ул шигырьләр. Анда Салиховның истәлекләре дә була. Аларның ничек итеп табылуы шул мәкаләдә ачык, аңлаешлы итеп язылганга, кабатлап тормыйк.

Ихтимал, ул мәкалә байтак сораулар да тудырыр. Шулай да иң элек ике сорауны ачыклау мәслихәт. Аның беренчесе һәм иң мөһиме: бу алты шигырь чыннан да Муса Җәлилнекеме, түгелме яки ул башка кешенекеме? Икенчесе — шактый ук четереклесе: ни сәбәпле Гобәйдулла Салихов ул алты шигырьне чормага яшереп куйган да бу хакта беркемгә дә әйтмәгән?

Бу сорауларга өстән-өстән генә, берике сүз белән генә җавап бирү мөмкин түгел: алар катлаулы, дәһшәтле, хәтәр, куркыныч вакыйгалар белән үрелгән. Шуңа күрә бу язмада аларның кайберләренә генә тукталырга туры килә.



Муса Җәлилгә нисбәт ителгән «Озатып калучы» шигыренең кульязмасы

Рәзин Нуруллин язганча, беренче сорауга ачыклык кертү юнәлешендә эш башланган да инде. Шундый үтенеч белән ул Казан федераль университеты доценты, филология фәннәре кандидаты, Муса Җәлил иҗатын өйрәнүче Нурфия Йосыповага мөрәҗәгать иткән. Аның раславынча, бу шигырьләр, чыннан да Муса Җәлил стилендә язылган. Күчереп язучы Гобәйдулла Салихов, бәлки, кайбер төгәлсезлекләр дә җибәргәндер, өстәвенә алар башкорт телендә күчерелгән ди галимә.

Әлеге вакыйга редакциядә шулай ук зур кызыксыну уяткан: «Ничек кенә булмасын, һәммә фактлар җентекләп өйрәнүне, тикшерүне

таләп итә. (Аллаһ боерып, киләчәктә, бәлки, Муса Җәлилгә нисбәтле шушы шигырьләр турында Нурфия Йосыпованың да, башка галимнәрнең дә фәнни язмаларын журналыбызда күрергә насыйп булыр әле. – ***Ред.****) Галимнәр бу эш белән шөгыльләнә дә», – диелгән искәрмә шул хакта сөйли.*

Рәзин Нуруллин мәкаләсе һәм редакция искәрмәсе миндә — 35 ел дәвамында Муса Җәлил иҗатын өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе яклаган, докторлык диссертациясе язган, герой-шагыйрь иҗатына багышлап күп санлы фәнни-публицистик хезмәтләр, әдәби әсәрләр иҗат иткән җәлилче-галимдә — шулай ук зур кызыксыну тудырды.

Әлегә кадәр шагыйрь иҗаты нигездә «Бөек Ватан сугышына кадәрге», «Фронт лирикасы» һәм «Моабит дәфтәрләре» дигән өч зур чорга бүлеп өйрәнелә иде. Әгәр шул алты шигырь, чыннан да Муса Җәлилнеке булса, ул вакытта герой-шагыйрь иҗатының яңа — дүртенче (хронология буенча өченче) сәхифәсе ачыла, дип исәпләргә була һәм аны шартлы рәвештә «Седльце шигырьләре», дип атарга мөмкин. Ни өчен дигәндә, беренчедән, ул шигырьләр шунда — Польшадагы хәрби төрки халыкларны җыю урыны булган лагерьда күчереп алынган; икенчедән, Седльце (Седлец) лагере — антифашистик оешмаларның баштагы үзәге һәм аның җитәкчеләреннән берсе — махсус төркем белән дошман тылына җибәрелгән һәм әсирлеккә эләккән җәлилче Гайнан Кормаш була; өченчедән, бу алты шигырьнең аерым чоры, үз тарихы бар. Ул тарих үткән белән бүгенгене генә түгел, киләчәкне дә тоташтыра ала. Киләчәк дигәндә, Муса Җәлилнең Дәүләт Куркынычсызлыгы Комитеты архивына тапшырылган һәм әлегә кадәр табылмаган дүртенче дәфтәре турында сүз бара. Бу сүз бик җитди: Муса Җәлил кулъязмаларының КГБның яшерен архивында саклануы турындагы документны Казанга шул оешманың баш идарә начальнигы, генерал Леонид Шебаршин алып килә. Димәк, ул дәфтәр бөтенләй юкка чыкмагандыр: йә шул архивта сакланадыр яки кайдадыр, кемнәргәдер җибәрелгәндер, һәм ул, Гобәйдулла Салиховлар яшәгән йортны сүткәндә чормада табылган шул алты шигырь кебек, көтмәгәндә килеп чыгарга да мөмкин. Мондый версияне дә бөтенләй кире кагып та, хәзергә бу турыда ачык итеп сөйләп тә булмый, гәрчә фаразларга нигез бар.

Төрки-татарлар тупланган урын булгангамы яки башка сәбәп беләнме, сугыштан соң Седльце хәрби әсирләре турында теләр-теләмәс кенә искә алганнар. 1962 елның май аенда гына: *«Героям Красной Армии, павшим в борьбе с гитлеровским фашизмом за нашу и вашу свободу в 1941-1945 годах. Честь их памяти. Седльце, 13 мая 1962 г.»* дигән язулы монумент куелган.

366 шталаг дигән бу лагерь совет-герман чигендәге шул Седльце шәһәрендә, 1939 елда оештырыла. 1941 елның җәеннән анда совет, француз, соңрак итальян әсирләре дә тотыла. Седльце тирәсендәге лагерьларда 40 меңләп әсир һәлак ителә. 10-15 градуслы салкында, ачык һавада, ачлыктан тилмергән әсирләр һәр көнне дүрт-биш йөзләп кырылган. 1942 елның 21 августында шунда «Идел-Урал» легионы төзелә башлый. Анда татар, башкорт, Идел буе халыклары керә һәм аның төп максаты партизаннарга каршы көрәш оештыру була.

Сталинның Кырым татарларын туган илләреннән сөрүе һәм Казан татарларын сөрергә әзерләнүе хәзер сер түгел. Соңгысыннан аны «Идел-Урал» легионында Муса Җәлил һәм җәлилчеләр оештырган 900 чамасы хәрби әсирдән торган 825 нче батальонның Витебск тирәсендә, немец командирларын кайсын юк итеп, кайсын әсирлеккә алып, бик күп корал арсеналы белән партизаннар отрядына кушылуы, 30 меңгә якыны Франциядә

фашистларга каршы көрәше турындагы хәбәр генә туктатып кала. Диктаторның татарларга карата булган мондый мөнәсәбәтенең нигезендә зәһәр мәкер генә түгел, зур сәясәт тә ята. Ихтимал, моның белән ул берничә миллион Кызыл Армия сугышчысының әсирлеккә эләгүен дә, советлар иленең башка милләт әсирләреннән төзелгән легионнарның дошман сафына кушылуларын да халыктан яшереп тотарга теләгәндер. Тарихчы-галим Искәндәр Гыйләҗевнең «Идел-Урал» легионы» дигән китабында бу хакта шаккатыргыч мәгълүматлар бар.

1941 елның июль уртасында Кызыл Армия бер миллион чамасы кешесен югалта; ноябрь аенда 3,6-3,9 миллион чамасы сугышчысы әсирлеккә эләгә. Шуның 280 меңе генә азат ителә, 2,6 миллионы һәлак була; әсирләрнең гомуми саны 5,7 миллионга җитә. Фашистлар басып алган җирләрдә барлыгы алты легион төзелә: Төркестан, Әзәрбайҗан, Грузин, Әрмән, Төньяк Кавказ, Идел-Урал татар легионнары. Алардагы дистә меңнәрчә әсир дошман ягында торып, Кызыл Армиягә каршы сугышырга мәҗбүр ителә. Алар икенең берсен сайларга тиеш була: яки лагерьдагы үлем, яки дошман сафына кушылу. Әле моңа фашистларга сатылган генерал Власовның миллионнан артык сугышчылы «Рус азатлык армиясе» дә өстәлә, ләкин монысын инде сер итеп саклау мөмкин булмый.

Әлеге уңайдан шунысын да әйтергә кирәк: 1946 елның дүртенче гыйнварында Римдагы Совет резидентурасы юлламасы белән Үзәккә 9 куен дәфтәре җибәрелә. Алар: Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Фоат Сәйфелмөлеков, Абдулла Батталов дәфтәрләре; кемнәрнекедер — икешәр дәфтәр булган дигән сүз. Аларның әле берсе дә табылмаган. (Хәер, Абдулла Алишның бер дәфтәрен, Муса Җәлилнең беренче «Моабит дәфтәре» белән бергә, Нигъмәт Терегулов, Уфадан махсус рәвештә шуның өчен Казанга килеп, 1946 елның 29 мартында Абдулла Алишның хатыны Рокыя Тюльпановага бирә, ә ул аны Язучылар берлеге рәисе Әхмәт Ерикәйгә илтеп тапшыра. Шуның белән А. Алишның ул дәфтәре эзсез юкка чыга).

Бу шигырьләрнең Муса Җәлилнекеме, түгелме икәнлеген ачыкларга керешкәндә, башта ук шунысын әйтергә

кирәк: беренче карашка, аларның шагыйрьнең «Фронт лирикасы» һәм «Моабит дәфтәрләре» шигырьләре белән охшашлыгы, аваздашлыгы, уртаклыгы аз, хәтта юк кебек тоела. Бөек Ватан сугышына кадәрге иҗаты белән охшашлыгы булу-булмауны ачыклау — аерым тикшерүне сорый. Гомумән, моны формаль яктан төгәл ачыклау өчен шагыйрьнең бөтен иҗатына лингвостилистик, ягъни тел-стиль анализы ясарга туры килер иде. Иң кызыгы шунда: ул анализның нәтиҗәсе барыбер ачык кына булмас, бәхәсле булып калыр, һәркем үзенчә аңлатма бирергә мөмкин. Ни өченме? Чөнки мондый юл, алым, концепция бу очрак өчен кулай түгел, икенче төрле методика зарур.

Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»н һәм фронт лирикасын өйрәнеп, гыйльми хезмәт язганда, мин аларны дүрт төрле стиль тональлегенә бүлеп тикшергән идем. Алар: «Туган илгә мәхәббәт хисе белән сугарылган патриотик лирика»; «Дошманга нәфрәт белдергән шигырьләр»; «Мәхәббәт лирикасы»; «Дусларча ягымлы елмаюлы, юмор әсәрләре».

Әлеге алты шигырьдә туган ил темасы («Туган ил сулары»); мәхәббәт лирикасы дип исәпләргә мөмкин булган («Сөйгән дустыма», «Дустым хисе», «Озатып калучы», «Дустыма») шигырьләр, шагыйрьнең алда әйтелгән шигырьләрендәге кебек, ачык лирик-патриотик хис белән сугарылмаган. Аларны «Сагышлы лирика» дип әйтергә була («Картлык» шигырендә ул тагын да ачыграк сизелә). Шуңа күрә ул шигырьләрнең тел-стиле дә үзенчәлекле. Менә хикмәт нәрсәдә. Бу шигырьләрне, нигездә аерым, «Сагышлы лирика» дигән, бишенче стиль тональлегендә язылган һәм аларның саны байтак булгандыр, дип исәпләргә мөмкин. Шуңа күрә аларны, гәрчә турыдан-туры аның стиленә туры килмәсә дә, Муса Җәлил шигырьләре түгел, дип тә әйтеп булмый.

Икенчедән, һәм монысы шулай ук әһәмиятле вакыйга: әгәр ул шигырьләр Муса Җәлилнеке булмаса, Гобәйдулла Салихов аларны яшереп куеп, беркемгә дә әйтмичә йөрмәс иде. Ни өчен әйтмичә йөргән соң? 1953 елга кадәр, ягъни Җәлилнең исеме акланганчы бу турыда сүз кузгату — белә торып, үзен-үзе һәлак итү булыр иде. Ул аны шагыйрьнең исеме акланып, хәтта Советлар Союзы Герое исеменә һәм Ленин премиясенә лаек булгач та әйтә алмаган. Нахакка «сатлыкҗан» исеме тагылган, НКВД вәкилләренең төн уртасында өйләренә кереп, тентү үткәрелгән кеше, әгәр дә: «Миндә Муса Җәлил шигырьләре саклана», — дип әйткән булса, аңа әллә нинди яңа гаепләр тагып, кулга алып, харап иткән булырлар иде. Запастагы офицер, кече лейтенант Гобәйдулла Салихов моны бик яхшы аңлагандыр, дип уйларга нигез бар. (Редакциядә аның М.Җәлилгә нисбәтле шигырьләр белән бергә, 1954 елның 26 февралендә үзе язган кулъязмасы да бар. Ул анда 1942 елның октябрендә Седльце шәһәрендәге хәрби әсирләр лагерында якташы, татар шагыйре Муса Җәлил белән танышып, аның алты шигырен күчереп алу мөмкинлеге булуы турында язган. Кулъязма журналда басылып та чыгар.*) Ул моны шуңа күрә тирән сер итеп саклагандыр.

Муса Җәлилнең коточкыч шартлардагы Седльце үлем лагеренда яралы хәлдә шигырьләр яза алуы шаккаткыч хәл, батырлык, ныклык үрнәге. Шигырьләрен әсирләргә укып, ул аларның күңелен күтәрергә, туган илгә, хәрби антларына тугрылык сакларга, дошманга нәфрәт белән карарга, аның тар-мар ителәчәгенә ышанырга, ныклык, чыдамлык күрсәтергә чакырган. Әмма әйтергә теләгән сүзләрен, фашистлар тентеп табарлар дип, турыдан-туры яза да алмагандыр: әсирләрне

* Әлеге кулъязма журналыбызның 9 нчы санында «Тормыш юлым» исеме белән басылып чыкты. — *Ред.*

тентеп, шикле, фашистларга каршы көрәшкә чакырган язулар тапкан очракта, аларны карцерга япканнар. Аннан чыгу юлы ике: йә үлем, яки лазарет булган. Ә лазарет фельдшеры аларның тиреләрен тунап, ул вакытта фашистлар Германиясендә модага кереп барган перчатка, сумка, акча янчыклары ясап саткан. Аеруча татуировкалы кеше тиреләре кыйммәтле саналган. Фельдшер андыйларны махсус эзләп йөргән. Бу лагерьда татарлар күп, аның шигырьләрен күчереп алучылар да бер Салихов кына булмагандыр. Бәлки, аларның да кайберләре исән калып, туган илләренә әйләнеп тә кайткандыр. Ләкин алар да, Г.Салихов кебек ул шигырьләрне беркемгә дә күрсәтмәгәндер. Күбесенең лагерьда ук югалып бетүе дә бик ихтимал.

Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»нә кадәр үк берничә куен дәфтәре югалуы мәгълүм. Аның беренчесе, Волхов фронтында яраланып, аңын җуйган вакытта юкка чыга. Тышы таушалып беткән шул калын куен дәфтәрен ул кыр сумкасында йөрткән. Шигырьләрен, поэмаларын шунда язган. Аларның да кайберләре «Моабит дәфтәрләре»нә кергән.

Икенче дәфтәре 1942 елның сентябрь аенда Ленинград өлкәсенең Рождественский лагеренда фашистлар тарафыннан утка ташлана. Рафаэль Мостафин тасвирлаганча, вакыйга болай була.

Муса Җәлил монда Гариф Хафизов дигән кеше белән таныша. Ул аңа багышлап «Гариф дуска» дигән шигырь дә язып бирә. Гариф аны яттан белгән. Двинск лагерена җибәрелер алдыннан Муса Җәлил аңа шул кесә дәфтәрен бирә һәм: «Әгәр син исән калсаң, бу шигырьләрне Казанга берәр газета яки журнал редакциясенә җибәрерсең», — ди. Муса Җәлилне алып китеп берәр ай чамасы вакыт узгач, фашистлар баракта тентү үткәрәләр. Хафизов ул дәфтәрне яшереп өлгерә алмый, тентүчеләрнең берсе аны табып, кулыннан йолкып ала да янып торган мичкә ыргыта. Гариф кулында ул дәфтәрнең өч бите генә ертылып кала. Алар Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»нә кергән «Тик булса иде ирек» (баштагы исеме — «Чәнечкеле тимерчыбык эчендә»), «Урман» (баштагы исеме — «Кара урман»), «Карлыгач булса идем» дигән шигырьләре. Әлеге вакыйгадан шул да аңлашыла: Муса Җәлил «Моабит дәфтәрләре»н төзегәндә, аларны хәтерендә кат-кат укып, төзәтеп, үзгәртеп, камилләштереп язгандыр, кайберләре, бәлки, хәтерендә дә сакланмагандыр. Г.Салиховка биргән шигырьләре белән дә шулай булырга мөмкин.

1942 елның октябрь ахыры-ноябрь башларында, Муса Җәлилне Польшаның Демблин лагерена алып киләләр. Ул монда Мәскәүдәге танышы Салих Ганиев дигән кешене дә очрата һәм аңа да байтак шигырьләрен әйтеп яздыра. Әсирләр күчереп алалар ул шигырьләрне. М.Җәлил кулында тышы таушалып беткән шактый гына калын күренгән куен дәфтәре була. Аны яшереп кенә йөртә. Ул шигырьләрнең дә шактые «Моабит дәфтәрләре»нә кертелә. М.Җәлил монда Гарәф Фәхретдиновны очрата һәм аңа да байтак шигырьләрен әйтеп яздыра. Ул аларның кайберләренең «Моабит дәфтәрләре»ндә булуын, ә кайберләренең М.Җәлилнекеме, әллә башка кешенекеме икәнлеген тәгаен генә әйтеп бирә алмаган. Гобәйдулла Салиховка карата мондый икеләнүне әйтеп булмый.

Кем белә, журналда шушы турыда язмалар басылгач, бәлки, Муса Җәлилгә нисбәт ителгән шигырьләр тагын табылыр һәм алар геройшагыйрьнең «Седльце шигырьләре» дигән сәхифәсенә өстәлер.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Гобәйдулла Салихов саклаган ул алты шигырьне Муса Җәлил шигырьләре дип танырга ныклы нигез бар. Шулай да, аларны тел-стиль ягыннан яңача анализлау барыбер кирәк булачак әле. ■

ЯШӘҮ СЕРЕ

Роза Хәмидуллина,
Муса Җәлил исемендәге
Чаллы шәһәр үзәк китапханәсенең бүлек мөдире,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре



Тормыш шулай яратылган: «Килүләр бар җиргә, китүләр...» Алай булмаганда тормышның яме, яшәүнең тәме булмас иде. Бер дә юкка гына шагыйрь мондый юллар да тудырмас иде:

Килгән китә!
Без дә бер китәрбез
үзебезне үзебез аңламыйча.

Китапларында басылмаган әлеге шигъри юлларны күренекле татар шагыйре Кадыйр Сибгатуллин язып калдырган. Шигырьнең исеме үк «Бөек сер» дип атала. Кайсыбыз, яшәү серенә төшендем, диеп зурдан кубып әйтә ала. Юк, юктыр андый кешеләр.

Шигырь мине уйланырга этәрде: үзен-үзе аңлап яшәр өчен күпме гомер кирәк икән адәм баласына?

Ә бит шагыйрь безгә болай ди:

Туа кеше.
Озак яши кеше.

«Озак яши», — диме...

Шагыйрь фани дөньяда 52 ел яшәп калды. Күпме бу? Уйлап баксаң — күп тә кебек, аз да. Тукта!.. Мин сабыең да шул яшьтә икән ләбаса. Әйе, үземне сабый, дип атадым. Күңелем сабыйлык-

тан чыкмаган, әйтерсең лә әле кичә генә тормыш тәмен белеп яши башладым. Ә шагыйрь инде бу яшьтә, үзен-үзе эзләп, бары тик иҗат итеп, күпләгән шигъри юллар калдырып, бакыйлыкка күчә. Һәм, барчабызны уйланырга этәреп, тормышның һәр мизгеленнән мәгънә табып яшәргә өндәп, мәңгелек шигырьләр калдыра:

Яшәргә, дип кенә тудырылган
Гомере бар
кеше яши генә.

Шагыйрь тормышта уйчан, хисле, серле кеше иде. Аз сүзле, ләкин һәрбер сүзе төпле, уйланылган, зур мәгънәгә ия. Ул сөйләгәндә дә шигъри юллар белән сөйли, колагымда шулай яңгырап тора. Аның истәлекләренә мөрәҗәгать итәбез икән, мондый юлларга тап булабыз: *«Беренче шигыремне хәтерләмим, табигый, ул беркайчан да басылмагандыр. Ләкин ышанам: ул — минем уйнап үскән песи баласы, урамыбыздагы каз бәбкәләре, өебезнең ишек каты почмагында минем бишмәт итәген чәйнәп аптыраткан бозавыбыз турында булгандыр».*

Кадыйр Сибгатуллин гигант төзелешләр чорында Балык Бистәсеннән килеп, гомеренең соңгы елларын Чаллыда яшәп иҗат итеп киткән шагыйрь. Ул бу хакта горурланып менә болайрак язып калдыра:

...Белми кеше кайда югалтасын,
белми кайда нәрсә табасын.
Гомеремнең бер өлеше булып,
язмышыма кереп каласың.
(«Мәләкәс буе»)

Үзе төзегән шәһәргә горурланып, аның тарихын сурәтли, сокландыгыч поэмалар тудыра:

Яши Чаллы,
Заманаы аңа
Алып керә Тукай пар атлары!
(«Хыял»)

Кадыйр Сибгатуллин яңа калада бары тик 16 ел яшәде һәм гомер юлының соңгы битләрен язды. Аларда үткәнне, бүгенгене, киләчәкне чагылдырырга омтылыш көчле.

Гомерен кеше өчкә бүлеп яши:
Киләчәге,
бүгене,
үткәне.
Киләчәктә килер, диеп ышана
үткәннәрдән үзенең көткәне,

— дип яза шагыйрь «Бер ноктада» исемле шигырендә, аннары болай дәвам итә:

Үткәннәрен кеше сагынмаса,
үткәннәре аның юк, димәк.

Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның үткәне матур. Ул — татар шигъриятe тарихында бай мирас калдырып киткән олы шәхес. Иҗатын барлау бүгенгәчә тынып тормый. Шагыйрь архивында калган урысча тәрҗемәдәге шигырьләрен туплаган «Осенняя весна» (1999) һәм әдип исән чакта дөнья күрмәгән шигырьләрен эченә алган «Әйтте шагыйрь» (2002), сайланма әсәрләреннән генә төзелгән «Бер ноктада» (2007) исемле күләмле китаплары басылды. Тормышы һәм иҗаты турында тулы библиографик мәгълүматларны туплап, «Биобиблиографик күрсәткеч» китабы (2009) бастырып чыгарылды. Шагыйрь иҗатына багышланган республика күләмендәге фәнни-гамәли конференция үткәрелде һәм аның материаллары аерым җыентык булып дөнья күрде (2007), язучы, шагыйрь, филология фәннәре кандидаты Факил Сафинның «Шигырьләрнең кирәк чагы» исемле монографиясе басылып чыкты (2011), «Нурлар суга төшә сынып-сынып...» (2012) дип исемләнгән истәлек-хатирәләр китабы да укучыларга килеп ирешә.

Шагыйрь иҗаты бер генә укучыны да битараф калдырмый, чөнки әсәрләренә Җир, галәм, кешелек язмышы, тормыш-яшәеш турындагы уйтойгылары салынган. Без кайтып-кайтып аның шигырьләренә текәләбез:

Еллар үткән.
Мең еллар да үткән.
Миллион еллар шулай үтәр тагын...
Ачылыр, дип Бөек Яшәү Сере —
Һәрбер кеше әле көтәр тагын.

Кадыйр Сибгатуллин шигырьләре


Хәмит Латыйпов рәсеме

БӨЕК СЕР

Туа кеше.
Озак яши кеше.
Үлә кеше серне аңламыйча.
Илаһи Көч Җирдә йөртә аны
гомере буе һич тә алдамыйча.
Алмаш туа аңа.
Яши.
Үлә.
Ул да китә.
Сере кала шулай.
Йөзенчесе,
меңенчесе серне
ачылмаган килеш ала шулай.
Еллар үткән.
Мең еллар да үткән.
Миллион еллар шулай үтәр тагын…
Ачылыр, дип Бөек Яшәү Сере —
һәрбер кеше әле көтәр тагын.
Шуңа күрә дә бит Бөек Сер ул.
Бөек Сер ул һәрчак читтә тора.
Кеше аңа якынайган саен
шуның кадәр ул да китә тора.
Ул ачылмас.
Ачылса да бары
ачылыр ул башка затлар өчен.
Ачкычлары галәм төпләренә
салынгандыр мәңге саклар өчен.
Бер күкләргә карап уйлау кызык
үз-үзеңне һич тә алдамыйча.
Килгән китә!
Без дә бер китәрбез
үзебезне үзебез аңламыйча.
Яшәргә, дип кенә тудырылган
Гомере бар
кеше яши генә.
Илаһи Көч Җирдә йөртә аны,
алдамый ул —
бары дәшми генә.

1987

БЕР НОКТАДА

Гомерен кеше өчкә бүлеп яши:
киләчәге,
бүгене,
үткәне.
Киләчәктә килер, дип ышана
үткәннәрдән үзенең көткәне.
Бүгене белән яши.
Әйтми кеше:
и, кызганыч, диеп, киләчәк.
Киләчәктә кемдер:
әрәм булды
үткән гомерләрем, диячәк.
Онытасы килә үткәннәрен —
онытырга кирәк кемгәдер.
Кемнәрнеңдер үткәннәре төшкә
кара кайгы булып керәдер.
Онытып булмый.
Үзенең яшәвенә
була алмас кеше хәтерсез,
хәтеренә әгәр төшми икән,
үткәннәре аның кадерсез.
Гомер бит ул!
Аның мизгеле дә
тоелмыйча үтә бик сирәк.
Үткәннәрен кеше сагынмаса,
үткәннәре аның юк, димәк.
Яше җитә адәм баласының
үзе генә тойган ноктага.

Үткәненә борылып карар өчен
шул ноктада кеше туктала.
...Үткәннәрне бүген искә алдык,
дуслар белән барлап утырдык.
Безнең үткән —
калын китап икән,
бик игътибар белән укырлык.
Рәхәт булып китте,
җиңел булып...
Гомеребезне күрдек,
тойдык бер.
Тормыш безне урап үтмәгән дип,
горурланып уйлап куйдык бер.
Киләчәккә карап шәраб салдык —
чыңлап алды кулда тустаган.
Без үткәннәр өчен чәкештердек,
бүгенгесе,
шөкер,
узмаган.
Өчкә бүлә гомерен.
Өчесе дә
кирәк аңа гомер иткәндә.
Яши кеше.
Үзе белән бергә
өчесе дә кала үткәндә.
Үпкәләмәм.
Төгәл түгел, димәм,
бер көн артык,
бер көн ким булса.
Мин бик риза
минем киләчәгем
үткәнемә әгәр тиң булса!

1987

РИЗА ТҮГЕЛ

Кабиләсе инде үлеп беткән.
Иле-җире,
халкы югалган.
Шуны гына раслар өчен җирдә,
шаһит булып кына...
ул калган.
Чукрак-телсез итеп карый аңа
бу илдәге халык күптәннән.
Башка телне белми,
аның телен
белми икән җирдә бүтәннәр.

Сөйләшәсең үзең белән үзең,
сүз кирәкми,
димәк, дәшмисең.
Ишетә торып,
сөйли белә торып,
чукрак-телсез булып яшисең.
Каушадым мин,
өшеде күк җаным,
аңладым да шундый хәл барын.
Йөрәгемә сукты салкын дулкын
үтеп Австралия ярларын.
Бу яңалык түгел иде, юкса,
дөнья баткан күптән бу чиргә.
Азмы халык туып яшәгән дә,
азмы халык киткән бу җирдән?!
Бөек халык һәрчак җиңә килгән,
көчсезләрне көчле бетергән.
Йортын-җирен алган,
мал-мөлкәтен.
Үзен аскан,
аткан —
үтергән.
Хәзер инде бетерү ысуллары
камилрәк,
каннар коелмый.
Эри халык!
Ә үзенә бер дә
бетәр кебек булып тоелмый.
Җиренә дә тими,
алмый йортын,
исән-имин тора малы да.
Бөек халык әкрен генә аның
кереп бара газиз җанына.
Чөнки белә:
тән ярасы бетә,
каны исән булса терелә;
җаны үлсен дисәң,
тәнгә тимә,
богау сал син туган теленә.
Азмы инде телсез халык?!
Җирдә шаһитлары гына калалар.
Азмы инде
ата-ана телен
аңлый алмый торган балалар?!
Яши әле минем халык җирдә,
шаһит булып кына калмадым.
Туган телем исән-сау вакытта
бүтән халык телен аңлармын.
Бетәргә, дип түгел,
туган халык
ахыргача бергә барырга.
Беребез дә безнең риза түгел
чукрак-телсез булып калырга! ■

Каюм Насыйри яшәгән йорт

КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ АСЫЛ ТЕЛӘГЕ

Эльмира Шәрифуллина

Татар халкының күренекле шәхесләрен атаганда Каюм Насыйри исеме беренчеләрдән булып телгә килә. Бу – урынлы да, чөнки ул үтә дә киң кырлы, үтә дә зур эшчәнлек һәм ихласлык белән халкына хезмәт иткән асыл затларыбызның берсе.

Үзе тумышы белән хәзерге Яшел Үзән районы Югары Шырдан авылыннан. 1825 елның 14 февралендә дөньяга килгән. (Байтак вакыт туган елы аннан алда туып, нарасый чакта ук бакыйлыкка күчкән агасының туган елы белән бутап йөртелә.) Әти-әнисе шул заманның шактый ук укымышлы, зыялы кешеләре нәселеннән була.

Каюм Насыйри башлангыч белемне әтисе Габденнасыйр мулладан алганнан соң, унбиш ел Казанның бишенче мәхәлләсендәге мәдрәсәдә укый, гарәп, фарсы телләрен үзләштерә, үзлегеннән, бөтен нечкәлекләренә төшенергә тырышып, татар һәм урыс телләрен өйрәнә.

Хезмәт юлын Духовное училищеда татар теле укытучысы буларак башлый. Соңрак училищеның «дәвамы» булган Духовная семинариядә мөгаллимлек итә. 1871 елдан башлап, татар балаларына урыс телен укытуга керешә. Ләкин аның бу эше бик күп каршылыкларга очрый. Әмма К.Насыйри кыйбласыннан чигенми: мәгариф өлкәсендә санап бетергесез күп хезмәт куя, киләчәк буынны тирән белемле, тәрбияле итү

өчен төрле дәреслекләр, китаплар яза, аларны тормышкөнкүрештә, гамәлдә куллану юлларын күрсәтә, укучылары каршына басып үзе дәрес бирә.

Ул, чын мәгънәсендә, тәҗрибәле педагог, киң колачлы мәгърифәтче, универсаль галим була.

Шул ук 1871 елдан башлап, К.Насыйри журналга охшаш еллык өстәл календаре чыгарырга алына. Бу эшне егерме дүрт ел буе, бирелеп, эшен саннан санга камилләштерә барып башкара, халыкка аңбелем тарата.

К.Насыйри календарь белән беррәттән «Таң йолдызы» исемле газета да чыгарырга ниятли. Әмма теләге тормышка ашмый. Шунлыктан, календаренда фәнни һәм әдәби мәкаләләр, тәрҗемәләр дә урнаштыра.1888 елда профессор В.Смирнов әлеге хезмәтнең әһәмияте, кыйммәте турында югары бәя биреп язып чыга. Кыскасы, бу гамәлләре К.Насыйрины беренче татар журналисты дип танырга җирлек тудыра.

«Каюм Насыйри». Р.Вахитов рәсеме

Татар халкының авыз иҗатын, гореф-гадәтләрен өйрәнү, җыю, классификацияләп бастыру, алай гына да түгел, милләтенең акыл җәүһәрләрен дөньяга таныту җәһәтеннән дә армыйталмый эшләгән кеше ул. Мәсәлән, профессор Н.Ф.Катанов: *«Насыйри әфәнде тарафыннан җыеп тапшырылган бу материаллар үз халкының искиткеч акыллы икәнен исбат итә...»* дип күрсәтә.

Шулай да, Каюм Насыйриның иң зур эшчәнлеге тел өлкәсенә карый. *«Бу өлкәдә ул бик катлаулы һәм күпьяклы хезмәтләр башкарды. Ул татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын, шуңа хакы һәм сәләте барлыгын исбат итте»*, — дип ассызыклый профессор Мөхәммәт Гайнуллин К.Насыйриның ике томлыгына (1974) язган кереш сүзендә.

«Урам теле, имеш,
Ломовойлар —
Әдәбият, фәнгә сәләтсез...» —
Шундыйларга каршы чыккан өчен
Насыйрига ярлык —
«Әдәпсез»...
Ни булса да булган,
Телгә каршы
Әшәке бер көрәш барганда,
Исән калган телем —
Каюм кебек
Фидаилар сөрән салганга!..

Шунысы сөенечле, Каюм бабабызның эшчәнлеге бүгенге көндә дә дәвам итә. 2014 ел ахырында КФУның филология һәм мәдәниятара багланышлар институты кочагында Каюм Насыйри институты ачылды. Аның максаты — туган телебезне, мәдәниятебезне,

Мәскәүдә К.Насыйри институты үзәген ачу вакыты. 17 декабрь, 2014 ел

рухи байлыгыбызны башка милләт вәкилләренә дә сөйләү, таныту; дөнья халыклары белән үзара дус, тату яшәү; кыйммәтен аңлаганнарга телебезне өйрәтү һ.б. Ә бу исә, һәрвакыт заман югарылыгында яшәргә омтылган К.Насыйриның иң асыл теләкләреннән була. Күренекле затыбыз яшәгән XIX гасырда әйтелгән тагын бер фикергә игътибар итик. Тюрколог, тарихчы В.В.Григорьев: *«Фән ноктасыннан бу* («Казан татарларының ышанулары һәм гореф-гадәтләре» исемле зур мәкалә. — *Э.Ш.*), *шиксез, бик кызыклы, яхшы ук гыйльми хәзинә бирергә вәгъдә итә торган эш. Бу хакта Каюм Насыйров тикшерүе — мөселман татарлары арасында гына түгел, бөтен ислам дөньясында да чыкканы юк, дисәк, ялгышмаган булырбыз...»*

Мөгаллим, галим, мәгърифәтче, язучы, тәрҗемәче, журналист, фольклорчы, җыеп әйткәндә, әдип-галим-энциклопедист. Әмма К.Насыйри калдырган рухи мирас әле бүген дә «үлчәнеп» бетмәгән.

Каюм бабабыз акыл эше белән беррәттән, физик көч сораган хезмәтләрне дә җиңел башкарган. Туган авылы Югары Шырданда аның үз куллары белән казыган коесы шуның

К.Насыйриның «Әбугалисина» китабы (1957) тышлыгы сурәте

бер дәлиле булып тора. Ул, аның рухи хәзинәсе кебек үк, бүген дә исән, бүген дә туган халкына хезмәт итә:

...Нуры булып изге гамәлләрнең,
Бер әдәбе булып,
Әхлагы –
Исән калган кое.
Һәм бүген дә
Тибеп тора көчле чишмәсе...

ҮТКӘННӘН ХӘБӘР

100 еллык бәйрәм (1825-1925)

Шушы февраль аеның 15ендә татарның карт язучысы Каюм Насыйриның туганына йөз ел тулды. Бу кеше 75 елдан артык гомер сөреп, үзенең шул гомерендә 40 ел чамасы вакыт гел китап язып бастыру белән шөгыльләнгән. Барлыгы ул төрле исемдә, татарча телдә 40 китап язган. Боларның эчендә бер-берсе 500 битле булганнары бар.

Аның китаплары арасында безнең авыл халкына билгеле булган «Әбугалисина», «Кырык вәзир», «Кырык бакча» дигән хикәят китаплары белән бергә авыл хуҗалыгы һәм башка эшләр турында язылган байтак китаплар бар.

Аның өстенә ул ел саен баштанаяк халык өчен кирәкле нәрсәләр белән тутырып, 24 ел буе зур күләмдә календарь язып килгән.

Каюм бабай татар телендә китап язган беренче кеше булып хисаплана. Ул үзе кече яшьтән үк Казанда торып, шунда үлгән. Менә аның шундый караңгылык заманда татар халкына иткән зур хезмәтләрен искә алып, аның туганына йөз ел тулган 15 нче февраль көнне бәйрәм ясалды. Татарстан хөкүмәте аның эшләгән эшләренә истәлек итеп, түбәндәге нәрсәләрне эшләргә булды:

1) Мәскәүдә гәзит язучылар укый торган йортта аның исеменә бер стипендия билгеләп, шунда һәрвакытта бер кеше укытып торырга;

2) Казандагы татар укытучылары җитештерә торган «Татар педагогика техникумы» дигән мәктәпне аның исеменә багышлап, «Насыйри мәктәбе» дип атарга;

3) Казандагы Евангелистовский һәм Яңа Бистәдәге Большой Симбирский урамнарны Насыйри урамнары дип атарга;

К.Насыйриның вафатына 40 ел тулу уңаеннан чыгарылган марка

«Сабанчы» газетасының (Пенза) тышлык сурәтләре



Да здравствует союз рабочих и крестьян!

„САБАНЧЕ"
(Пахарь)
Еженедельная Крестьянская Газета
Издание Пензенского Губисполкома и Губкома Р.К.П. (б).
Подписная плата на 1 мес. 20 коп. на 3 мес. 50 коп.
Адрес Редакции: Губисполком. Комн. №4
Год Издания Третий.

№ 10 (76)
Среда
مارت
25
Марта
چارشەنبە
1925 г.

г. Пенза,
Редакции «САБАНЧЕ»

4) Аның кирәклерәк китапларын сайлап, яңадан бастырырга һәм аның турында аерым бер китап ясарга.

Тәхәви К.Г.

(Мәкалә Пенза шәһәрендә чыккан «Сабанчы» газетасыннан алынды (28 февраль, 1925 ел, №7). Аны гарәп имлясыннан кириллицага филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты доценты Энҗе Кадыйрова күчерде.)

ӘНИ ТАВЫШЫ

Зимфира Гыйльметдинова

Ана белән Бала. Актриса белән Режиссёр. Гомер буе бер театрга хезмәт иткән икәү өчен бу төшенчәләрнең кайсы мөһимрәк? Кайсы комачаулый? Режиссёр анасы булу – горурлык, ә әниең озак еллар актриса булган театрның баш режиссёры булу җиңелме? Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының баш режиссёры Фәрит Бикчәнтәев белән без актриса-ана Наилә Гәрәева һәм аның режиссёр улы арасындагы мөнәсәбәтләрнең илле елдан артык гомерле тарихын барлыйбыз.

– Сез, башка артист балалары кебек үк, «сәхнә арты» баласы. Театрга беренче килүегезне хәтерлисездер?

— Театрга мине бик иртә алып килгәннәр, ул вакытта аңларлык яшьтә дә булмаганмындыр әле. Биредә үстем диярлек. Театрда мине яраталар, актриса апалар миңа карата бик игътибарлы иде. Хәтеремдә Фатыйма апа Ильская бик яхшы сакланган. Мәсгудә апа Хәйруллинаны ярата идем, чөнки ул барлык кара чәчле актрисалар арасында аксыл чәчле булуы белән аерылып тора иде. Әти белән әнинең гастрольдән кайтып кермәүче артистлар икәнлеген дә бик кечкенәдән аңладым. Чөнки еш кына алардан аерылып кала һәм бик сагына идем.

— *Үсә төшкәч театрдагы матур актрисалар белән әниегезне чагыштыргансыздыр әле?*

— Юк, чагыштырганым булмады. Киресенчә, мине әнинең төсе-бите белән башкалардан аерылып торуы һәрчак бераз каушата иде. Дәү әнием аны матур киендерергә, кешедә булмаган киемнәр алырга яратты. Әллә кайлардан ул заманнарда сирәк очраган кием-салым табып кайта да, әни белән икесе арасында мондыйрак сөйләшү була:

— Моңа охшаган киемне кеше өстендә күргәнең булдымы?

— Юк.

— Бик яхшы, димәк, әйбәт әйбер.

Әнинең киемнәре дә бик-бик җете иде, үзе дә ул елларда гаҗәеп популярлык казанган, исеме яңгыраган актриса булды. Урамнан тыныч кына узу мөмкин түгел, кешеләр безгә борылып-борылып карый. Аның ап-ак төстәге йон тужуркасын хәтерлим. Шуны кигән көнне Подлужный тавыннан шәһәргә менеп җиткәнче бар кешенең күзе бездә генә була. Мин бу хәлдән шактый уңайсызланып, йә алдан чабам, йә әнидән артка калып барам.

— *Оялу, дисез, ә соклану, әниегезнең матурлыгына соклану булгандыр бит?*

— Айдынны, Гүзәлем Әсәлне уйнавын күреп соклануым истә. Актриса буларак чын-чынлап гашыйк иткән роле — «Диләфрүзгә дүрт кияү»дәге Диләфрүз булды. Аның тавышы, аның көлүләре!.. Бервакыт мин радио-

дан «Беренче мәхәббәт» спектаклен тыңладым һәм анда әнинең тавышын ишетеп шаккаттым. Анда әти дә бар, әмма әнинеке — таң калырлык матур. Спектакльне радиога яздырганда студент кыз булган әле ул, ә шундый катлаулы, зур рольне башкарып чыккан. Әлеге радиоспектакльне берүзем мөкиббән китеп тыңлап утырдым. Әнигә карата тагын бер хис — көнләшү хисе бар миндә. Мәхәббәт героиняларын уйнаучы актриса бит ул. Балачакта әнине нык сагынган, юксынган вакытларым истә. Берсендә, миңа алты яшьләр булгандыр, Подлужный урамындагы йортыбызда ялгызым калдым. Безнең фатир ике катлы агач йортның беренче катында урнашкан. Баштарак түздем, түздем... аннан мине курку басты. Караңгы ныграк төшкән саен, курку артканнан-артты.

Аннан әнинең киемнәрен алып исни һәм елый башладым. Әти белән әни аерылгач, миндә әнигә ярарга тырышу, кечкенә булсам да, аның тормышын ничектер ямьле итү, җиңеләйтү теләге көчәйде. Биш яшемдә шактый йөгерек итеп укырга өйрәнгән идем инде. Күз алдымда бер күренеш тора: бәләкәй генә кухнябыз кебек җирдә әни керосинкада керләр кайната. Мин аның янына чыгып утырып, кычкырып китап укыйм. Әнинең янымдагы иң якын кеше икәнлегемне бик яхшы аңлый идем. Хәзер әни әтисез үсүемә үзен гаепләп, гел хәтерендә казына. Мин аңа беркайчан да үпкәләмәдем, аны гаепләмәдем. Килешмәү бар иде, ләкин һич тә рәнҗеш яки үпкә түгел.

— *Бер уйласаң, әтиегез сездән ерак та китмәгән, бер шәһәрдә — кул сузымында гына...*

Н.Гәрәева, Ф.Бикчәнтәев – «Алмазбулат» (Ю.Сафиуллин) спектаклендә

— Әти мине еш кына үзенә ала иде, шимбә-якшәмбеләрдә даими диярлек әти янында булдым. Аның белән без бик якын идек. Ләкин вафатыннан соң, никтер, бер тапкыр да төшемә кергәне булмады...

— *Алар яхшы мөгамәләдә калдылармы?*

— Аны алай гади генә әйтеп-аңлатып булмый. Әти бит театрдан китте. Һәм үз теләге белән китмәде. Театрга килергә яратмый иде ул. Очрашырга әллә ни мөмкинлекләре дә булмагандыр. Икенчедән, ул вакытларны азагына кадәр ачып та бетереп булмый әле...

— *Наилә апа Сезнең белән чиксез горурлана. Юбилеегыз алдыннан аның белән әңгәмә корганда, миңа Сезнең өчен бик борчылуы хакында да сөйләгән иде. Ул боларның берсен дә яшерми — күрсәтеп куана, күрсәтеп борчыла. Минем уемча, бу ярату — бер авыру дәрәҗәсендә. Сез моны үзегез ничек кабул итәсез?*

— Төрлечә. Акылым белән мин әнине аңларга тырышам, ләкин кырыс булырга да туры килә. Тавышымны ишетми торса, көн дә иртә-кич шалтыратмасам, ул сырхаулый, хафалана башлый. Хафалануын күрсәтмәскә тырыша. Ләкин барыбер күренә инде. «Театрда мин синең малаең түгел», — дип шелтәлим дә үзен. Нишләтәсең, әни кеше өчен мин барыбер бала, ул мине яратып, «балакаем» дип йөртә. Мин кайчак оялып, качып та йөрим аннан.

— *Минемчә, ана мәхәббәтендә берниндi оят юк...*

— Теориядә шулай да ул... Бүген әле Марсель абый Сәлимҗанов белән булган бер әңгәмәне тыңлап утырдым. Ул анда: «Әни минем күп спектакльләремдә уйнады. Минем белән эшләү аңа җиңел булмады. Аны башка артистларга караганда күбрәк сүгә идем», — ди.

— *Сез дә шулаймы?*

— Әйе.

— *Сез бик музыкаль кеше. Әниегезне нинди музыкага тиңләр идегез?*

— Әнине нindider музыкага, чәчәккә, төскә тиңләргә әзер түгел әле мин. Эчке дөньясы шулкадәр бай аның, ул кичергән вакыйгалар, хисләр минем хәтердә дә тупланып бара. Ләкин алар әле нindider музыка рәвешендә түгел.

— *Әниегезнең Сезгә ясаган иң зур бүләге нинди?*

«Go! Баламишкин» спектакленнән соң

— Миңа дүрт яшьләр булганда әти белән әни Ленинградтагы гастрольләреннән тышына машина рәсеме төшерелгән шоколад алып кайткан иде. Әле дә хәтерлим аны. Балачакта иң истә калган күчтәнәч — шул. Әни ул гел — һәрбер премьерага, сезон ачылуга, туган көннәр, Яңа еллар тагын әллә нинди бәйрәмнәргә бүләкләр ясый. Дәү әнием Рауаннан күчкән гадәтедер бу. Ул: «Бер вакыйга да гади генә, сизелмичә генә узарга тиеш түгел», — ди иде. Бүләк алмаса, әни, һич югы, открытка булса да язып куя. Аның шундый күркәм гадәте бар. Улым Йосыфка да мәктәпкә киткәндә, мәктәпне тәмамлаганда, башка вакыйгалар уңаеннан биргән бүләкләре бихисап. Кечкенә чагымда мин аквариум сорап алдырган идем. Йосыфка ул электропианинога кадәр бүләк итте. Миндә соңгы елларда әни бүләк иткән китаплар, статуэткалар... шулкадәр күп! Барысын да искә төшереп тә бетереп булмый. Армиядә хезмәт иткәндә әдәби, театраль журналлар, китаплар салып посылкалар җибәрүе...

— *Ә сез аңа еш бүләк бирәсезме?*

— Кызганыч, юк. Ул миңа моны сеңдереп-сеңдереп маташа да, тормыш ыгы-зыгысы барыбер һаман оныттыра бара.

— *Фәрит әфәнде, ә театрны профессия итеп сайлавыгыз, шулай ук әниегезнең теләге идеме?*

— Мәктәпне тәмамлагач, минем бик зур теләгем — музыка юлыннан китү мөмкинлегем бар иде. Гитара белән нык кына мавыктым. Музыка мәсьәләсендә миңа әнинең абыйсы зур йогынты ясады. Ул оркестрда скрипкада уйный иде. Театрда да күбрәк вакытны оркестр янында уздыра идем. Музыка, уйнаулары, әзерләнүләре миңа бик кызык иде. Барабаннарда уйнарга кызыктым, бер барабанчы янына музыка училищесына өйрәнергә дә йөрдем. Гитарада уйнарга Пионерлар сараендагы ансамбльгә йөрдем. Ләкин мин мәктәп тәмамлаган елда музыка училищесының гитара курсына укучылар алмадылар. Матбугатта театр училищесына студентлар җыю хакында белдем дә, шунда киттем. Аңарчы да Марсель абый Сәлимҗанов театр учи-

лищесына чакырып йөри иде. Мин ул чакта моңа катгый рәвештә каршы килдем. Ә мәктәпне тәмамлагач, үзем шул училищены сайладым да куйдым. Әни дә: «Ярар», — диде. Әзерләнә башладым: Лермонтов шигырьләрен өйрәнәм, урыс мәсәлләрен… Әни ишетеп алды да: «Син нәрсә, урыс бүлегенә бармакчымы? Әтиең дә, мин дә татар театрында эшләдек. Урыс бүлегенә керсәң, кеше күзенә ничек күренермен? Син бит татар театрында үскән бала!» — дип, каршы төште. Биш яшемә кадәр мин урысча бер сүз дә белми идем, ә мәктәпне тәмамлаганда татарча начар сөйләшә идем. Шуннан соң әни татарча шигырьләр, мәсәлләр өйрәтеп, имтиханга үзе әзерләде. Һәм мин театр училищесының татар бүлегенә укырга кердем.

Армиядә чакта бервакыт әни килеп төште. Кунакханәдә өч көнләп яшәде. Шулчакта мин аңа ГИТИСка кире кайту теләгем юклыгын әйттем. Өч көн эчендә бу уемнан да кире кайтарды ул. «Бичура» пьесасын да ГИТИСның III курсында укыганда әни табып җибәрде. Питерда укыйм, ул чакта телефоннар юк, «переговорный»дан атнага бер тапкыр үзем шылтыратам. Шул сөйләшүләрнең берсендә ул: «Худсоветта Мансур Гыйләҗевнең «Бичура» дигән пьесасын укыдылар. Худсовет ошатмады, миңа ошады. Сиңа җибәрәм, укып кара әле», — диде. Мин укыдым, пьеса ошады. Кайттым да Марсель абыйга: «Бичура»ны куям», — дидем. Марсель абый да җиңел генә ризалашты. Тормышымда әнидән башка кабул ителгән карарлар булмады, диярлек. Нинди генә юл башыма әйләнеп карасам да, анда Наилә Гәрәева тора. Ул минем киңәшчем дә, ярдәмчем дә, чын кайгыртучым да.

— *Сез махсус аның өчен «Бабайлар чуагы»н куйдыгыз, башка спектакльләрдә бик күп матур рольләр бирдегез…*

— Алдагы сезонда без аның белән тагын бер яңа әсәр — «Исәнме, улым»

Л.Хәмитова, Й.Бикчәнтәев, Ф.Бикчәнтәев, Н.Гәрәева

драмасына репетицияләр ясый башладык. Пьеса буенча — ана улы белән озак кына телефоннан сөйләшә. Әсәрне укый башладык, әни елый да елый, җөмлә саен елый. Мин әйтәм: «Нәрсә булды соң, нигә елыйсың?» — дим. Хискә бирелеп, текстта үз тормышына, халәтенә тиңдәшлек күреп елый икән. «Рольне алай уйнап булмый бит. Скрипкачының, пианиночының уйнаганда, рәссамның рәсем ясаганда елаганын күргәнең бармы синең?» — дим. «Юк», — ди. «Ә ник син барын да үзеңә кабул итәсең? Бу әсәр синең турыда түгел, башка кеше турында», — дим. Мин аның белән шулай артык хисләрен тыю өчен дә «көрәшәм». Бер яктан безнең мөнәсәбәтләр кызык та — элек ул миңа укыган «нотыклар»ны хәзер мин аңа укыйм: «Болай итмә, тегеләй итмә…»

— *Әнине өйрәтер дәрәҗәгә җитә алсак та, әнидән дә зирәк булыр дәрәҗәгә беркайчан да җитеп булмый.*

— Булмый, анысы дөрес. Тик әниең сау-сәламәт йөгереп йөргәндә,

рәхәтләнеп иҗат иткәндә андый фәлсәфә уйга килми. Көндәлек мәшәкатьләр белән яшисең дә яшисең.

— *Наилә апаның уйнарга теләп тә, уйнамый калган рольләре күпме?*

— Уйныйсы килгән барлык рольләрен уйнап чыккан берәр актриса яки актёр бармы икән ул? Аның Арбузовның Татьянасын уйныйсы килгәнлеген беләм. Укырга кергәндә үк: «Анна Каренинаны уйныйсым килә», дигән. Шәһәрдә туып-үскән, күбрәк урыс әдәбиятында тәрбияләнгән кыз бит ул. Икесенең берсен дә уйный алмаган. Пионерлар йортына йөргән, музыкага өйрәнгән, актив комсомолка булган. Бабай, әниемнең әтисе, Хәким абый Сәлимҗановлар белән бик дус булган, әби бик татар җанлы, татар рухлы булган, шунлыктан әни татар рухын да югалтмаган. Уйнаган рольләре, «йолдыз» булып балкыган еллары да күп аның, артист язмышына үпкәли торган түгел.

— *Сез Наилә апаны Бәрәскәдәге үзегез яраткан йортыгыз каршында бәбкә саклап утырган дәү әни итеп күз алдына китерә аласызмы?*

— Юк. Ул бит тынгысыз җан, бер көн дә тик утыра алмаячак. Ул бит әле укыта, туганнары янына чаба, театрга бер көн килми түзми. Аңа кем генә мөрәҗәгать итмәсен, шунда ук ярдәм итә башлый. Йосыфның лицеенда төрле кичәләр әзерләшә.

— *Сез режиссёр буларак сәхнәдә аңа кисәтүләр ясыйсыз, тәнкыйть сүзе дә әйтәсездер. Ә аның Сезгә кеше алдында кисәтү ясаганы яисә тавышын күтәргәне булдымы?*

— Юк, беркайчан да. Спектакль чыгарганда да мин аны чакырам, әкрен генә әйтәм: «Әни, килеп кара әле, нәрсәдер килеп чыкмый минем», — дим. Ул килеп карый, аннары без аның белән киңәшләшәбез, сөйләшәбез, аңлашабыз. Аның киңәшләре һәрвакыт кирәк һәм кадерле минем өчен. Ә кеше алдында ул миңа беркайчан да бернинди кисәтү ясамый.

— *Кечкенә чакта каеш эләккәне булдымы соң? Әни кешегә шук ир баланы ялгыз үстерү җиңел булмагандыр?*

— Каеш эләкмәде, бервакыт киез итек эләкте. «Ярды» гына әни киез итек белән. Мин мәктәптән бер көнгә өч «берле» алып кайткан идем. Беренче сыйныфка әнинең апасы — Эльза апам илтте. Әниләр бик озак гастрольдә иделәр. Әни юк та юк, аның юклыгыннан беренче сыйныф миңа гаять авыр бирелде. Эльза апа гел сүгә, гел сүгә, дәрес әзерләү кыен... Менә, ниһаять, әни кайтты... Мин дә «берле» төяп кайттым. «Син бик озак югалып тордың. Шуңа алдым мин аларны!» — дигән балаларча протест булгандыр ул. Башлангыч сыйныфларда укуны бөтенләй яратмадым. Рәсем ясыйм, башка эшләр белән шөгыльләнәм. Бишенче сыйныфка гына «җыйналып», грамоталар, дипломнар алып укый башладым.

— *Әңгәмә азагында әниегезгә нинди теләк әйтер идегез?*

— Саулык, сәламәтлек телим. Тынычлык теләп булмый, чөнки ул — әйткәнемчә, тынгысыз җан. Бүгенге көнгә кадәр түләп бетермәслек бурычлы мин аңа. Әнинең театрда булуы — минем өчен бәхет. Кайбер вакытларда аның артык игътибарыннан уңайсызлык кичерсәм дә, объектив яктан карасаң — мин бәхетле кеше. Иң зур теләгем: үзенә күбрәк игътибар бирсен, үзен сакласын иде.

Әңгәмә тәмамлангач, Фәрит Бикчәнтәев өстәленнән Наилә апа бүләк иткән тагын бер китапны табып алды. Тышлыкны ачып, истәлек язуын эзләде. «Ә менә бу китапны әле күптән түгел генә бүләк итте ул миңа. Нишләптер, язмаган бу юлы, гадәттә, гел истәлек язуы калдыра иде. Сәер...»

Бер тапкыр язу калдырмаган... Әни кешенең игътибарында бер тапкыр кечкенә генә деталь җитмәгән. Улы сизгән. Димәк: «Әнинең миңа булган игътибары кайчак артыграк», — диюе дә... болай, ир балага хас гади кыркулык кына. Бер дә сәер түгел... ■

Илһам сәйраны

Милләтебезнең күренекле каләмкярләре һәм сәнгатькярләре быел да сентябрьнең матур бер көнендә Аккош күленә – мәшһүр җырчыбыз Илһам ага Шакировка нисбәтле «Илһам сәйраны»на җыйналды.

Быел Илһам аганың күркәм юбилееен — 80 яше тулуын киң җәмәгатьчелек зурлап билгеләп үткән иде. Баксаң, «Илһам сәйраны»на дә ун ел булган икән!

Табигатьнең гүзәл урынында узган әлеге сәйранда һәр чыгыш ясаучы якты истәлекләргә бирелеп алды, «Җыен» фондының башында торучыларның берсе булган Дамир Сираҗиев, шулай ук фидакяр затларыбыз Миркасыйм Госманов, Шәүкәт Биктимеров, Туфан Миңнуллин исемнәре ихтирам белән яд ителде, хөрмәтле җырчыбыз Илһам ага Шакировка багышланган шигырьләр һәм җырлар яңгырады.

Сәйранга җыйналучылар бөек җырчыбызга исәнлек-саулык теләделәр, «Илһам сәйраны»н әүвәлге еллардагыча истә калырлык итеп оештырганы өчен «Җыен» фонды директоры Фоат Рәфыйковка зур рәхмәтләрен ирештерделәр. ■

«МӘҺДИЕВНЕҢ ШӘП ЯЗУЧЫ БУЛАЧАГЫНА ШИКЛӘНМИМ...»

13 февраль, 1969 ел.
Татарстан Язучылар берлеге идарәсе.

Утырышта катнашалар: Ибраһим Гази, Афзал Шамов, Атилла Расих, Гомәр Бәширов, Валерий Синев, Илдар Юзеев, Хәмит Ярми, Рафаэль Мостафин, Мәрзия Фәйзуллина, Зәки Нури, Мирсәй Әмир, Николай Беляев, Мөхәммәт Мәһдиев, Кыям Миңлебаев, Равил Фәйзуллин, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни, Сафа Сабиров, Ян Винецкий, Ләбибә Ихсанова, Гази Кашшаф (*әлеге утырышта катнашучыларның бүген нибары өчесе генә исән-сау: М.Фәйзуллина, Н.Беляев һәм Р.Фәйзуллин. — **Л.Л.***).

Көн тәртибендә:

1. СССР Язучылар берлегенә яңа әгъзалар кабул итү (Н.Беляев, С.Сабиров, М.Мәһдиев);
2. В.И.Ленинның тууына 100 ел һәм ТАССРның оешуына 50 ел тулуны билгеләп үтү уңаеннан Татарстан Язучылар берлегенең иҗади-оештыру эшләре, шул нисбәттән иҗат секцияләре алдында торган бурычлар;
3. Татар фольклорына багышланган кичәне уздыру турында (Х.Ярми);
4. Гаризалар карау.

Утырыш башлана.

Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы секретаре вазифасын башкаручы **Равил Фәйзуллин** идарә әгъзаларын Николай Беляев документлары белән таныштыра:

— Николай Беляев, 1937 елда туган, урыс, шагыйрь һәм тәрҗемәче, «Голоса расстояний» һәм «Ветер» дигән шигъри китаплар авторы. Тәкъдим итүчеләр: Давыт Көгелтдинов, Геннадий Паушкин, Рафаэль Мостафин.



Равил Фәйзуллин



Николай Беляев

Рафаэль Мостафин

Сибгат Хәким

Н.Беляев иҗаты турында сүз алып сөйләүчеләр:

Рафаэль МОСТАФИН. Николай Беляевның иҗади эшчәнлеген күптәннән — 1959 елдан бирле күзәтеп киләм. Үзенчәлекле һәм кызыклы шагыйрь. Шушы көннәрдә генә ул Муса Җәлилнең яңа шигырьләрен тәрҗемә итте. Миңа ул тәрҗемәләр бик ошады.

Сибгат ХӘКИМ. Николай Беляев турында Давыт Көгелтдинов бик әйбәт әйткән. Аның иҗаты турында М.Соболь дә кызыклы гына рецензия язган. Дәрдемәнднең тууына 100 ел тулу уңаеннан Беляев әлеге шагыйрьне тәрҗемә итәргә алынды. Әйтергә кирәк, аның тәрҗемәләре бу өлкәдә җиң сызганып эшләүчеләрнекенә караганда яхшырак килеп чыга. Безнең классик шигъриятебезнең Казанда үз тәрҗемәчесе булганга сөенергә генә кала. Мин Николай Беляевны Язучылар берлегенә чын күңелемнән тәкъдим итәм.

Мирсәй ӘМИР (Н.Беляевка). Ничек тәрҗемә итәсең?

Николай БЕЛЯЕВ. Юлга-юл аудару (подстрочник) ярдәмендә.

Фатих ХӨСНИ. Мин Беляев иҗаты белән күптән түгел генә таныштым. Аның «Голоса расстояний» китабын бер тында укып чыктым. Ул миңа бик ошады. Заманча, традицион шигырьләр. Бик шәп шагыйрь. Тәрҗемәләрендә бернинди «өйрәнчеклек» юк. Барысы да чын мәгънәсендә шигъри. Николай Беляевка шатланып тавыш бирәм.

Зәки НУРИ. Миңа Беляевның шәхес буларак тыйнаклыгы ошый. Аның шигырьләре дә, тәрҗемәләре дә күңелемә хуш килә. Беляев безгә зур ярдәм итәр, дип ышанам. Һәм безгә аны файдаланырга кирәк. Язуын күбрәк язсын. Сыйфат ягыннан калышмыйбыз, сан ягыннан бары тик алга! Мин Беляевны әгъзалыкка кабул итү ягында.

Афзал ШАМОВ. Кайда тудыгыз? Үзегез турында сөйләгез әле.

Н.БЕЛЯЕВ. Ярославльдә туганмын. 1941 елда Уфа аша Саратовка эвакуацияләндек. 1947 елдан бирле Казанда яшим. Монда мәктәп һәм университет тәмамладым. Ил буйлап күп йөрдем: Урал, Себер, Кузнецк, Ала-тау... Болар минем «геологик үткәнем» белән бәйле. Геолог, инженер-конструктор, журналист булып эшләргә туры килде. Хәзер Дәрдемәнд шигырьләрен тәрҗемә итәм.

Ибраһим ГАЗИ. Тагын нинди планнарыгыз бар?

Н.БЕЛЯЕВ. «Ветер» китабыннан соң (ул озакламый кибет киштәләрендә пәйда булырга тиеш), 1971 елда өченче китабымны нәшер итәргә уйлыйм. Параллель рәвештә тәрҗемәләр белән дә шөгыльләнәчәкмен.

Ф.ХӨСНИ. Сезнең кумирыгыз кем?

Н.БЕЛЯЕВ. Кумирларым күп — Пушкин, Лермонтов, Блок... Замандашларымнан Межиров, Евтушенко иҗатлары бик якын. Гомумән, һәрбер шагыйрьдән, һичьюгы, бер яхшы шигырь табарга була.

Ибраһим Гази

Мирсәй Әмир

Афзал Шамов



Сафа Сабиров

И.ГАЗИ. Фикер алышуларны туктатырга һәм тавышка куярга, дигән тәкъдим бар.

Яшерен тавыш бирү юлы белән Н.Беляев бертавыштан СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә.

Р.Фәйзуллин утырышта катнашучыларны Сафа Сабиров документлары белән таныштыра:

— Сабиров Сафа Сабир улы, 1915 елда туган, татар, прозаик һәм тәрҗемәче, Казан һәм Мәскәү нәшриятларында басылган күпсанлы китаплар авторы (барлыгы 15 китап). Тәкъдим итүчеләр: Әмирхан Еники, Габдрахман Әпсәләмов, Атилла Расих.

С.Сабиров иҗаты турында сөйләүчеләр:

Гомәр БӘШИРОВ. Киләчәккә нинди иҗади планнарың бар?

Сафа САБИРОВ. Кечкенә бер повесть язарга керештем. Озакка сузмыйча гына тәмамлармын, дип уйлыйм.

З.НУРИ. Кабул итү комиссиясенең фикере ничек?

Г.БӘШИРОВ. Комиссия кабул итәргә, дигән фикердә. Сафа Сабиров елгачылар тормышын яхшы белә һәм алар турында начар язмый. Без Сафа Сабировны кеше буларак та, язучы буларак та, нәшрият хезмәткәре буларак та яхшы беләбез. Безнең фикеребезчә, ул Язучылар берлегенә лаеклы кандидат.

Атилла РАСИХ. Сафа Сабиров нәшриятта озак еллар эшли. Аның белән төрле темага бәхәсләшергә мөмкин. Ул әдәбиятка изге эш итеп карый. Тыйнак кеше. Болар барысы да әйбәт, әлбәттә. Әмма бер тыйнаклык белән генә ерак китеп булмый — кыюрак та булырга кирәк. Без аңардан эчтәлеге белән югары идеяле, зур күләмле әсәрләр көтәргә хаклыбыз.

Ф.ХӨСНИ. Миңа калса, без аның иҗатына бик җитди карамыйбыз төсле. Язучылар берлегенә кабул ителү ул — бик җаваплы эш. Иптәшнең җитешсез якларын да күрсәтергә кирәк. Мин Сафага кулымнан килгәнчә булышып киләм. Әйе, аның тормыш тәҗрибәсе бай һәм ул тормыштагы чын фактик материалларга таянып яза. Әдәбиятта күптәннән эшли, зур тырышлык куеп эшли. Вәләкин аның теле әле укучыны җитәрлек дәрәҗәдә канәгатьләндерерлек түгел. Бу хакта әйтми калырга ярамый. Ул — үсеп килүче каләм әһеле, киләчәктә прозада үз сүзен ныклап әйтер әле, дип ышаныйк. Мин Сафа Сабировны Союзга кабул итү яклы.

Р.МОСТАФИН. Мин Фатих Хөсни фикере белән тулысынча килешәм — Сафа Сабировны берлеккә алырга кирәк. Ул безнең арага бихисап иҗат белән килә. Әмма аңа әсәрләрен сыйфат ягыннан яхшыртасы бар әле.

З.НУРИ. Тавышка куярга кирәк, дигән тәкъдим бар.

Яшерен тавыш белән Сафа Саби-

Гомәр Бәширов

Зәки Нури

Мөхәммәт Мәһдиев

Илдар Юзеев

ров бертавыштан СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә.

Р.Фәйзуллин Мөхәммәт Мәһдиев документлары белән таныштыра:

— Мәһдиев Мөхәммәт Сөнгать улы, 1930 елда туган, татар, тәнкыйтьче һәм прозаик, «Без — кырык беренче ел балалары» дигән повесть һәм күпсанлы тәнкыйди язмалар авторы. Тәкъдим итүчеләр: Нәкый Исәнбәт, Гариф Ахунов, Ибраһим Нуруллин.

М.Мәһдиев иҗаты хакында фикер алышучылар:

С.ХӘКИМ. Мәһдиев иҗатын зур игътибар белән күзәтеп барам. Аның тәнкыйте үзенчәлекле, кызыклы. Мин аның шәп язучы булачагына шикләнмим. Мәһдиев төгәл детальләр белән кыска һәм тыгыз итеп яза. Язучыларның кайбер әсәрләре басылмыйча ятарга мөмкин. Мәһдиевнең дә андый әсәре бар. Ул — «Иж-Буби мәдрәсәсе» дигән мәкалә. Бу әсәреннән чыгып, Мәһдиевнең халкы өчен борчылып язучы икәнен аңларга була. Аның иҗади эзләнүләрендә халык белән, бүгенге тормыш белән тирәнтен бәйләнеш ята. Әдәбиятка тирән белемле, югары интеллектуаль галим килә. Ул тулы хокуклы совет язучысы саналырга хаклы.

Беренче рәттә (сулдан): **М.Әмир, Г.Ахунов, Л.Ихсанова; икенче рәттә: А.Расих, Ш.Галиев, Р.Мостафин. 1970 нче еллар**

Фатих Хөсни

Атилла Расих

Хәмит Ярми

Кыям Миңлебаев

А.ШАМОВ. Мин — Мәһдиевне шатланып каршы алучыларның берсе. Без аңа язучы итеп тә, җитди әдәбиятчы итеп тә карыйбыз. Кайсы отыры үсештә булыр — әлегә билгесез, әмма ни генә дисәк тә, ул талантлы. Аның «Без — кырык беренче ел балалары» дигән повесте — безнең өчен яңа, аерым бер проблемалар күтәрмәсә дә, бик яхшы әсәр. Кайбер җитешсезлекләрне күрсәтеп үтәргә була, ләкин алар Мәһдиев иҗатын бербөтен итеп караган вакытта әллә ни мөһим роль уйнамый.

Илдар ЮЗЕЕВ. Галимнәр турында язачаксызмы?

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ. Язмамдыр, мөгаен. Миңа авыл темасы якынрак.

З.НУРИ. Әйдәгез, Мәһдиевне тыңлыйк әле.

М.МӘҺДИЕВ. Повестьлар һәм хикәяләр язачакмын. Бер повесть тәмамладым инде. Ул хәзер «Казан утлары»нда. Сугыш һәм сугыштан соңгы еллар тәэсиреннән арына алмыйм. Гәрчә миңа авыл бик якын, флот турында да язасым килә. Мин дүрт ел флотта хезмәт иттем. Хәзерге вакытта фәнни эш белән шөгыльләнәм, тәнкыйть белән дә кызыксынам. Тәнкыйть — тынгысыз һәм авыр хезмәт, әмма мин аны ташларга җыенмыйм. Университетның татар теле һәм әдәбияты кафедрасында эшләвемне дәвам итәчәкмен.

М.ӘМИР. Мин, бәлки, аның иҗатын бик үк яхшы белмимдер, әмма шуны беләм — ул актив эшли. Повестен зур кызыксыну белән укыдым. Ләкин Мәһдиевне күккә чөяргә иртәрәк әле. Без аны артык мактап ташлап, иҗатына начар йогынты ясавыбыз бар. Язучылар берлегенә алырга кирәк, дигән тәкъдимнәргә бертавыштан кушылам.

А.РАСИХ. Мәһдиевнең потенциаль мөмкинлегенә ышанам. Элекке фәнни хезмәткәр буларак, берүк вакытта галим дә, язучы да булуның авырлыгын яхшы аңлыйм. Без аңа булышырга тиеш.

Ф.ХӨСНИ. Мәһдиев — кызыклы язучы. Аның һәрнәрсәгә үз карашы бар. Әсәрләренә нечкә юмор хас. Безнең әдәбиятыбыз өчен бу бик кыйммәтле, кирәкле шәйдер. Тавышка куярга тәкъдим итәм.

Яшерен тавыш бирү юлы белән М.Мәһдиев бертавыштан СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә.

Татар фольклорына багышланган зур кичә үткәрү һәм аның якынча планы турында фольклорчы-галим **Хәмит Ярми** сөйли:

— Кичә өч бүлектән булачак: революциягә кадәрге фольклор, совет дәвере фольклоры һәм үзешчән сәнгатькярләр чыгышы. Төрле стендлар һәм экспонатлар куелачак. Буфетларда милли ризыкларыбыз тәкъдим ителәчәк.

Хәмит Ярми чыгышыннан соң идарә — «кичәне үткәрү комиссиясенә Язучылар берлегеннән түбәндәге иптәшләрне кертергә кирәк», дигән нәтиҗәгә килә: **Г.Бәширов, А.Шамов, Х.Ярми, Л.Сәйфуллина.**

Шуннан соң Татарстан Язучылар берлеге рәисе **И.Гази** В.И.Ленинның тууына 100 ел һәм ТАССРның оешуына 50 ел тулуны билгеләп үтү уңаеннан Татарстан Язучылар берлегенең иҗади-оештыру эшләре, шул нисбәттән иҗат секцияләре алдында торган бурычлар хакында нотык тота. И.Гази чыгышы буенча җентекле фикер алышу булганнан соң, идарә карар бирә:

а) Алда торган юбилейларга нисбәтле материаллар туплау һәм чыгышлар-очрашуларның еллык планын төзү эшен пропаганда бюросына йөкләргә;

б) Республикабыз районнарына чыгып татар әдәбияты турында лекцияләр сөйләү өчен танылган язучылардан һәм галимнәрдән торган төркемнәр оештырырга.

— Бүгенге заман прозасы — Р.Мостафин, Ф.Мусин;

— Бүгенге заман поэзиясе — И.Юзеев, З.Мәҗитов, Х.Госман;

— Бүгенге заман драматургиясе — Б.Гыйззәт, А.Әхмәдуллин;

— Тукай һәм Дәрдемәнд иҗаты буенча — И.Нуруллин, Р.Харисов;

— Г.Ибраһимов иҗаты буенча — М.Хәсәнов, О.Кадыйров, Г.Әдһәмова;

— Ш.Усманов иҗаты буенча — А.Яхин, Н.Гыйззәтуллин;

— Такташ һәм Кутуй иҗаты буенча — Х.Госман;

— М.Җәлил һәм А.Алиш иҗаты буенча — Р.Мостафин, Г.Кашшаф, Н.Юзиев;

— Ф.Кәрим иҗаты буенча — С.Хәким, З.Мәҗитов;

— Г.Камал һәм К.Тинчурин иҗаты буенча — Б.Гыйззәт;

— Ә.Фәйзи иҗаты буенча — Т.Галиуллин, Н.Юзиев;

— Х.Туфан иҗаты буенча — Р.Мостафин, М.Гайнетдинов, Т.Галиуллин;

— С.Хәким иҗаты буенча — Н.Юзиев, Т.Галиуллин. И.Юзеев;

— М.Әмир иҗаты буенча — Ф.Хатипов;

— Ф.Хөсни иҗаты буенча — Р.Свиригин, Р.Мостафин, Ф.Мусин;

— Н.Исәнбәт иҗаты буенча — А.Әхмәдуллин, Ф.Урманчеев, Х.Мәхмүтов.

Бүгенге татар әдәбияты торышы һәм үз иҗатлары хакында чыгыш ясарга тиешле язучылар: Риза Ишморат, Шәйхи Маннур, Зәки Нури, Афзал Шамов, Габдрахман Минский, Илдар Юзеев, Гариф Ахунов, Шәүкәт Галиев, Гариф Галиев, Атилла Расих, Нурихан Фәттах, Гамил Афзал, Саҗидә Сөләйманова, Гөлшат Зәйнашева.

Көн тәртибенең чираттагысы гаризалар карауга багышлана.

Соңыннан шундый карар чыгарыла:

1. Язучылар берлеге әгъзасы С.Хәсәновка (Хәсән Сарьян) «Нокталы өтер» дигән китабын тәмамлау өчен 100 сум күләмендә матди ярдәм күрсәтергә;
2. Яшь язучы Рөстәм Мингалимовка яңа шигырь китабын төгәлләү өчен яшьләр фондыннан 50 сум күләмендә акча бүлеп бирергә;
3. Газиз Мөхәммәтшинга Минзәләгә 7 көнлек командировка тәкъдим итәргә;
4. Яшь язучы Таһир Госмановка яңа романын машинкада бастыру өчен 15 сум бирергә.

ТАССР Язучылар берлеге
идарәсе рәисе **И.Гази**

ТАССР Язучылар берлегенең
җаваплы секретаре вазифасын
башкаручы **Р.Фәйзуллин**

*Беркетмәне **Ләбиб Лерон** укыды.* ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

КАМЫТ — Гадәттә, бу сүз урыс теленнән алынма дип карала. Ләкин тел белгече Рифкать Әхмәтҗанов урысча «хомут» сүзе үзе үк төрки телләрдән алынган булырга мөмкин, дип исәпли һәм моңа кайбер дәлилләр дә китерә. «Britannica» энциклопедиясе дә камыт белән ияр Азия далаларыннан килгән, дигән фикердә тора.

Электә агач камытны «җөфт» дигәннәр. (Фарсыча «җефет» — «җөп», «пар», «иш», «куш» мәгънәсендәге сүз, димәк, «җөфт» — «куш агач» кебек камыт.) Үзбәкчә «камыт» — «бойынча», ягъни «муенча». Татарларда «мунчак»/«муенчак» исә — хайван муенына кигезелә торган элмәкле каеш яки бау. Камытны чөелдерек белән тарттырып бәйләп куялар. Камыт агачларының тоташкан җире «җилкәлек» дип атала. // Дөя камыты. Камыт агачы. Камыт бавы (Себер татарларында — «камыт колагы», «камытколак»). Камыт бөяте. Камытка бөят кую, бөят утырту. Үгез камыты — «боендырык» (монда да «муен» сүзе катнашканын күрәбез). Тау Иленең таулары, / Өзелә камыт баулары. / Камыт бавын ялгый-ялгый / Сызыла йөрәк майлары. *Тау Иле халкы җырыннан.*

МӨШТӘРИ Исмәгыйль Мингали улы (1888-1962) — Казандагы Мәрҗани мәчетенең имамы булып торган зат. Казан губернасының Тәтеш өязе Үтәмеш авылында (хәзер Татарстан Республикасының Апас районына керә) рухани гаиләсендә туган. Аның әтисе 1982 елдан югары Ындырчы

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

авылында (шулай ук Апас районына карый) имам булган. Исмәгыйль 1909 елда Казанда Дүртенче җамигъ мәчете каршындагы мәдрәсәне тәмамлый һәм беркадәр вакыт шунда хәлфә булып эшләп ала. 1911 елдан хәзерге Кама Тамагы районындагы Олы Бортас авылында имам-хатыйб була. Совет хакимияте урнашкач, имам репрессияләргә дучар ителә һәм фәкать 1941-1945 елгы сугыш тәмамлангач кына Казанда бердәнбер ябылмый калган Мәрҗани мәчетен җитәкли. 1956 елда ул мәчет бинасыннан төрле зарарлы кустарьчылык (мичкә ясау, җилем, олифа, дегет, буяулар җитештерү) цехларын чыгаруга ирешә. Мәчет ихтыяҗлары өчен «Москвич» һәм «Волга» автомобильләре сатып алына, бина ташкүмер ягып җылытуга күчерелә. Капиталь ремонттан соң мәчеткә Мәскәүдән зур өч кәндил кайтартылып түшәмгә эләләр, вәгазьләр микрофон ярдәмендә укыла башлый.

Мөштәри-хәзрәт — Татарстан АССР, Удмурт АССР һәм Пермь өлкәсе буенча мөхтәсиб, ДУМЕС (СССРның Аурупа өлеше һәм Себер мөселманнарының Диния нәзарәте) әгъзасы булган.

1962 елның җәендә, Мөштәри хәзрәтнең вафатыннан соң, аның вазифаларын вакытлыча мәзин С.Гыйззәтуллинга йөклиләр.

Бу чор Мәрҗани мәчете тормышында тотрыксызлык белән характерлана. Мөфти хәзрәтләре Ш.Хыялетдинов тәкъдиме белән Ростов шәһәреннән чакырылган К.Шәнгәрәевне халык кабул итми, шуннан соң мөфти беренче имам итеп мәчетнең бухгалтеры Ислам Алмановны «билгеләп карый». Әмма мөселманнарның күпчелеге аңа да каршы чыга, чөнки мөтәвәллиятнең финанс эшләрендә хилафлык табыла. Җирле хакимиятләр исә мәчетнең ялгышлар җибәргән башкарма органы рәисе Салих Тимерхановны яклап чыгалар. Эш КПСС Үзәк комитеты генераль секретаре Леонид Брежнев һәм КПССның

Мәрҗани мәчете

Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табиевлар исеменә күмәк шикаять язуга тикле барып җитә. Казан мөселманнары Дини культлар буенча Совет вәкиле Мангуткин, Идел буе районы советы рәисе урынбасары Имамиев һәм Идел буе милициясе начальнигы урынбасары Садыйковларның янап, мәчетне ябу ихтималы белән куркытуларыннан зарланалар. («Исторические мечети Казани» китабы буенча.) Ахырда Чиләбе өлкәсе Троицк шәһәре мәчете имамы Исмәгыйль Динмөхәммәт улы Рәхмәтуллин кандидатурасы барысын да канәгатьләндерә.

«МУЗЫКА ҖӘМГЫЯТЕ» — 1907 елда Казанда мөселман яшьләре оештырган җәмгыять. «Шәрык клубы»нда чыгыш ясаучы җәмгыять музыкантлары арасында скрипкачы Гали Зәйпинны, кыллы оркестр җитәкчесе Заһидулла Яруллинны, җырчылардан Фәттах Латыйповны, Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинны, Исмәгыйль Галиәкбәровны күрсәтергә мөмкин. Шул ук вакытта В.Апанаев, И.Галиәкбәровлар җитәкчелегендә милли оркестрлар барлыкка килә, алар уннарча музыкаль кичәләр һәм концертлар оештыра. ■

КУРАЙ

(ТР Милли музее фондларыннан)

Мәшһүр музыкантыбыз, композитор Ифрат Хисамов берьюлы ике курайда уйный. 1990 нчы еллар

Курайчы – Рафаэль Гайнетдинов

Арча районының танылган курайчысы, мөгаллим Айрат Зыятов (1971-2015) Ифрат Хисамов ясаган курайда уйный

Татарстан Республикасының Милли музеенда музыка уен кораллары коллекциясендә буйлы флейталар төркемендә сыбызгы курайлар саклана. Курайның тавышы, тембры һәм яңгырашы аның формасыннан һәм нинди материалдан ясалуыннан тора. Татарлар конус, цилиндр рәвешендә сыбызгы курай, кире конус рәвешендә көпшә һәм ачык телле курайларны үз иткәннәр. Аларны металл, агачтан ясыйлар һәм никадәр тишек ясалуына карап яңгырашлы көй чыгаралар. Карап торышка гап-гади тишекле бер таяк, ә үзеннән күпме моң, сагыш агыла...

Гүзәлия Җәләлева әзерләде.

Туфан абый үзе салган йорт янында (Биектау районы Кече Битаман авылында) учак тергезә. 20 сентябрь, 2011 ел

ЙОРТ ҖАНЛЫ ТУФАН

Ләбиб ЛЕРОН

Туган авылын, туган нигезен җаны-тәне белән яратучы татар баласы (үзе әйтмешли!) иде ул. Сагына иде авылын. Язганнарының күпчелеге тикмәгә генә авыл һәм аның кешеләре турында булмагандыр. Бер «Әлдермештән Әлмәндәр»е генә ни тора! Заманында Мәрәтхуҗадагы үз йортларында яшәп тә алды кебек. Кечкенә трактор *(кайбер як халкы аны «Беттем-беттем» дип атап йөртә. — **Л.Л.**)* сатып алуы, Туфан абыйның аны йөртеп азаплануы, артка чигә алмыйча иза чигүе хакында каләмдәш дусты Марсель Галиев мәзәк итеп тә язды…

Әйе, ярата иде ул авылны. Шуңадырмы, гомер кояшы баеп килгән бер вакытта, ягъни соңгы елларда, Туфан абый төрле җирдә йорт салу

яисә салдырту белән мавыгып алды: кайсын — кызык өчен, кайсын — ял итү өчен, кайберсен — яшәр өчен, бакчасында казынып өчен. Чын авыл баласы бит — ничек эшсез торсын инде Туфан!

Кайчандыр ул да, калага килгән күпчелек авыл баласы шикелле, фатирсызлык белән интеккән. Яңа фатирга өмет итүләр кая, искесе булса да ярар иде дә бит кана… Хәер, аның иске дигәнендә яшәве дә кайчак үзе бер газапка әйләнә…

Минем архивымда Туфан абыйга турыдан-туры кагылган, аның үз кулы белән язылган бер язма саклана. Ул — язучы, драматург, берлек әгъзасы, 34 яшьлек Туфан Миңнуллинның Татарстан Язучылар союзы *(ул чакта «берлек» дип аталмый иде әле. — **Л.Л.**)* идарәсенә язган үтенече:


Татарстан язучылары союзы идарәсенә
Язучылар союзы члены Миңнуллин Туфаннан
Үтенеч
Мин бүгенге көндә хатыным һәм балам белән бер бүлмәле (20 кв.м.) иске фатирда яшим һәм эшлим. Уңайлыклары юк: гомуми коридор, санузел юк, караңгы — көндез дә ут белән утырырга туры килә.
Шул сәбәпләр аркасында иҗат итүе кыен. Фатир бирүегезне сорыйм.
[подпись]
6 январь 1969 ел.
Халитов квартирасы бирелде III/69

Туфан Миңнуллинның үтенеч язмасы. 1969

Татарстан Язучылары
союзы идарәсенә
Язучылар союзы члены
Миңнуллин Туфаннан

Үтенеч.

Мин бүгенге көндә хатыным һәм балам белән бер бүлмәле (20 кв.м.) иске фатирда яшим һәм эшлим. Уңайлыклары юк: гомуми коридор, санузел юк, караңгы — көндез дә ут белән утырырга туры килә.

Шул сәбәпләр аркасында иҗат итүе кыен. Фатир бирүегезне сорыйм.

Имза.
6 январь, 1969 ел

Үтенеч астына кемдер «Халитов *(Яхъя Халитов, дип уйларга кирәк. — **Л.Л.**)* квартирасы бирелде. Март, 1969» дип язып куйган. Кем әйтмешли, иске фатирдан — иске «яңа» фатирга! Ул чорда шактый танылган тәрҗемәче-редактор Яхъя Халитов кадәр Яхъя Халитовның фатиры булгач, ул әллә ни начар булмагандыр әле. Яктырак, иркенрәк фатир булгандыр…

…Вафатына берничә ай калып барганда, эшкә якынрак булсын дип, Туфан абый Дәүләт Советы бинасы янындагы яңа бер таш йортка күчкән иде. Гаиләсе белән, әлбәттә. Ләкин ул фатирда озын-озак еллар иркенләп яшәргә, дәртләнеп иҗат итәргә язмады шул аңа: 2012 елның 2 май көнне Туфан ага Миңнуллинны Ходай үз хозурына — Мәңгелек йортына алды. Җирдә эш бетмәс, кайт әйдә, дигәндер инде… ■

«МИН КЕМГӘ ЭНДӘШИМ?..»

Рафаэль Сәхәби

Миңа безнең бөек композиторларыбыз, язучыларыбыз, артистларыбыз белән таныш булып, бергә эшләү бәхете тиде. Алар арасында Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин да бар иде. Яшь җырчыларга Рөстәм аганың әсәрен башкару — зур мәртәбә саналды. Сибгат Хәкимне дә аерып әйтәсе килә. Ул яшь җырчыларга карата шулай ук бик игътибарлы булды.

Көннәрдән беркөнне Рөстәм ага Яхин миңа Сибгат ага Хәким шигыренә язылган «Минем таныш өянкеләр» исемле җыр тәкъдим итте. Җыр үземә тәүдә үк бик ошады. (Рөстәм абыйның җырлары, гомумән, яхшы: бер ишетүдә истә кала торганнардан.) Репертуарыма керде, халыкның да күңеленә хуш килде. Бигрәк тә язучы Аяз Гыйләҗев ярата иде бу җырны. Язучылар берлегендә очрашсак, туктата да: «Сәхәби, слушай, парин, бер генә куплет җырла әле», — ди. Мин җырлый башлауга, үксиүкси еларга тотына.

Бу җырны мин әлегәчә җырлыйм. Аның сүзләре хәзер үземә дә тулаем туры килә инде...

Рөстәм Яхинның концертыннан соң. Рәсемдә (сулдан уңга): **Х.Бигичев, Р.Яхин, М.Якупов, З.Сөнгатуллина һ.б. 1980 нче еллар**

Р.Яхин яшь башкаручы дуслары Р.Сәхәбиев, Р.Ибраһимов, С.Раинбәков, Р.Дәминов белән. 1980 нче еллар



Р.Яхин үз кулы белән язган нота

МИНЕМ ТАНЫШ ӨЯНКЕЛӘР

Сезгә эндәшми мин кемгә
Эндәшим, өянкеләр?
Җитте минем дә, сезнең күк,
Картайдым, дияр көннәр.

Кабынды, янды бер чорда
Яшьлекнең саф хисләре.
Сез — минем мәхәббәтемнең
Бердәнбер шаһитләре.

Кайда ул бергә ашкынган,
Бергә шаулаган көннәр?
Минем таныш өянкеләр,
Сезгә баш ияр кемнәр?..

Җырланмаган җыр

Сәйдә Зыялы

Татарстанның халык артисткасы Нәфисә Василованың (Анастасия Петровна Васильева) якты истәлегенә багышлана

Натук күргән төшеннән сискәнеп уянды да, күргәннәрен күңеленнән кичереп, озак уйланып ятты. Балачагы, имеш. Биле авыртудан иелеп йөрергә мәҗбүр карчыктай алга авышкан, салам түбәле өйләрнең тәрәзә төбенә чүгәләп утырган да җырлый, имеш:

Ак калпагың ки сәнә,
Чугын артка чөй сәнә;
Эчеңдәге җаның ничек,
Безне шулай сөй сәнә…

Бу җырны Натукның әнисе Кәтернә түти бәрәңге әрчегәндә гел җырлый торган иде. Җырның сүзләрендә сагыш, аерылышу төсмере булмаса да, әнисенең йөзе, нигәдер, уйчан булыр, күзләреннән моң түгелер иде. Бу җыру, мөгаен, сөеклесе Питер белән икесе арасындагы матур сердер, яшьлек мәхәббәтләре середдер. Җыруны җырлаганда әнисенең күз алдына Питере белән яшәгән чаклары килә торгандыр да күңеле сагышланадыр…

Питер сугыштан кайтмады. Кәтернә түти берсеннән-берсе яшь биш бала белән тол калды. Атасының йөзен күрергә дә насыйп булмаган Натук бүген әнә шул җыруны үзе җырлап утыра:

Ак калпагың ки сәнә,
Кыңгыр сал да бер якка;
Ай калыккач чык, җанаш,
Очрашырга аулакта…

Кәтернә түти морҗага сөялгән дә онытылып җыру тыңлый, имеш. Бераздан әниләре янына Җәгүр абыйсы белән Иван килеп басты. Шул арада әллә кайдан Аннук белән Анный да пәйда булды. Алар һәммәсе — ап-ак киемнән. Барысының да карашы Натукта, имеш. Ул карашлар шундый якты — йөзләрендә елмаю чаткылары чагыла. Әнисенең күзендә моңның әсәре дә юк. «Нишләп болай икән?» — дип уйлый, имеш, Натук. Соравына җавап эзләп үз-үзен капшый башлый. Күлмәгем ертылмагандыр бит, дип уйлый. Капшый-капшый… Тик аның өстендә күлмәк юк! Чү! Натук үзе түгел бит бу! Җыр, җыр бу! Натук җырга әверелгән ләбаса!

«Ни-нәрсәгә ишарә соң бу? — дип, үз-үзенә сорау бирде ул. — Фанилыктан мәңгелеккә күчкән якыннарым да, исәннәре дә нишләп әле бергә күренә? Өлкән кешене нарасый итеп төштә күрсәң, авыруга юрыйлар…»

Натукны шөбһәле уйлар биләп алды.

Соңгы айларда аның кәефе гел начар. Кан басымы күтәрелә, йөрәге кага…

Натук торып юынды да әкренләп чәй әзерләде. Төшендә күргән балачагы,

искергән йортлары, нишләптер, күз алдыннан китмәде. Иске йорт үткәннәрне исенә төшерде. Җәгүр абыйсын хәрби хезмәткә озатуларын да хәтерли әле ул.

Көз иде. Төнлә беренче кар төшкән. Кар көндез эреп бетте, аяк асты сазланды. Киртә, читән буйларындагы бөдрә чирәмнәр генә ап-ак килеш утырды. Аларның өй каршына авыл егетләре җыелды. Бер-берсенең иңнәренә кулларын салып түгәрәк ясап басканнар да дөньяларын онытып җырлыйлар. Җырлары гел аерылышу турында. Моңнары йөрәк аша, җан аша сулкылдап чыга:

Төнгә каршы берәү моңлы итеп
Аерылышу көен җырлады;
Тынга калды урман буйлары да,
Чишмәләр дә акмый тыңлады…

Натук, күңеле белән җыр сүзләренә ияреп, урман буйларында йөри. Әнә, юл буендагы озын усакларның бер генә яфрагы да селкенми. Каен ботаклары, бөгелеп-бөгелеп, яшь түгә сыман. Ә җыр һаман тарала. Әнә, ул болыннар, калкулыклар буйлап килә-килә дә, Чөмәрәй, Гөргөри чишмәләре янына җитә. Чишмәләр сагыш тулы җырга мөлдерәмә карашларын төбәп, тып-тын кала…

Җәгүр абыйсыннан соң озак та үтмәде, Анный тутасы да туган йортны калдырды — Казанга барып житен комбинатына эшкә урнашты. Бу комбинатка паспортсыз да алалар икән эшкә. Аннары әле тулай торактан урын да биргәннәр. Бу чор Натук күңелендә бик әйбәт саклана. Анный тутасы бәйрәмдә авылга кайтыр иде. Букчасында мендәр конфет, бер-ике ак күмәч, клиндер ише, төшләргә генә керә торган тәм-том булыр иде. Әй, аларның тәме… Аны сөйләп тә, сүз белән аңлатып та булмастыр…

Уналтысы тулгач, Аннук тутасы да житен комбинатына юл тотты. Озакламый Иван дәдәсен дә хәрби хезмәткә озаттылар. Бөкрәйгән өйләре тагын да аскарак иелеп, күңелсезләнеп калды…

Кәтернә түти Казандагы балалары янына баргалый торган иде. Ул чакта Натук хуҗабикә була. Бер кәҗә, ике сарык, өч тавык аның тәрбиясендә кала.

Әнисе өйдә вакытта да эш җитәрлек. Җәй көне йә кукуруз, йә бәрәңге басуыннан чүп үләне җыялар. Малларга кышка азык кирәк бит. Курыкмыйча, иркенләп кенә барып җыясы булса, ярыйсы да… Тик… чүп үләнен алып кайтырга рөхсәт юк. Басу каравылчысы Рәкыйп күзенә күренергә ярамый. Шуңа күрә көндез шым гына җыеп куялар да үләннәрен, эңгер төшкәч кенә алып кайталар. Беркөнне күршеләре Марҗи түти дә үлән җыеп куйган икән — кичләтеп кукуруз җиренә кызлар бергә китте. Бәйләгән үләннәрен иңнәренә алып бер-ике адым атлаулары булды, әллә каян гына атын чаптырып кыр каравылчысы Рәкыйп килеп тә чыкты. Рәкыйп колхоз идарәсе урнашкан авылныкы. Бик явыз, диләр. Тәмсез телле. Имансызлыгы белән танылган. Һәрчак кулында чыбыркы уйнар, өстендәге иске кожаны җилбәгәй җибәрелгән булыр. Кыр каравылчысы килә-килешенә җилләнеп арбадан сикереп төште дә әче итеп сүгенде.

— Мин сезнең һәммәгезне дә сытып үтерәм хәзер!..

Кызлар куркудан, үләннәрен ташлап, кукуруз арасына посты.

...«Ходаем, бу кабахәт адәм Марҗи түтине нишләтә инде?» — дип, кызлар калтырана ук башлады. Рәкыйп, мыгырдана-мыгырдана, балаларның үләнен арбасына ыргытты да, атының камыт бавын ныклап бәйләргә кереште. Бу тамашаны карап торган шук телле Марҗи, кинәт шаркылдап көләргә тотынды:

— Кара әле, Рәкыйп, китәсең дәмени? Мин тагын рәкатьләр күреп үләм икән әле, дип көтеп торам. Ха-ха-ха... Син ятим нарасыйларны елатучы гына икәнсең. Ха-ха-ха...

Кыр каравылчысы әче итеп тагын бер сүгенде дә атын куалый-куалый китеп барды.

Натук бу көнне үзенә зур сабак алды. «Курыкмаска кирәк икән! Каршы торырга! Курыкканны эт тә куркыта, дип әни белеп әйтә икән».

...Ул җәйне Анный тутасы аңа өр-яңа күлмәк алып кайтты. Дүртенче сыйныфка шул күлмәген киеп йөри башлады Натук. Өстендә яңа күлмәк, муенында кызыл галстук. Гел «4»ле, «5»ле билгеләренә генә укый торган Натукның башы күктә. Җитмәсә әле укытучылары Кузьма Тимофеевич, дәрестән соң калдырып, аның белән сөйләшеп утырды:

— Район үзәгендә фестиваль буласы, Натук. Аннук белән икегез барырсыз инде!

Натук каушап калды. Гадәттәгечә ияге тартышып куйды. Сүзләрен әйтә алмыйча тотлыгып торды:

— К-к-кузьма Т-тим-мофеевич! Нәрсә суң ул ф-фе-стиваль?

— Ә-ә, курыкма, Натук. Фестиваль ул — җыр ярышы. Иманым камил, син беренче урынны алачаксың!

Натук курка шул. Тотлыгып, җырын башлый алмый торудан курка. Аның бу җитешсезлегенә әнисе дә бик борчыла. «Җөкле чагымда каршыма эт көтүе килеп чыкканые. Әллә шуннан инде Натугымның тотлыгып торуы. Бик курыкканыем шул», — дип искә ала...

Бардылар алар фестивальгә. Зу-у-ур клуб. Юк, аларның Чишмәбаш авылындагыише генә түгел. «Шулай зур булганга ишек өстенә урысчалатып «Дом культуры» дип язып куйганнардыр», — дип фикер йөртте Натук. Культура йорты бала-чага белән шыгрым тулы. Пәрдәсе төшерелгән сәхнәдә ыгы-зыгы. Оештырып йөрүче бер апа чыгыш ясарга тиешлеләрнең исемлеген барлый. Берәүләр, баянга кушылып, репетиция ясый... Аларның баянчысы юк бит. Натук белән Аннук ничек җырлар?

Кузьма Тимофеевич, шушы мәсьәләне хәл итәргә ниятләп, «Культура йорты» директорын эзләп китте.

— Безгә баянчы кирәк иде. Булышмассызмы икән? — диде укытучы.

— Кайсы авылдан?

— Чишмәбаштан без. Чишмәбаш мәктәбеннән.

— Ә-ә, керәшеннәр икән.

— Әйе, керәшеннәр, — диде Кузьма Тимофеевич, кабатлап. — Балалар баянсыз җырлый алмас бит инде.

— Җырламасалар соң! — диде, нигәдер җене чыккан директор. — Монда керәшеннәрдән башка да җырчы җитәрлек!

Укытучыларыннан калышмыйча ияреп йөргән Натук белән Аннук бу сөйләшүнең шаһиты булды...

Фестиваль башланды. Чират чишмәбашлыларга да җитте. Алып баручы көр тавыш белән кызларны игълан итте:

— Хәзер сәхнәгә Чишмәбаш мәктәбенең дүртенче класс укучылары Наталья Арсеньева белән Анна Подъячеваны чакырабыз. Алар «Фазыл чишмәсе»н башкара. Халык көе, Сибгат Хәким сүзләре!

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле төркеме чыгыш ясый.
Уртада (сулдан уңга): **Татарстанның халык артистлары Ания Туишева, Нәфисә Василова, Татарстанның атказанган артистлары** (сулдан уңга) **Илгизәр Исламов һәм Фәрит Мирзануров. Арткы планда – күренекле баянчы, Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин. Париж. 1990 нчы еллар**

Залдагылар гөрләтеп кул чабып, кызларны каршы алды. Натук белән Аннук җитәкләшеп сәхнә уртасына килеп басты. Натукның ирен читләре тартышып алды. Күз кырые белән дустанә караш ташлаган Аннук аның кулын кысты. «Каушама, башлыйбыз!» — дигән ишарә иде бу. Кызлар берьюлы җырлап та җибәрде:

Чылтырап аккан чишмәгә
Суга дип килгән идем...

Каушау онытылды. Натукның хыялы җыр сүзләренә ияреп, көй дулкынында тирбәлде...

Соңыннан аларга түш билгеләре тактылар, җылы сүзләр әйттеләр... Күңелләренә горурлык тулы җылы хис иңде. Тик, мәдәният йорты директорының: «Керәшеннәрдән башка да җырчылар җитәрлек!» — дигән каһкаһәле җөмләсе, бала күңеленә кылчык сыман кадалды да, озак әрнетте...

Хәер, ни генә булса да, фестиваль дигәннәре ничек кенә узса да, бу көн Натукның зур сәхнәгә беренче тапкыр аяк баскан көне иде.

***

Натук, урыныннан торып, тәрәзә каршысына килеп басты. Аның җиденче каттагы фатирыннан шәһәрнең ерак почмакларына хәтле күренә. Әнә, Кабанга терәлеп утырган Камал театры. «Артистлар, мөгаен, репетициягә барадыр, — дип уйлап куйды ул. — Ашыгалардыр...» Аның гына беркая да ашыгасы юк. Аның исеме язылган афишалар шәһәр урамнарында юк хәзер. Аны эштән чыгардылар. Дөресрәге, кудылар. «Егерме биш ел җырладың. Син ни консерватория, ни музыка училищесы тәмамламадың. Дипломың юк», — диделәр. «Диплом, имеш! Байлар аны хәзер сатып кына ала! Минем тавышым бар!» — диде Натук. «Юк, Әнисә ханым, пенсиягә чыгасыз!» — диделәр.

Натукның сәхнә псевдонимы — Әнисә Асылова. Бу исемне аңа татарның атаклы композиторы Александр Ключарёв үзе кушты! И-и, ул көннәр... И-и, ул узган гомерләр...

...Натукка унике яшь тулар-тулмас чакта алар Чишмәбаштан Казанга күченделәр. Әтиләре сугыштан кайтмагач, өлкәннәре китеп беткәч. Менә авам, менә җимереләм, дип торган өйдә Кәтернә түти белән Натук нишләсен? Казанга килеп, Анный тутасына сыенырга туры килде. Натук иң элек мәктәптә укыды. Унбиш яше тулгач, штукатурчылар, буяучылар әзерли торган училищега керде.

«Төзүче һөнәренә ия кеше кайда да эш таба», — дип киңәш итте өйдәгеләр. Укуын тәмамлагач, зур бер төзелеш идарәсенә җибәрделәр аны. Бригадада кызлар гына диярлек. Һәммәсе авылныкылар. Берсе дә эштән курка торган түгел. Җырлый-җырлый эшлиләр. Әле яңа өелгән йортның диварларын эчке яктан кызлар штукатурлый. Өсләрендә — буяу, ком, балчык измәсе белән чуарланган комбинезон. Ә ачык тәрәзәләрдән җыр агыла:

Озата барма, иркәм, озата барма,
Олы юл бит, бәлки, адашмам...

Бер көйне тәмамлагач, кызлар бераз гөрләшеп, сөйләшеп ала. Шул мәлне Натук җыр башлый:

Төнгә каршы берәү моңлы итеп
Аерылышу көен җырлады;
Тынга калды урман буйлары да,
Чишмәләр дә акмый тыңлады...

Кызлар да, эшләреннән туктап, тын калды. Әйе, бу җырны күбесенең Зифа апа Басыйрова башкаруында тыңлаганы бар. Аның тавышы да үзәкләрне телгәләп ала. Моңа гаҗәпләнер урын да юк. Зифа апа артист бит ул. Җырчы. Җитмәсә әле, ул баянга кушылып җырлый. Ә Натукның тавышы — икенче... Кызлар, әйтерсең лә кирпеч ватыклары, ком, балчык измәләре белән тулы караңгы диварлар арасында түгел, ә ямь-яшел табигать кочагында. Натукның тирән моңы, кабатланмас аһәңле сагышы тирә-юньдәге үсемлекләрне сыйпап уза. Аның җырын чишмәләр дә челтерәүдән туктап тыңлап тора. Агач яфраклары да селкенми... Ә урамда... Алар эшли торган тәрәзә турына халык җыелган. Бер ханым түзмәгән — кызлар янына ук кергән. Натукның җыры тәмамлануга һәммәсе гөрләтеп кул чапты. Урамнан кергән ханым, дулкынланып, аның кулларына килеп ябышты:

— Сеңлем, җаным! Синең урының — сәхнәдә! Тавышыңда дәрьялар көнләшерлек моң, чишмәләрне елатырлык сагыш бар. Рәхмәт, матурым!

Көтмәгәндә килеп чыккан мондый игътибардан чая гына Натук бераз каушап ук калды, ияк нервлары тартышып алды, бер мәл тотлыгып торды.

— Р-рә-рәх-мәт! — диде ул, бераздан.

Сүз дә юк: аның җырчы буласы килә. Бик килә. Тик... Алырлар микән соң? Аның музыкаль белеме юк бит. Алай да беркөнне тәвәккәлләргә ниятләде ул. Сорап, эшеннән алдарак китте дә, Җыр һәм бию ансамбле урнашкан бинаны эзләп тапты. Көзге көн иде. Урамда яфрак яңгыры ява. Салкынча җил битләрне кисеп уза.

Ансамбль урнашкан бинага килеп кергәндә репетиция тәмамланырга тора иде. Артистлар таралыша башлады. Гадәттә кыю Натук, монда кергәч, бераз каушабрак китте. Ияк нервлары тагын тартышып алды.

— И-и-сә-ән-ме-сез! — диде ул, тотлыга-тотлыга.

— Исәнмесез! — дип җавап бирде аңа мөлаем гына хатын-кыз. — Кем кирәк иде?

Чишмәбаш мәктәбенең залына охшаган бүлмәгә күз йөртеп алды Натук. Түрдәрәк бер өстәл. Кырыйдарак тагын берәү. Өстендә — баяннар. Түр өстәл янында тәмләп тәмәке көйрәтеп утыручы ир-атка игътибар итте кыз. «Минем бу абыйны күргәнем бар бит, — дип уйлап алды эченнән. — Кайда күрдем соң мин аны?» Әмма кыз хәтерли алмады. Бер-ике адым шул абыйга таба атлады.

— Ми-ми-нем җырчы буласым килә, — диде ул, ниһаять.

— Бик мәслихәт, — дип елмайды түрдәге абый, янып беткән тәмәке төпчеген көл савытында изә-изә. — Нинди җырлар беләсең?

— Халык җырларын яратып җырлыйм. Озын көйләрне.

Зифа буйлы, ачык йөзле, күзләреннән күңел сафлыгы бөркеп торучы кыз бала ир-атка ошады булса кирәк. Ул мөлаем ханымга мөрәҗәгать итте:

— Венера Хәсәновна, яшь җырчыны тыңлап карыйбызмы? — диде.

— Әлбәттә тыңлыйбыз, Александр Сергеевич.

— Нинди җыр җырлыйбыз? — диде Александр Сергеевич.

— «Гөлҗамал»ны, — диде Натук.

— «Гөлҗамал»ныммы? — дип кабатлап сорады композитор Александр Сергеевич Ключарёв, ялгыш ишетмимме, дигәндәй.

— Башладык, алайса.

Натукның күз карашы каядыр билгесезлеккә төбәлде... Аның күңеле кайчандыр апалары җыела торган аулак өйгә күченде. Башларына чәчәк-калфак кигән, түшләренә тәңкәләр белән бизәлгән күкрәкчәләр бәйләгән, толымнарына чулпылар таккан кызлар берсеннән-берсе моңлырак җыр җырлый. Аларның сөйгәннәре еракта. Кайсылары бәхет эзләп киткән, кайсылары солдат хезмәтендә.

...Натук дөньясын онытып «Гөлҗамал»ны җырлый:

Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал,
Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр.
Энҗе дә мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы...

Натук туктады. Аны тыңлаучылар да беразга тын калды. Табыш иде бу! Композитор өчен дә, хормейстер өчен дә табыш иде!

— Альт! — диде Александр Сергеевич. — Сирәк очрый торган затлы тавыш. Гөлсем Сөләйманова аһәңнәрен ишеткәндәй булдым. Исемеңне ничек дидең әле? — Ул Натукка таба борылды.

— Натук. Наталья Арсеньева. Авылда Натук диләр.

— Ә-ә, — дип елмайды Александр Сергеевич. — Керәшен кызымыни?

— Әйе.

— Кайсы якныкы?

— Чишмәбаштан мин. Саба ягыннан.

— Менә нәрсә, сеңелем, — диде Александр Сергеевич, тәмәке төтененнән саргаеп беткән бармакларын өстәл өстендә биетә-биетә. — Сәхнәдә син Наталья Арсеньева түгел, Әнисә Асылова булырсың. Чөнки син табигый асыл, затлы тавышка ия! Бер сүз белән әйткәндә — талант! Самородок! Шуңа күрә фамилияң Асылова булыр.

— Белемегез нинди? — дип кызыксынды мөлаем ханым. — Укыйсызмы?

— Мин төзелештә эшлим, — диде Натук, кырыс кына.

Натук ансамбльдә эшли башлаган көннәрдә гайбәт яратучы кыз-кыркын арасында шактый сүз йөрде:

— Штукатурчы-маляр да җырчы булдымы? Нота да танымый бит ул!

— Әйтмәсәң дә... «До»ны «ре»дан аера белмәгән башы белән...

***

Ансамбльгә килүенә Әнисәне бригадага алдылар. Александр Сергеевич Ключарёвның «Кәккүк» көен (Солтан Габәши музыкасы, Әхмәт Ерикәй шигыре) хор өчен эшкәрткән чагы. Башлап җырлауны композитор Әнисәгә тапшырды. Башлап җырларга теләүчеләр күп булса да, түбән альт тавышы белән Әнисәдәй иркен итеп, матур итеп җырлый алучы юк. Композитор да, хормейстер да, җырчы кызлар үзләре дә моны бик әйбәт белә.

Ул арада яшь композитор Марс Макаров олуг шагыйрь Хәсән Туфанның тирән фәлсәфә белән сугарылган, катлаулы язмышларның газапларын гаҗәеп

төгәл, оста итеп тасвирлаган «Киек казлар» шигыренә музыка язды. Бу җырны да Әнисәгә тапшырдылар.

...Бүген менә, гомеренең авыр мизгелләрендә, тәрәзә янәгына сөялгән дә шул җырны пышылдап көйли Әнисә:

Яңгырларда, явымнарда,
Давылларда-җилләрдә
Киек казлар кыйгылдаша
Мин белмәгән телләрдә.
Киек казлар кыйгылдаша,
Җырлашалар микәнни?
Туган илләр кала бит, дип
Елашалар микәнни?

Әнисәнең керфекләре дымлана. Тезелешеп очкан казларның моңсу кыйгылдашуы, канат кагышларының шавы ишетелгәндәй була. «Нәрсә соң син, җыр? — дип сорый ул үз-үзеннән. — Җанны тетрәндереп, уйларны әллә кайларга алып китәсең. Син, җыр, дәрья тирәнлегендә бәргәләнгән эчке дулкынмы, әллә җаннан ургып чыккан хисләр чишмәсеме? Синең эчтәлегеңне, моң агышыңны аңларга, төшенергә омтылган саен күңел кыллары ныграк тартыла, ныграк зеңли, үзәкләр ныграк өзелә», — дип нәтиҗә чыгара Әнисә.

Бүген ул үзе дә тоташ моңнан, әрнүдән генә тора диярлек. Әйтерсең лә бүген аның бар халәте — җырланмаган җыр. Ялгызлык, үзен кирәксез итеп тою аның җанын кимерә. Сәхнәсез ятим ул. Сәхнәсез чүл уртасында дымсыз-сусыз интегүче гөл. Менә ничә еллар инде көннән-көн сула ул, шиңә...

...Аны пенсиягә озаттылар. Җырчы булып эшләвенә егерме биш ел тулуга озаттылар. Гүя аның сулыш юлларын томаладылар. Әле яше илле бишкә дә җитмәгән. Тавышы күкрәгеннән гөрләп чыга. Аның концертларына тамашачылар яратып йөри... Юк, үзен болай тиз генә озатырлар, дип Әнисә көтмәгән иде. Дөрес, туры сүзлелеге бар: бу җитәкче кеше, тәнкыйть сүзен әйтергә ярамас, дип тормый. «Тәлинкә тоту», ярарга тырышу ише сыйфатлар аңа чит, ят. Җыр сәнгатендә, эстрадада ул үзенең лаеклы урынын белә...

Белеп нишлисең? Фәрман чыгарыла... Иртәгесен син эшкә килмисең. Ә ни-чек я-шәр-гә? Сәхнәдән аерылу канатлары киселгән кош сыман калу булса... Җан асрарга да кирәк бит әле. Мәдәният хезмәткәренең кеп-кечкенә пенсиясен ничек җтикерергә? Заманасы да нинди бит әле! Намустан башлап һәрнәрсә сатыла һәм сатып алына! Ил җимерелде. Кризис. Ел саен акча алышына... Әнә, гомере буе Камал театрында уйнаган талантлы артистларның берсе: «Пенсиягез күпме?» — дип сорагач, «Үләргә җитә, күмәргә җитми», — дигән. Моңа өстәр сүз юк. Бу — хакыйкать!

Әнисәне пенсиягә җибәргәндә карышып торырлык түгел иде. Синең музыкаль белемең, дипломың юк, диделәр аңа.

Авыр, күңелсез уйларыннан арынырга теләгәндәй, ул тагын яңа җырларны өйрәнгән, беренче булып башкарган көннәрен исенә төшерде.

...Беркөнне аның янына гөрләп, шаулап композитор Зиннур Гыйбадуллин килеп керде. Фаил Шәфигуллин сүзләренә ул яңа көй язган. Җырның исеме дә бик матур — «Яшьлегем тугае» дип атала. Сөенечен, дулкынлануын тыеп тормыйча, композитор кулына баян алды да сыздырып җибәрде. Нота өстенә язылган сүзләрне укый-укый, Әнисә аңа кушылды:

Ничәнче мәртәбә
Нурланып яз килде,
Тургайлар канатын кагынды.

Күзләрең сагышлы,
Дип әйтте бер тургай,
Нишлим соң, тургаем, сагындым.

Өйрәнде җырны Әнисә. Премьера көне дә җитте. И-и, ул кичә… Кочагы белән чәчәк күтәргән композитор сәхнәгә менде, аның артыннан Фаил. Зал алкышларга күмелде. Шушы искиткеч тантана шавын басарга теләгәндәй, бер ханымның ямьсез ысылдавы ишетелде:

— Бу боларның җырын гына түгел, үзләрен дә… алган икән…

Таныды бу тавышны Әнисә. Ул — аның хезмәттәше. Әллә ни тавышы булмаса да, гайбәт таратып йөрүчеләрнең берсе.

Адәм баласы никадәр сәләтсез булган саен көнчелеге шул тиклем зуррак була икән. Әнисә шушы хакыйкатькә тагын бер кат инанды.

…Аның гайбәтләргә дә, гаилә бәхетенең кыска гомерле булуына да исе китми. Аның менә дигән улы бар. Дөрес, сәхнәдән башка яшәү авыр, бик авыр. Сәхнә аның өчен хезмәт урыны гына түгел, сәхнә — аның дөньясы.

Пенсиягә җибәрелгәч тә зур сәхнәнең серле кочагында илаһи мизгелләр кичерергә насыйп булды аңа. Чишмәбаш авылында оештырылган «Нардуган» фольклор ансамбле Камал театрына концерт белән килде. «Аулак өй» дип аталган тамашага авылдашлары Әнисәне кунак кызы итеп дәштеләр. Ап-актан киенгән Әнисә сәхнә түрендә үзе чәчәк бәйләмен хәтерләтә иде. Залда аның якташлары. Гөргөри, Чөмәрәй чишмәләренең суын эчеп, Үри инешендә коенып, Баландыш тавы итәгендә уйнап-үскән авылдашлары. Ул аларга бүген иң яраткан җырларының берсен — «Киек казлар»ны җырлый:

…Казлар кебек очасылар,
Китәселәр юк минем,
Кыйгак-кыйгак, илем ерак,
Дияселәр юк минем.

Кыйгылдаша болытларда,
Мин белмәгән телләрдә,
Киек казлар китеп бара
Мин күрмәгән илләргә.

Ул чакта җыр дулкыны эчендә дөньясын онытып утырган тамашачы, Әнисә туктагач та, бераз тын торды. Аннары дәррәү кузгалып кул чабарга кереште…

***

Бүген менә әллә нәрсә генә булды. Дөнья бары тик моңнан гына тора сыман. Каршыдагы йортның тәрәзәләрен дә, урам буйлатып тезелгән агач яфракларын да сагыш сарган диярсең. Әй, шул сагышларны көйгә салып җырлыйсы иде! Әллә нәрсәгә бүген эшләгән чаклары исенә төшә. Күптән булган вакыйгалар күңел кылларына кагылып уза…

…Тәрәзә яңагына сөялеп кичерешләр дәрьясы эчендә тирбәлгәндә, кинәт кенә күз аллары томалана башлады. Җиңелчә генә башы әйләнеп китте, тез буыннары йомшаргандай тоелды. Ул әкрен генә ятагына таба борылды. Әнә, аның караваты янында морҗага сөялеп әнисе Кәтернә түти тора. Кулларын сузган да, кызына: «Натугым минем! Җырланмаган җырым! Кил үземә…» — дип кочып ала.

…Әнисә Асылова бу авыруыннан соң аягына кабат баса алмады…

Дөньяда 2006 ел иде. ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның октябрь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мәктәпләр комиссиясендә

Шәһәрнең мәктәпләр комиссиясенең 10 нчы октябрьгә билгеләнгән мәҗлесендә Яңа бистәдәге мәдрәсә янындагы русский класста сабак укыту мәсьәләсе каралачак булган. Ләкин бу мәсьәләне хәл кылу өчен комиссия әгъзасына сайланган мөселманнарның фикере кирәк булган. Әлеге мәҗлескә комиссия әгъзасы 6 мөселманның берсе генә дә килмәгәнгә күрә, мәсьәләне хәл итми калдырырга мәҗбүр булганнар. Комиссия, бу мөселманнарның гадәттә дә комиссия мәҗлесләренә килмәгәнлекләрен, бик күп вакытта мөселманнарга гаид [караган] мәсьәләләрдә шушы ялкаулыклар аркасында уңайсызлыкларга очралганлыгын игътибарга алып, мәктәпләр комиссиясе әгъзаларын арттыруны сорап Думага мөрәҗәгать итәргә карар кылган вә моның өстенә үткән Дума дәверендә эшлеклелеге белән танылган Ибраһим Яхинны сайлауны Думадан сорарга мәслихәт күргән.

Кояш. — 1915. — №823. — 18 октябрь.

Аитова ханымның кызлар мәктәбендә

Күптән түгел мөхбиребезгә Казанның мөкәммәл кызлар мәктәбе булган Аитова мәктәбенең мөдирәсе Фатиха ханым белән мәктәбе хакында мөзакәрә итәргә туры килде. Фатиха ханым татар кызларының укуларына сугыш вакытының зур тәэсире булмаганлыгын сөйли, мәктәп башка еллардагы шикелле үк тулы, кызларның мәктәпкә дәвамнарында һәм укуларында алдагы елдагыдан зур аерма күренми, ди. Ләкин, шуның белән бергә, Фатиха ханым мәктәпкә бәйле берничә хәлләрдән шикаять итә ки, бу хәлләр инде сугышка мөнәсәбәтле түгел, бәлки үзебездән генә килгән хәлләр һәм дикъкать ителеп, ислях ителергә тиешле хәлләрдер. Фатиха ханым әйтә: «Кызларыбызның татарча укытыла торган дәресләргә иткән әһәмиятләре бик зурдыр. Бу, табигый, куандырырлык хәлдер. Ләкин шәкертләребез арасында русча тел дәресенә һәм кул эшләренә бик зур дәрт итәргә теләмәгәнлек күренәдер. Боларга тәргыйб итү [кызыктыру] юлында мәктәп идарәсе тарафыннан сарыф ителә торган чаралар да кирәгенчә тәэсир итмиләр. Кирәк русчаның вә кирәк кул эшләренең әһәмиятен кызларыбыз өчен сөйләп торырга хәзерге көндә ихтыяҗ юк. Моны һәрбер татар үз башы белән уйлап таба. Шуңа күрә бу тугрыда без фәкать ата-аналарның балаларына тәэсир итүләрен генә көтәбез».

Моннан башка Фатиха ханым гаиләнең балалары укымыш вә хәрәкәтенә игътибар итмәвеннән зарлана: «Бездә гаилә баласын мәктәпкә китереп биргәч,

---

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Аитова кызлар мәктәбе 1909 елда Фатиха ханымның ире Сөләйман акчасына төзелгән бинада ачыла.

шуның белән үзенең вазифасы үтәлгәнгә хисаплый вә баласының хәленә үзе нәзарәт итми башлый. Чынлыкта бу эш, гаиләнең бу ваемсызлыгы, баланың кирәк укуына вә кирәк хәрәкәтенә начар тәэсир итә. Гаиләнең бу мөнәсәбәте кайсы вакытта тәмам гаҗәп бер дәрәҗәгә җитә. Безнең мәктәбебез вакыт-вакыт балаларның гаиләләренә сораулыклар таратып, баланың хәленә нисбәтле берничә сөаль бирә. Менә шул сорауларга бирелгән җаваплардан инде гаиләнең баласы хәленә бер дә игътибар итәргә теләмәгәнлеге күренә, хәттә күп аналар балаларының мәктәптән вакытлы кайтамы, юкмы икәнен дә дөрес итеп белмиләр, бер куелып киткән форма буенча «вакытлы кайта» дигән җавапны яза да бирәләр», — ди.

Мәктәп мөдирәсенең бу хаклы шикаятьләрен без балаларның гаиләләренә ирештереп, бу мәсьәләләрдә дикъкатьлерәк булырга тиешлекне аларның хәтерләренә төшерүне кирәк табабыз. Мәктәп гаиләнең игътибар вә ярдәменнән башка балаларны тәрбия итүдән гаҗиздер. Шуңа күрә ата-аналар бу турыда игътибарлы булып, балаларны тәрбия юлында мәктәп белән кулга-кул тотынып хәрәкәт итәргә тиешледер.

Кояш. — 1915. — №826. — 21 октябрь.

Яңа табиблар шифаханәсе*

Бу шифаханәгә мөдир итеп җәмгыяте хәйрия әгъзаларының үткәндәге гомуми җыелышында клиника ординаторы, табиб Әбүбәкер әфәнде Терегулов сайланган иде. Байтактан бирле килгән бәгъзы чибәр, бәгъзы зәгыйфь, бәгъзы дә бертөрле генә хәлдә дәвам итмәктә булган бу шифаханә хәзерге көндә мөдир әфәнде иҗтиһады белән мөтәхассыйс [специалист] табиблар шифаханәсе хәленә китерелгән.

«Сөт тамчысы»

Әбүбәкер әфәнде Терегулов тарафыннан күтәрелгән фикер буенча, җәмгыяте хәйрия шифаханәсе янында балаларның сау-тазалыгын саклауга хезмәт кылдыру максаты белән «сөт тамчысы» ачарга уйланганлыгы сөйләнмәктәдер. Мондый гүзәл бер максатның вөҗүдкә чыгуы матлуб [кирәкле] вә җәмгыяте хәйрия әгъзаларының моны булдыртырга тырышулары мәслихәттер.

Кояш. — 1915. — №828. — 23 октябрь

*Мәгълүмат кыскартып тәкъдим ителә.

Авылым мәзәкләре
яки Көлке куа килә...

Илдар Юзеев

КӨЛДЕРҮЧЕСЕ БУЛСА...

Актанышка килгәч, безне кунакханәгә урнаштырдылар. Бердәнбер клиент, яшьрәк кенә бер ир-егет каршылады.

— Сез әллә әртисләрме? — ди.

Сюжет корырга туры килде.

— Әртисләр, кәнишне. Син үзең кем?

— Уполминзагта күкәй җыям. Сез нинди әртисләр соң?

— Менә монысы... (Марс Шабаевка күрсәтәм)... Илһам Шакиров булыр...

Күкәй җыючыбыз, илһамланып, шатлыгыннан үкереп җибәрде:

— Илһам, бу синме?! Исәнме, малай?! Исеңдәме, синең белән бер утыруда йөз күкәй ашаган иек?..

— Истә, — ди «Илһам», — дөрес, мин аларның икесен генә ашаган ием...

— Менә монысы, — мин әйтәм, Габдрахман абыйны (Минский) күрсәтеп, — халык артисты Габдрахман Хәбибуллин. Монысы — атказанган артисткабыз Гөлшат Сәйфуллина... (Гөлшат Зәйнашева башын ия). «Зәңгәр шәл»не караганың бармы?

Егетебез, түзә алмыйча, баскан урынында бии башлый:

— Габдрахман абзый, тегене күрсәтегез инде... Хәзрәтне!..

«Артистыбыз» ялындырып тормый, шундук рольгә кереп китә, Гөлшатның күкрәк тирәсенә үреләː

— Күкрәгеңә җеннәр оялаган, Мәйсәрә, өшкерергә кирәк!..

Күкәй җыючыбыз, рәхәтләнеп, тәгәри-тәгәри көлә:

— Габдрахман абзыкаем, тагын бер генә тапкыр күрсәт инде, зинһар өчен!..

Габдрахман абзый тагын уйнап күрсәтә, тегене тагын тәгәрәтә.

Әле дә безнең шундый тамашачыларыбыз бар! Татар театрын әнә шул тәгәрәп көлә белүчеләр һәм тәгәрәтеп көлдерүчеләр, елатучылар — драматурглар тота.

Туфан Миңнуллин

ДӨРЕС ҖАВАП

Сугыштан соңгы елларда Әсма апаны кәнсәләргә чакырып алалар.

— Нигә эшкә чыкмыйсың? — ди председатель.

— Тамагым ач, өстем ялангач, эшкә чыгып ни файда, ашарыма булмагач, — ди Әсма апа.

Председатель янында утыручы счетовод кыз, сүзгә кушылып:

— Эшкә чыкмасаң, сурәтеңне, ташбакага атландырып, стена газетасына мыскыллап язабыз, — ди .

— Сталин гумер буе гәҗитттә тора әле, чуртым да булганы юк, —ди Әсма апа.

Дамир Гарифуллин

АВЫЛДА ГЫНА ИВАН ИКӘН

Керәшен авылларында исемнәрне үзләренчә үзгәртеп әйтү яки кушаматлар белән генә сөйләшү гадәте бар. Менә бер авылдан Метри белән Иван хәрби комиссариатка комиссиягә килгән.

— Мин — Метри Асанов, — дип яздырырга теләгән беренчесе.

— Ничек?

— Метри Асанов.

— Андый исем булмый.

— Метри инде, туганнан бирле Метри, — дигән бу егет. — Метри Асанов.

Кемдер сүзгә кушылган:

— Метри булгач, Дмитрий була инде ул, Дмитрий Асанов була...

— Син хәзер Дмитрий Асанов буласың, — дигән хәрби комиссариат хезмәткәре.

— Ярый, Дмитрий Асанов булырмын, — дигән бу.

Исемен яздырып чыккач, коридорда Иванны эзләп тапкан һәм аны читкәрәк алып киткән дә вәкарь белән генә:

— Син дә минем кебек көлкегә кала күрмә, син авылда гына Иван икән, монда Диван дип яздыр, — дигән ди.

Гарифҗан Мөхәммәтшин

КИТКӘННӘР ИКӘН...

Арбор авылы (Балтач). Февраль ае. Егетләр, ат чаналарына төяп, басудан колхоз фермасына салам ташый. Кышның соңгы көннәренә хас аяз кояшлы көн. Юл буенда басу читендә үсеп утырган ялгыз карама янына җиткәч, Мөхәммәтгали кинәт кенә «Тр-р-р-р-р» дип кычкырып җибәрә. Олаулардагы атлар берәм-берәм туктап кала. Егетләр башын чөеп карама башына карап торган Мөхәммәтгали янына җыела.

— Нәрсә булды, Мөхәммәтгали? — диләр, аптырап.

— Узган ел салам ташыганда менә бу карама башында өч карга утыра иде, киткәннәр икән! — ди аптыраган кыяфәтле Мөхәммәтгали.



Туфан Миңнуллин. З.Хәйруллин шаржы

Мөҗәһит Әхмәтҗанов

СЕБЕРКЕНЕ КЕМ АШЫЙ?

Ир белән хатын мунча яккан. Хатыны иреннән:

— Карале, сиңайтәм, себерке пешердеңме әле? — дип сораган.

Шулчак боларның кызлары Айсылуга бик кызык булып киткән:

—Себеркене кем ашый соң, эти? — дип сораган ул.

Гариф Ахунов турында мәзәкләр

Хөҗҗәт Гыйльфан

ИКЕ ДЕПУТАТ ҺӘМ БЕР ГАИШНИК

Вакыйга СССР заманында Мәскәүдә булган булса кирәк. Дусты Гариф Ахуновны янәшә утыртып, Мостай Кәримнең затлы «Волга»да шәһәр буйлап җилдерүе икән. Менә берзаман боларны гаишник туктаткан да йөртүчедән документын сораган, имеш. Мостай Кәримнең (шулай ук Гариф абыйның да) СССР депутаты булган чагы, ул шуны раслаучы таныклыгын түш кесәсеннән каударланмыйча гына тартып чыгарган да аклы-каралы тәпәч иясенә сузган. Гаишник, таныклыкка күз төшерүгә, үрә катып честь биргән һәм «шофёр» янында утырган Гариф абыйга сез кем буласыз инде, дигән сораулы карашын төшереп алган. Гариф Ахунов аңа болай дип сүз каткан, имеш:

— Если у меня шофёр депутат Верховного Совета СССР, то тогда кем буду я?

Рабит Батулла

ОЗАТУ

Бер җыелыштан соң кайтырга торганда Нәкый Исәнбәт сәркатип Гариф Ахуновка зарланып тора икән:

— Яшьләр санламый хәзер! — ди.

— Ни булды, Нәкый абый? — дип сорый Ахунов.

— Картларга ихтирамыгыз юк. Такси да чакырта алмыйсыз! — ди Исәнбәт.

Әдипне таксига утыртып, Ахунов озата китә. Кайтып җиткәч, таксига акчаны Гариф түли.

— Син шулай баймыни? — дип сорый Исәнбәт.

— Бай түгел, — ди Гариф. — Нәкый Исәнбәтнең өчтомлык мәкальләр китабының өченче томында, ике йөз сиксән җиденче биттә, өстән унҗиденче юлда мондый мәкаль бар: «Ярлы янудан курыкмас!»

— Шулаймыни? — ди Исәнбәт.

Баксаң, өчтомлыкта бу мәкаль бөтенләй юк икән.

Нәҗар Нәҗми

ТАТАРЛАРЫМ, БАТЫРЛАРЫМ…

Хәсән ага Туфанның 70 яшьлек юбилее. Котлаулар беткәч, аңа сүз бирделәр. Юбиляр трибуна артына басты да сүз башлады:

— Кадерле татарларым!..

Зал гөж килеп кул чапты. Моның сәбәбен аңламый калган, президиумда утырган КПСС Өлкә комитеты секретаре Мөҗәһит Вәлиев рәислек итүче Гариф Ахуновтан:

— Что? Что он сказал? — дип сорады. Ахунов шунда ук җавап бирде:

— Кадерле батырларым! — диде.

Татарча бик үк шәп белмәгән М.Вәлиев тынычланды булса кирәк.

ТАТАР АРМИЯСЕ

Мәҗит Гафуриның йөзьеллыгы. Шул көннәрдә генә Мәскәүдән миңа «Ветеран 2-ТА» («ТА» — танк армиясе) дигән медаль җибәргәннәр иде һәм мин шуны тагып алган идем.

Агыйдел буенда оештырылган табын башланыр алдыннан кул чайкап торган бер урыс язучысы: «Что за медаль? Что это значит «ТА»? — дип сорады миннән. Янәшә торган Гариф Ахунов шунда ук җавап бирде:

— «ТА» — «Татарская армия», — диде. ■

Мирасворд

- Татар хатын-кызларының борынгы баш киеме
- Язучы … Сабиров
- Башлангыч (иск.)
- «Рәдде бичара кыз» драмасының авторы
- Афанасий … (рус шагыйре)
- … ана яфрагы
- «Мартин …» (Джек Лондон романы)
- Татар-стандагы шәһәр
- Борынгы төркиләр байрагы
- Борынгы сугышчыларның күн,металл баш киеме
- Һади …
- Камыр әчету өчен савыт
- Владимир … (совет тел белгече)
- Грамматик категория
- Япония акчасы / … Миңнуллин
- Шәмсетдин … (мәгърифәтче, дин галиме)
- … Урда
- Кисәкчә
- Амударьяның борынгы исеме / Мирсәй …
- Элек арба күчәрен майлаганда кулланылган кара сыекча
- Чандыр, ябык
- Законтәртип өчен җаваплы офицер (иск.)
- Әлдермеш карты / Коръән сүрәсе
- … Тимбикова
- Грек хәрефе
- Будда монахы
- Җәяүлеләр күпере
- «Гөләндәм туташ хатирәсе» романының авторы
- Борынгы грекларда халык җыелышы
- Элек сугышта батырлык күрсәткән кешегә бирелгән бүләк
- Хельсинкида яши
- … Канашевич
- Маймылның бер төре
- Күрәзәлек, юрау
- Төрек акчасы / Борынгы грек шагыйре
- Вертолёт / Галим … Мәрданов
- Котылу, азат булу
- Аксыл кызыл

Рәис Габдулла төзеде.

9 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: «Чүкеч», Фаил, лазем, Әнәс, ыру, аркалык, Макар, әкә, җәя, егерме, ПЕН, Ашыт, «Ил», зәррә, Иктин, тахта, кын, арт, лигнит, «Мулла», Бигиев, инша, Зыя.
Өстән аска: Ика, фауна, җепкыр, Әрмән, ТНТ, Ильская, бүз, ак, Нәҗми, лаеш, угия, «Ыргыз», эллин, чолык, тәте, Илеш, ар, Ра, гавам, кызу, Әмирхан, келәт, чүмәлә, «Ант».

Бертуган Алафузовлар төзеткән фабрика бинасы

«Безнең мирас»

елъязмасы /октябрь

- **760 ел элек (1255)**

Иске Сарай каласында бөек Чыңгыз ханның оныгы, Җүчинең угылы Батый (Бату) хан (1209-1255) вафат була.

- **155 ел элек (1860)**

Казанда абыйлы-энеле Алафузовларның тегү фабрикасы һәм күн заводына нигез салына.

- **140 ел элек (1875)**

2 октябрьдә Казанда атлы трамвайлар йөри башлый.

- **130 ел элек (1885)**

1 октябрьдә Казан почта-телеграф округы төзелә.

- **80 ел элек (1935)**

28 октябрьдә Татар дәүләт академия театрында «Профессор Мамлок» спектакленең премьерасы (алман язучысы Фридрих Вольф әсәре) була. Спектакльне карау өчен Казанга әсәрнең авторы Ф.Вольф килә. Ул пьесаны яхшы куюы өчен ТДАТ коллективына рәхмәт хаты белән мөрәҗәгать итә.

Хаттан: «Фашизмга каршы пьесамның татар телендә башкарылуын бик тә сагаеп көттем. Ләкин сезнең аны кабул иткәндәге мәхәббәтегез, бу гаять авыр теманы үзләштергәндәге илһамыгыз һәм, ниһаять, премьера вакытында безнең арада урнашкан һәм чын күңелдән булганлыктан, шундый матур формалар алган мөнәсәбәт — болар барысы да мин көткәннәрдән күп өлеш артык булып чыкты.

Безнең арадагы бәйләнешнең киләчәктә дә өзелмәвен чын күңелдән телим».

- **60 ел элек (1955)**

«Совет әдәбияты» журналында Илдар Юзеевның «Таныш моңнар» поэмасы дөнья күрә.

- **25 ел элек (1990)**

Казан консерваториясенең Зур концерт залында Сөембикә манарасына ай куюга багышланган әдәби-музыкаль кичә була. ■

Фиринат Гаптелхәй улы Халиков 1957 елның 28 августында Украина ССРның Донецк шәһәрендә дөньяга килә. Киров сәнгать училищесын (1984), Россия сәнгать Академиясенең Казандагы рәсем иҗаты остаханәсен (1996) тәмамлый.

Фиринат Халиков — СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1989), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2001), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2006). Рәссам татарның борынгы тарихына багышланган йөзләгән рәсемнәре белән танылды. Ул скульптура жанрында да иҗат итә. Мәсәлән, Алабуга шәһәренә нигез салучы бөек болгар әмире Ибраһим бин Мөхәммәд истәлегенә ясалган сынның авторы — Ф.Халиков.

Фиринат Халиков

Алабугада бөек болгар әмире Ибраһим бин Мөхәммәдкә куелган бронза һәйкәл

«Сөембикә җыен җыя». 2005.
Киндер, майлы буяу

www.beznenmiras.ru

БЕЗ – МИРАСЛЫ ХАЛЫК!

«Безнең мирас» белән бергә булыгыз!

2016 елның беренче ярты еллыгына почтада язылу бәясе – 498 сум

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132
РОССИЯДӘ – 70275

«Безнең мирас» журналына башкача язылу:

- www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә – 498 сум
- редакциядә – 380 сум
- www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия – 350 сум

4 612750 670172

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, Г.Тукай музеендагы киосктан (Г.Тукай ур., 74) , «ТАТМЕДИА» АҖ бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан метросы киоскларыннан сатып алырга мөмкин.